ӘШЛИСЕ КИЛӘ!

Ата-ана «юк» дисә дә, дәүләт рөхсәт итә

> 15

ВАТАН УЛЫ

Россия Герое Иван Додосовның тормыш сәхифәләре

> 16

МОҢЛЫ МИРАС

Гомерен татар сәнгатенә багышлаган кешенең мирасы өчен гаиләсе генә җаваплымы?

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 170 (28943) | Җомга | 18 ноябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

«ВТ» архивыннан

ХУҖАҢ КЕМ, АВЫЛ?

ПАЙЧЫЛАР ҮЗ ҖИРЛӘРЕН АЛЫРГА ТЕЛИ

Пай җирләрен инвесторларга биреп, аларны кире ала алмаулары турындагы хәбәрләр төрле районнардан әледән-әле ишетелеп тора. Яңа Чишмә районының Шахмай авылыннан да шундый эчтәлектәге мөрәҗәгать килеп ирешкәч, хәлне ачыклар өчен, юлга кузгалдык.

> 6

Ишетми калмагыз

Татарстанда мобилизацияләнүчеләрнең генә түгел, бәлки «Алга» һәм «Тимер» батальоннары хәрбиләре, шулай ук махсус хәрби операция зонасына командировкага җибәрелүче Росгвардия, Эчке эшләр министрлыгы, Иминлек федераль хезмәте идарәсе хезмәткәрләренең балигъ булмаган балаларына да бер тапкыр 20шәр мең сум түләнәчәк. Татарстан Премьер-министры шул хактагы карарны имзалаган.

Моның өчен акча Татарстан Хөкүмәтенең резерв фондыннан биреләчәк. Документның гамәлдә булуы 24 февральдән (махсус хәрби операция башлану көненнән) барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

Россия Мәгърифәт министрлыгы барлык мәктәпләргә бер үк төрле кием кертүне күздә тота. Бу хакта министр Сергей Кравцов депутатлар алдында ясаган чыгышында белдергән.

РБК хәбәренә караганда, Дәүләт Думасының Гаилә, хатын-кызлар һәм балалар мәсьәләләре комитеты рәисе Нина Останина бердәм пособие алмаучы гаиләләргә мәктәп формасына акча бирергә тәкъдим иткән. «Универсаль пособиесез гаиләләргә беренче сентябрь алдыннан мәктәп киеме сатып алу өчен акча бирү тәкъдимен кертәчәкбез», – дигән ул. Депутат әйтүенчә, форма сатып алу өчен акча мәсьәләсен хәл итәргә кирәк, чөнки төрле гаиләләрнең матди хәле төрлечә.

Сүз уңаеннан, Дума бала туу һәм аны карауга бәйле бердәм пособие билгеләүне күздә тоткан законны сишәмбе көнне кабул итте.

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан буенча Баш идарәсе быел 10 ай эчендә бездә яшәү шартларын бозган 561 чит ил кешесен илләренә озаткан. Алар судта Россиянең Административ хокук бозулар турында кодексы статьясы буенча гаепле дип танылган. Бездәге тәртипләрне санга сукмаучыларның күбесе элекке Советлар Союзы республикаларыннан – Таҗикстан, Үзбәкстаннан. Суд приставлары шулай ук Нигерия, Конго, Куба, Германиядән килүчеләрне дә өйләренә кайтарып җибәргән.

Мигрантлар башта Чаллы шәһәрендәге Чит ил кешеләрен вакытлыча тоту үзәгенә җибәрелә. Юлга билет алганнан соң, Баш идарәнең суд приставлары аларны Россия чиге аша кертү-чыгару пунктына – аэропортка кадәр озата.

Татарстан октябрь аенда иң күп автокредит бирелгән төбәкләр рейтингына эләккән. ТАСС агентлыгы Илкүләм кредит тарихлары бюросы мәгълүматларына таянып язганча, машиналы булу өчен иң күп кредитны Мәскәүдә (2,67 мең), Мәскәү өлкәсе (2,59 мең), Татарстан (2,29 мең), Санкт-Петербург (2,23 мең) һәм Краснодар краенда яшәүчеләр (2,2 мең) алган. Әмма октябрьдәге автокредитлар саны барыбер узган елның шушы ук чорындагы белән чагыштырганда 42,2 процентка кимегән (80,6 меңнән 46,6 меңгә калган).

Районнарда ни хәлләр?

Актаныш

Колын халкы авылдашлары – 75 яшьлек Фәндәлия Габдуллинаны өйле иткән. Торган йорты яшәрлек хәлдә булмагач, аны Пучыдагы картлар һәм инвалидлар йортына илтергә җыеналар. Әмма Иске Айман авыл җирлеге башлыгы Марсель Әхмәтханов буш өйләрне барлый башлый. Фәндәлия апага сыеныр урынны күршедәге йортта табалар. Фәндәлия апаны кызыл балчык белән бүрәнә аралары сыланган йорттан күчерүгә авыл белән тотыналар. Күршедәге өйне яңадан сүтеп җыялар игелекле авылдашлар. Түшәмнәрен, идәннәрен алыштырып буйыйлар, стеналарына обой ябыштыралар. Идәннәренә паласлар җәяләр. Газ торбалары да ап-ак итеп буяла. Октябрь башында, Өлкәннәр көнкөнлегендә, өмә белән, Фәндәлия апаны күчереп тә куялар. «Мондый йортта яшәрмен дип уйламаган да идем», – дип сөенә ул.
(«Актаныш-информ»)

Әлмәт

Районның ЗАГС идарәсендә Екатерина һәм Радик Гомәровларны котладылар. Аларның гаиләсендә 15 ноябрьдә дөньяга килгән кыз – быел Әлмәт районында туган 1700 нче сабый. Бәхетле әти-әнигә баланың беренче документын – туу турында таныклык тапшырдылар. Хәзер алар – күпбалалы гаилә. Агатаны өйдә абыйсы Родион һәм апасы Радмила көтә.
(«Әлмәт таңнары»)

Буа

Гүзәлия Азизова – Буа эчке эшләр бүлегендә полициянең участок хезмәткәрләре арасында бердәнбер хатын-кыз. Полиция капитаны органнарда инде җиде ел эшли. Ул тәртип саклый торган участокта өч мең чамасы кеше яши. Гүзәлия Азизова аларның һәрберсен диярлек танып белә. Мәктәпне тәмамлагач, ул башта юрист белеме ала. Аннары Казанда полиция участогында хезмәт итә башлый. 2019 елдан Буада эшли.
(«Байрак»)

Мамадыш

Югары Ушмы авылы мәктәбендә махсус хәрби операциядә һәлак булган Ирек Садыйков истәлегенә мемориаль такта куелды. Ирек кайчандыр шушы мәктәпне тәмамлаган. «Бөтен Мамадыш районы үз герое белән горурланачак. Аның истәлеге мемориаль тактада гына түгел, безнең күңелләребездә дә сакланачак», – диде район хакимияте башлыгы Анатолий Иванов. Ирек Садыйковка 24 яшь булган. Мәктәптән соң Мамадыш политехник көллиятендә инженер-технолог һөнәрен үзләштергәч, армия сафларына киткән. Украинада хәрби махсус операция башлангач, аның частен хәрби бурычны үтәргә җибәрәләр. Ефрейтор Ирек Садыйков 23 апрельдә Мариуполь янында минага эләгеп һәлак булган. Ирекне ул хезмәт иткән һәм хатыны белән яшәгән Валуйка шәһәрендә җирләгәннәр.
(«Нократ»)

ТАТАРСТАН – БИШЕНЧЕ

ФӘННИ-ТЕХНОЛОГИК ҮСЕШ БУЕНЧА ИЛКҮЛӘМ РЕЙТИНГ ИГЪЛАН ИТЕЛДЕ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов фәнни-технологик үсеш һәм Дәүләт Советының Фән буенча комиссияләренең уртак утырышында катнашты. Утырышны Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Дмитрий Чернышенко һәм Дәүләт Советының Фән юнәлеше буенча комиссиясе рәисе, Новосибирск өлкәсе губернаторы Андрей Травников үткәрде.

Чара кысасында беренче тапкыр 2021 елда төбәкләрнең фәнни-технологик үсеш буенча илкүләм рейтингы тәкъдим ителде. Андый рейтингны төзергә Россия Президенты Владимир Путин кушкан иде. Әлеге эшнең төп максаты – күрсәткечләр ярдәмендә төбәкләр һәм технологияләр юнәлешенә игътибарны арттыру. Тикшеренү уздырганда фән белән шөгыльләнүче белгечләр, алар арасында яшьләрнең саны, төбәкләр тарафыннан тотылган чыгымнар күләме, икътисадта ил технологияләренең ни дәрәҗәдә кулланылуын күздә тоталар.

Быел илкүләм фәнни-технологик үсеш рейтингында беренче өч урынны Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Томск өлкәсе алган. Татарстан – бишенче урында. Беренче унлыкка Башкортстан, Новосибирск, Свердловск, Ульян, Мәскәү һәм Түбән Новгород өлкәләре кергән.

Президент Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, Татарстан илнең фәнни-технологик үсешенә зур өлеш кертә. Республикада «Фән һәм университетлар» илкүләм проекты кысасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни үзәк, шулай ук махсуслаштырылган уку һәм фән, инженерлык үзәкләре булдырылды. Тикшеренүләр юнәлешендә җиһазлар һәм кадрлар яңартыла. Яшьләрнең фәнни лабораторияләре челтәре булдырылган. Предприятиеләрнең югары уку йортлары һәм фәнни оешмалар белән элемтәләре ныгый, кооперация элемтәләре тирәнәя. «Бүген илебезнең технологик бәйсезлеген торгызу бурычы беренче планга чыга. Татарстанның фәнни комплексын үстерү эше әнә шул мәсьәләне күздә тотып башкарыла», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Билгеле булганча, бу атнада Рөстәм Миңнеханов Татарстан Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советының чираттагы утырышын уздырды. Анда ул фән-мәгариф комплексын яңа дәрәҗәгә күтәрүне республика алдындагы мөһим бурыч дип атады.

Дәүләт Советында

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин «Бердәм Россиянең Яшь гвардиясе» республика бүлеге активистлары белән очрашты. Очрашуда яшьләр алдында торган бурычлар турында фикер алыштылар.

«Көндәлек хезмәтегез, конкрет эшләрегез белән ватанпәрвәрлекне, тормышта актив позициядә торуыгызны күрсәтәсез, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Бүгенге шартларда, бигрәк тә нык үсешле, күпмилләтле республикабызда мондый сыйфатлар аеруча кирәк».

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, бүген партиянең республика оешмасында 129 меңнән артык кеше бар. Татарстанда иң җаваплы, иң җитди сәяси көч ул. «Язмышыгызны «Бердәм Россия»гә бәйләп, үзегезне зур партия эшенә һәм иҗтимагый эшчәнлеккә әзерлисез, – диде партиянең Татарстандагы төбәк бүлеге сәяси советы секретаре. – Партиябезнең киләчәге яшь алмашка, яшь көчләрнең килүенә бәйле. «Яшьләр парламенты», «Яшьләр Хөкүмәте», «Талантлар университеты», «ПолитЗавод» кебек республика һәм партия проектлары сәяси активлыкны үстерүгә юнәлдерелгән».

Фәрит Мөхәммәтшин Донбасстан мәҗбүри күченүчеләргә, шулай ук азат ителгән территорияләрдә яшәүчеләргә гуманитар ярдәм күрсәтүне «Бердәм Россиянең Яшь гвардиясе» эшендә төп юнәлеш буларак атап үтте. «Мондый эшегез өчен барыгызга да рәхмәт, – диде ул. – Сез, гуманитар йөкләрне аралап, азык-төлек, беренче чиратта кирәкле әйберләрне кешеләрне вакытлыча урнаштыру пунктларына таратып, беренче ярдәм күрсәтеп, балалар белән эшләп,

tatarstan.ru

югалган кешеләрне табарга ярдәм итеп, иң мөһим сыйфатларыгызны күрсәтеп киләсез. «Без бергә» гуманитар штабы көче белән 142,3 тоннадан артыграк гуманитар йөк төяп озатылды. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга кирәкле әйберләр җыеп озату, мобилизацияләнүчеләрнең гаиләләренә булышу дәвам итә».

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, бүгенге шартларда партия һәм аның яшьләр «канаты»ның көчен берләштерергә кирәк. «Илебез авыр чор кичерә. Без бергә, бердәм булырга тиеш», – диде ул.

Казанда хакимият, эш бирүчеләр һәм һөнәр берлекләре арасындагы хезмәттәшлек турында фикер алыштылар. Бу эшкә нигез салынуның 30 еллыгына багышланган фәнни-гамәли конференциядә катнашучыларны республика җитәкчелеге исеменнән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин сәламләде.

Республика парламенты җитәкчесе фикеренчә, социаль партнерлык буенча хезмәттәшлек республика файдасына эшли.

– 30 ел элек тә, бүген дә республика алдында җитди бурычлар тора, – диде ул. – Әмма без аларны һәрвакыт бергә хәл итәбез. Республикада социаль партнерлык һәм өчъяклы килешүләр һөнәр берлекләре, эш бирүчеләр һәм хакимияткә үзара хезмәттәшлек итәргә яхшы этәргеч бирә.

Фәрит Мөхәммәтшин профсоюз лидерларына алга таба да республикада гамәлгә ашырыла торган барлык файдалы эшләр башында торуны теләде. Алар исә Дәүләт Советы Рәисенә Идел буе федераль округы профсоюзларының территориаль оешмалары ассоциациясенең «Һөнәр берлекләре хәрәкәтен үстерүгә өлеш керткән өчен» күкрәк билгесе тапшырды. Ә парламентаризм музеена шахмат бүләк иттеләр. Мәгънәсе дә бар: зур эшләр кара-каршы утырып хәл ителергә тиеш.

Моннан утыз ел элек, 1992 елда, республикада социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчъяклы республика комиссиясе төзелгән һәм Министрлар Кабинеты, Республика Профсоюзлар советы һәм Татарстан дәүләт предприятиеләре ассоциациясе арасында беренче өчъяклы килешүгә кул куелган иде.

ЧИРАТ ТОРАСЫ ЮК

ЦИФРЛЫ СИСТЕМАГА КҮЧҮ РЕСПУБЛИКА КЛИНИК ХАСТАХАНӘСЕ ТОРМЫШЫН НИЧЕК ҮЗГӘРТКӘН?

Республика клиник хастаханәсе «цифрлы клиника» дигән халыкара статус алды. Заманча технологияләр пациентларга мөнәсәбәтне ничек үзгәрткән? Татарстанның баш хастаханәсендә хәзер ничек дәвалыйлар? Без әнә шуларны белешеп кайттык.

t.me/nashtatarstan_official

Татарстанның әйдәп баручы хастаханәсе Россиядә Сәламәтлек саклау министрлыгы системасына караган оешмалар арасында мондый халыкара статуска ия беренче клиника булды. HIMSS (дөньяда медицина өлкәсен мәгълүматлаштыру сыйфатын бәяләүче бердәнбер оешма) халыкара сертификаты клиникага узган атнада бирелде. Эшне 10 ай эчендә башкарып чыкканнар. Бу максатларга 450 млн сумга якын акча тотылган һәм 3,6 мең хезмәткәр өчен 6 мең тренинг үткәрелгән. Хәзер табиблар электрон мәгълүмат системасында эшли. Ул ярдәм күрсәтүне бердәм система аша оператив рәвештә оештыруга мөмкинлек бирә.

Баш табиб Рафаэль Шәвәлиев сүзләренә караганда, хәзер хастаханәдә нәтиҗәле эшләү өчен барлык шартлар да тудырылган.

– Республика клиник хастаханәсе – республикабызның сәламәтлек саклау өлкәсендә флагман. Безгә тәүлегенә 100–120 пациент мөрәҗәгать итә, планлы рәвештә – тагын 150. Көненә барлыгы 250–280 пациент кабул итәбез. Теркәлүдән башлап, хастаханәдән дәваланып чыгуга кадәр – пациентка бәйле барлык процессларны цифрлаштырдык. Хәзер без аларның барысын да онлайн рәвештә күзәтәбез. Теләсә кайсы вакытта һәр пациентның кайда булуын, аның белән нинди табиб шөгыльләнүен беләбез. Системада эшләү өчен, шәфкать туташларына, дежур персоналга һәм бүлек мөдирләренә планшетлар бирелде, – диде баш табиб.

Дөрестән дә, хастаханә зур үзгәрешләр кичергән. Иң мөһиме – яңа мәгълүмати система кәгазьдән цифрга күчәргә мөмкинлек биргән. Барлык хезмәтләр дә хәзер бер системада башкарыла. Табибларга – вакыт сарыф итеп, кәгазь тутырырга, ә пациентларга озын-озак чиратларда торырга кирәкми. Система үзе бөтен хастаханәне тәртипкә сала.

– Барлык процесслар да автоматлаштырылган, шуңа хәзер кабул итү бүлекләрендә чират җыелмый. Хирурглар элек бик күп вакытларын кәгазь эшенә сарыф итә иде. Хәзер аларның хәтта күбрәк операцияләр ясарга да вакытлары кала. Моннан тыш, тагын да катлаулырак пациентларны кабул итү мөмкинлеге барлыкка килде. Әйтик, хәзер без бөерләрне һәм бавырны кан белән тәэмин итүче аорта, кан тамырлары белән эшли алабыз. Элек андый авыр операцияләргә алынырга батырчылык итми идек. Узган елгы белән чагыштырганда, быел 1300 операциягә күбрәк ясадык, – ди баш табиб.

Рафаэль Шәвәлиев әйтүенчә, эчке процессларны тәртипкә салу артык чыгымнардан да котылырга мөмкинлек бирә.

– Даруларны азрак сарыф итә башладык. Система табибка һәм консультантка бер-берсенә туры килмәгән, әйтик, антибиотик һәм ялкынсынуга каршы препаратны билгеләргә рөхсәт итми. Шулай ук, әгәр системада андый мәгълүмат булса, доктор препаратларны дөрес булмаган дозада яки пациентның аллергиясе булган даруны билгели алмый. Система бу турыда үзе хәбәр итә. Сүз сырхауның иминлеге турында бара. Система медицина ярдәменең куркынычсызлыгын тәэмин итәргә, ә табибка хаталарны булдырмаска мөмкинлек бирә, – диде ул.

Шәфкать туташларының да эше бернигадәр җиңеләйгән. Хәзер аларның кул астында ноутбук кына түгел, ә күчереп йөртә торган мобиль пост, дарулар һәм ярдәм күрсәтү өчен барлык кирәк-яраклар бар. Мобиль пост процедураларны пациентның караваты янында башкарырга мөмкинлек бирә. Шәфкать туташы шунда ук дәваланучының температурасын һәм кан басымын үлчи, кирәкле даруларны бирә. Аларның һәркайсының цифрлы штрих-коды бар.

Медицина картасы урынына һәр пациентның штрих-кодлы беләзеге барлыкка килгән. Бу аның авыру тарихын белергә, табибларга пациентны дәвалау планын төзергә ярдәм итә. Анализларга исә бернинди амбулатор карталар да кирәкми. Тикшеренүләрнең һәм дәвалауның барлык мәгълүматлары бердәм мәгълүмат системасына керә. Ул пациентның хәлен белү диаграммасын автомат рәвештә төзи.

Хастаханәнең 1 нче кабул итү-диагностика бүлеге мөдире Алексей Толстиков да HIMSS стандартларына күчүнең клиника эшен югары һәм сыйфатлы дәрәҗәгә күтәрүен билгеләп үтте.

– Әлеге система пациентның хәлен күзәтергә генә түгел, аның белән булган барлык үзгәрешләрне дә анализларга мөмкинлек бирә. Хәзер барлык мәгълүмат компьютерда бар. Бу безнең вакытны сизелерлек кыскартты. Әйтик, анализлар алу элек 10–15 минутка сузылса, хәзер 5 минут җитә. Мондый дәвалау тиз һәм нәтиҗәле, – диде Алексей Толстиков.

Ләйсән САФИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Россия дәүләтчелеген ныгытудагы, парламентаризмны үстерүдәге зур өлеше һәм актив төстә законнар иҗат итү эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе **Мөхәммәтшин** Фәрит Хәйрулла улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **Александр Невский ордены** белән бүләкләнде.

***

Хезмәттәге казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Татавтодор» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Шәймиев** Айрат Минтимер улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **Почет ордены** белән бүләкләнде.

***

Гаилә институтын ныгытудагы һәм балалар тәрбияләүдәге зур казанышлары өчен **Гыйлаҗева** Гөлназ Тимергали кызы, **Фаретдинов** Айдар Рәфис улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ата-ана даны» ордены медале** белән бүләкләнделәр.

***

Гаилә институтын ныгытудагы һәм балалар тәрбияләүдәге зур казанышлары өчен **Гыйльмурадова** Лилия Николаевна, **Гыйльмурадов** Мансур Сарыйм улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ата-ана даны» ордены медале** белән бүләкләнделәр.

***

Фәнни-педагогик эшчәнлегендәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Казан дәүләт энергетика университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең кафедра мөдире **Ильин** Владимир Кузьмичка Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган югары мәктәп хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасының икътисади һәм сәнәгать потенциалын ныгытуга мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Когогин** Сергей Анатольевич **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

Мирасны саклаганда

«Әлеге чараны уздыру өчен нәкъ менә Татарстанны сайлаулары юкка түгел». Казан кабат дөньяның төрле илләре белгечләренең очрашу урынына әвереләчәк. Декабрь башында Татарстан башкаласында Бөтендөнья табигый һәм мәдәни мирасны саклау конвенциясенең 50 еллыгына багышланган халыкара форум узачак.

Чара 1 декабрьдә Санкт-Петербургта башланып, 4 декабрьдә Казанда дәвам итәчәк. Бу хакта Казан Кремлендә журналистлар белән очрашуда сөйләделәр. Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова сүзләренчә, форумда меңләп белгечнең катнашуы көтелә.

– Шул исәптән 300ләп яшь белгеч килер, дип көтәбез. Әлегә тәгаен генә катнашучы илләрнең дә, белгечләрнең дә төгәл санын әйтә алмыйбыз. Форум кысасында төрле мәйданчыкларда барлыгы тугыз чара узачак. Әйтик, 10 елдан соң ЮНЕСКО комитетының яшьләр моделе кабат Казанда узачак. Шулай ук форум кысасында «Бөек ефәк юлы» проекты турында фикер алышулар булачак, – дип сөйләде министр.

Чараны оештыручылар – Россиянең Тышкы эшләр министрлыгы һәм Татарстан Хөкүмәте. Форумда катнашучы илләргә килгәндә, оештыручылар БДБ, Африка, Латин Америкасы илләреннән, Франция, Греция, Сүрия, Иордания, Монголиядән кунаклар көтә.

КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры Рамил Хәйретдинов әлеге дәрәҗәле чараның ни өчен нәкъ менә Татарстанда уздырылуының сәбәбен атады.

– Бу – беренче чиратта, Татарстанның һәм Россиянең тарихи мирасны саклау өлкәсендәге казанышларын тану, – диде ул. – Халыкара мөнәсәбәтләрнең ни дәрәҗәдә сәясәтләштерелгәнен аңлыйсыздыр. Әмма шундый шартларда да чит илләрдәге фикердәшләребез белән элемтәләр өзелмәде. Хәзергә вакытта без ЮНЕСКО исемлегенә кертү өчен Татарстандагы тагын бер объектны әзерлибез. Ул – КФУның астрономик обсерваториясе. Бу мәсьәлә 25 ноябрьдә Парижда узасы фикер алышуларда да күтәреләчәк.

Аның сүзен Һәйкәлләрне һәм истәлекле урыннарны саклау буенча халыкара берлекнең (ИКОМОС) илкүләм комитеты вице-президенты Рафаэль Вәлиев дәвам иттерде:

– Казан Кремле ЮНЕСКО исемлегенә 2000 елда кертелде. Болгар – 2014 елда, Свияжск – 2017дә. 2023 елда исә Казан обсерваториясенең дә шушы ук исемлеккә кертелүен көтәбез, – диде ул.

Сүз уңаеннан, ЮНЕСКО исемлегендә Россиядән 18 мәдәни объект бар.

– Без еш кына тегеләй яки бу тарихи вакыйганы бүгенгебез аша бәялибез. Миңа калса, моннан 50 ел элек башлап җибәрелгән эш безгә һәм бездән соңгы буынга борынгы бабаларыбыз калдырган мираска тагын да җаваплы карарга этәргеч бирә. Болгар һәм Казан Кремленең – мең еллык, ә Зөя утрау-шәһәрчегенең биш гасырлык тарихы бар. Бу һәм башка кадерле тарихи урыннарыбызның яшь буынга яхшы хәлдә тапшырылуы бик мөһим, – ди Ирада Әюпова.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Әйтеп кенә бактым

Мода

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Кышкы салкында тезе ертык джинсы чалбар киеп йөрү башыма сыймый. Кыска чалбар, балтырсыз оекбаш киеп, тубык сөякләрен шәрәләндереп йөргән яшьләргә дә шаккатам. Салкын тидермәсәләр ярый инде, дип борчылып та куям. Нихәл итмәк кирәк, яшьләрнең заман модасыннан артта каласылары килми.

Заманында без дә «клюш» чалбар да кидек, тарларын да, колакларны капларлык итеп, чәч тә үстердек. Без дә яшь идек, без дә мода артыннан кудык. «Спартак» фабрикасы чыгарган очлы башлы туфлиләр безнең өчен «крик моды» иде... Һәм шуның белән шул да бугай. Инде соңрак, чит ил капкалары ачылгач, мода безгә чит-ят илләрдән керә башлады.

Шунысы кызык: «мода» дигән сүз Россиягә XVII гасырларда кереп, XIX гасырга хәтле «обычай» дигән мәгънәдә йөргән. «Мода» сүзе кием-салымга гына кагылмый. Ул – латиннан французларга күчкән сүз, диләр һәм «чара», «үрнәк», «кагыйдә» дигән мәгънәләрне аңлата. Мода – гадәтләр, зәвыклар тупланмасы һәм билгеле бер чорда, билгеле бер вакытта барлыкка килеп, күпчелек тарафыннан таныла, кабул ителә. «Мода» дигәннәре мәдәният-сәнгатькә, гомумән, яшәешебезнең төрле өлкәләренә үтеп керә. Хәтерлим, бала чакта берәр ярамаганрак эш эшләсәк, ялгышрак сүзләр әйтсәк, әти безгә: «Тапкансың мода», – ди торган иде.

Баш миенең кузәнәкләрен киереп, шуны уйлап утырам әле: безнең халык гомер буе күрше тавыгына кызыгып яшәде һәм яши бугай. Европача киенү, француз ислемайлары сибү, сөйләгәндә берәр чит ил сүзе кыстыру – безнең өчен зур мәртәбә! Без бер башка үсеп киткәндәй булабыз. Чит илләр үрнәгендә яшәргә омтылу безнең каныбызга сеңеп, геннар аша киләдәр кебек тоелып китә. Кайчак, нигә бездән дә үрнәк алмыйлар икән, дип гарьләнеп тә куям. Әмма үз-үземә «Үрнәк алырлык нәрсәбез бар соң?» дигән сорау бирәм дә аптырап калам.

Чит илләр безгә карата төрле санкцияләр, ягъни чикләүләр куллана башлагач, телгә «импортозамещение» дигән сүз килеп керде. Аның «импорт» дигәне дә – чит сүз бит әле, латинчадан «читтән кертү» дигән мәгънәне аңлата. Без чикләүләргә рәхмәт тә укып алабыз әле, ниһаять, бөтен нәрсәне үзебез җитештерә башлаячакбыз, дип шатланган булабыз. Әмма «күрше тавыгы»н бик уздырып җибәрә алмыйбыз. Сугыш кораллары җитештерергә шомарып беттек үзе, ә менә башкаларына килгәндә...

Беркөнне телевизордан фармацевтика («фармация» дә – грек сүзе, дарулар турында фән дигәнрәк мәгънәдә) казанышлары, үзебездә чит илнекен алыштырырдай дарулар җитештерелә башлау турында сөйлиләр. Әмма «Европа аналогы» дигән сүзләр дә кыстыралар. Әлбәттә, моның гаебе юк, тик «Россия аналогы» дигән сүзләр дә ишетәсе килә бит. Әлегә бары тик дөнья үрнәгендә яшибез кебек, бу – үзенә күрә бер мода. Иң аянычы: безгә читтән яхшысы да, яманы да керә, сайланып тормыйбыз. Нишлисең, «широкая душа» инде.

Хәзер менә «американча демократия» урнаштыру уе белән дөнья бутый башладылар. Кайбер сәясәтчеләр, Американы бөтен дөньясын берләштереп торучы бердәнбер дәүләт итеп күрәләр, ул булмаса, илләр сугышып, таркалып бетәчәк икән бит! Әтием Солтан исән булса: «Тапкансыз мода», – дип әйтми калмас иде.

Америка үзенең идеологиясен мәңгелек итмәкче. Аңа телəктәшлек итүче дәүләтләр дә юк түгел. Әмма дөнья йөзләрендә бер төрле генә уйлап, бер төрле генә ашап-эчеп, бер төрле генә җырлар җырлап, көйләр көйләп, бер төрле генә киенеп, бер төрле генә йолагадәтләр саклап яшәргә теләүче халык юктыр ул. Дәүләтләрнең генә түгел, хәтта аерым гаиләләрнең дә үз кагыйдәләре, яшәү рәвешләре бар.

Модалар гасырлар буе туа, бетә торган. Үзен дөнья тоткасы санаганнар да мәңгелек түгел. Хәер, дөньяда мәңгелек бер нәрсә дә юк инде ул. Үзенең ничек гомер итәсен дә һәр халык үзе хәл итәчәк.

НИЧЕК АҢЛАТЫРГА СИНЕ, ВАЗГЫЯТЬ?

Сишәмбедән чәршәмбегә каршы төндә бу юлларның авторы йокларга иртә ятты. Көн тыгыз: физик хезмәт белән дә ярыйсы шөгыльләнергә туры килде, күп мәгълүмат эшкәртергә насыйп булды, «Ватсап» һәм «Телеграм» аша контактка керүчеләр дә күп иде. Кыскасы, йөрәк ял сорады. Әмма озак йокларга насыйп булмады, хатын уятты. «Телефонына хәбәр җибәрдек, ачмады, дип әйтәләр», – диде ул.

Польшаның Люблино воеводствосына – Украина чигеннән ерак булмаган төбәккә – ике ракета төшкән икән. Ике кеше үлгән дә. Илнең хәрби һава көчләре Томашув-Любельский аэропортыннан һавага юк итүче очкычларны күтәргәннәр, фаҗига урынына армия һәм прокуратура вәкилләре дә килеп җиткән. Ул арада мәгълүмат агентлыкларыннан: «Америка разведкасы Россия ракеталарының, НАТО составына кергән Польша чиген үтеп, ике кешене үтерүләренраслый», – дигән хәбәрләр ява башлады. Варшава НАТО килешүенең 5 нче статьясын куллануны таләп итәчәк, дигән яңалык та озак көттермәде. 5 нче статья җавап уты ачуны таләп итә, бу инде – Россия белән Төньяк Атлантика блогының сугышы башлану дигән сүз.

Кыскасы, шул хәлләргә бәя бирүне сорыйлар. Иртән телефондагы үземнең җавабымны укыйм: «Сугышырга бик ашыкмаслар, моны ялгышлык дип бәяләп була. Күп булса, украиннарга ярдәмне арттырырлар һәм тизләтерләр. Йоклаган идем, күрмәдем», – дигәнмен. Яңадан күзгә йокы кермәде инде, төнге икенче яртыларга кадәр яңалыклар карап яттым. Россиянең Оборона министрлыгы ракеталарның үзенеке булуын рәсми рәвештә кире какты. Украиннар, моны фейк дип атап, Мәскәүне гаепләделәр һәм үч алырга чакырдылар. Фикерләр күп һәм төрле иде. Пентагон 5 нче статьяны кулланырга чакыручыларны: «Фактлар булмыйча, спекуляция ясамыйбыз», – дип суындырды. Байден хәтта үзе дә ракеталарның Россиянеке булмавы турында фикерне алга сөрә башлады. Поляклар иртәнгә: «Ракеталар Россиянеке (Х-101 ракеталары), әмма аларны кем атуын белмибез», – дип игълан иттеләр. Төнлә Польша Президенты Анджей Дуда Байден белән сөйләште, башка лидерлар белән дә элемтәгә керде. Уртак фикер «хисләрне тыярга» дигән сөземтәгә кайтып калгандыр, күрәсең.

Бу юлларның авторы һич кенә дә өйдә утырган килеш журналист тикшерүе үткәрергә җыенмый. Әле көн туып кына килә һәм вакыйгаларның үсеше ничек буласын әйтеп булмый. Әйе, НАТО килешүенең 4 нче статьясы хәрәкәткә килер, ул статья хәрби блокка кергән илләрнең үзара җыелып киңәшүен генә күз алдында тота. Җавап уты ачылмас, дип уйлыйм. Ракетаның курстан тайпылып читкә очуы – бик мөмкин хәл. 1999 елда НАТО Югославияне ракеталар белән дөмбәсләгәндә, берничә тапкыр Болгариягә тидерде. Эшне зурга җибәрмиләр андый вакытта. Бик яхшы дигәндә гафу үтенәләр һәм компенсация түлиләр. Агымдагы вазгыятьтә НАТО – Россия конфликты килеп чыгу ихтималын кечкенә дип саныйм, нуль бөтен фәлән процент кына. Алдагы язмаларның берсендә без: «Сер итеп кенә әйтәбез: мөселманнар белән яхшы мөнәсәбәттә булганда, НАТО Россия белән туры конфликтка кермәячәк», – дип белдергән идек. Бераз соңрак: «Бөек вакыйгаларның увертюрасы уйнала, Якын Көнчыгышта тектоник үзгәрешләр әзерләнә», – дидек. Россия – Украина конфликтының чишелеше дә шул үзгәрешләргә турыдан-туры бәйле дип уйлыйбыз», – дип язган идек. Бу фаразлар үз көчендә кала. Көнбатыш – Россия конфликтына иртә әле, шулай булгач. Украина кулы белән утлы күмер чүпләп булганда, нигә дип әле көнбатышлылар башларын утлы учакка тыксын?

Вәләкин детективлар остасы Джеймс Хедли Чейзның бер цитатасы бар минем коллекциядә. «Хатын-кызлар – гаҗәп җан ияләре, беркайчан да алардан алдагы минутта ни көтәргә икәнен аңлый алмыйсың, еш кына алар үзләре дә моны белми. Алар кәефләрен кәлтә койрык алыштырганга караганда да ешрак алыштыра», – ди ул. «Хатын-кызлар» дигән сүз урынына «ил лидерлары», «сәясәтчеләр» дигән сүзләрне куегыз, берни дә үзгәрмәячәк. Шуңа күрә вакыйгалар кәлтә койрык алыштырганга караганда тизрәк алышына һәм капма-каршыга үзгәрсә, бер дә гаҗәпләнмәгез. Мин бу юлларны язар алдыннан үткән төндә шулай булды да ул, мөнәсәбәтләр тиз һәм диаметраль каршылыкта үзгәрделәр. Шуңа күрә вазгыятьне аңлап та, аңлатып та булмый.

Хәзер исә мин сезне башка геосәяси ребусны тикшерергә чакырам. Күптән түгел генә Истанбулда булып үткән террор актына күз салабыз. Сүз уңаеннан әйтик: сишәмбедән чәршәмбегә каршы төндә Истанбулда (аның чын исеме шундый) машиналар янды һәм шартлады, ул вакыйганы да террор акты дип тамгалаганнар иде. Иртән генә, техник җитешсезлек сәбәпле, янгын чыгуы мәгълүм булды. Истанбулның Истикләл урамындагы шартлауны искә төшерик әле. Хәзер безгә билгеле инде: аны тумышы белән Сүриядән булган Ахлам Әлбасхыр исемле хатын җибәргән. Сорау алу вакытында ул үзен Көрдстан эшчеләр партиясенең махсус разведкасы офицеры дип атаган. Бу – утка табынучы көрдләрнең сугышчан канаты, алар Төркиянең бер өлеше үзләренеке булырга тиеш дип саный.

goodfon.ru

Ярый, шулай булсын ди. Хәзер нинди генә террорчы агымнар юк, кешеләрне шартлаулар белән шаккатыра алмыйсың. Әмма тикшерүләр йомгагы сүтелә башлагач кына, гаҗәп нәрсәләр өскә калка. Төрек газетасы Yeni Şafak яза менә: «Истанбулда террор акты ясаган хатынны АКШ инструкторлары әзерләде. Аны Сүриянең Кобани шәһәреннән озаттылар, ә әмерне ул Көрд эшчеләр партиясеннән алды». Газетага ни язмаслар, дип әйтер идең, Төркиянең эчке эшләр министры Сөләйман Сойлу: «Әнкара Истанбулдагы терактны кайдан координацияләүләрен белә, шуңа күрә АКШ илчелегенең кайгы уртаклашуын кабул итми», – дип, рәсми рәвештә белдерде һәм «җавап кискен булачак» дип тә өстәде. Министрны еш кына Әрдоганның варисы дип атыйлар. Президент фатихасыннан башка гына белдерүләр ясамас ул. Әмма дипломатияне һәм сәясәтчеләрне аңлау өчен, Балида Байден белән Әрдоганның кул кысышып күрешүләрен һәм күзгә-күз сөйләшүләрен дә истә тотарга кирәк. Әйе, әйе, бәлки, кесәләрдә куллар йодрыклангандыр да, әмма дипломатик этикет саклана барыбер. Дөрес, очрашуның видеоязмасын караучылар: «Байден Әрдоганнан күзләрен яшерә», – дип яздылар язуын, әмма бу аңа Әнкарага F-16 очкычларын вәгъдә итәргә комачауламады.

Истанбул терактына бәйле эш моның белән генә бетми әле. Анда Израиль эзе дә шәйләнә. Ашдодтан килгән ике турист хатынның шартлау алдыннан гына Истикләл урамы буйлап Ахлам Әлбасхыр белән янәшә үтеп китүләрен төшергән видеоязма бар. Социаль челтәрләрдә төрекләр, яшел киемлесен Израиль солдаты, диләр. Алар инде Израильгә китеп өлгергән. Әмма бу фактлар Әрдоганга Израиль лидерларын сайлауда җиңү белән котлап шалтыратырга аз гына да комачауламый. Авраам Линкольнның: «Сәясәтче миңа әти-әнисен үтергән һәм үзенә хөкем карары чыгарганда, ятим булганы өчен кызгануларын үтенгән кешене хәтерләтә», – дигән сүзләрен белмәсәм, вакыйгалар тиләләр йортында бара дип уйлар идем.

«Ни өчен Төркиягә барып төштең әле?» – дип сорарсыз, бәлки. Вакыйгалар күчәрендә Әнкара Мәскәү белән бер орбитада әйләнә. Әрдоган, Балидан торып, Польшага төшкән ракетада Россиянең гаебе юклыгын белдерде. НАТО, 4 нче статьяга буйсынып, консультациягә җыелса, анда ике ил – Төркия һәм Венгрия – Россияне яклап чыгыш ясаячак. Сәясәт сәхнәсе артыннан килгән бер хәбәрдә, яңа террор актларын Төркия, Венгрия һәм Польшада оештырырга җыеналар, дигән сүзләр бар. Аркадаш илләрне чайкалдыру һәм конфликт сызыгын зур итеп үткәрү өчен тырышкан көчләр күп. Гарәп илләрендәниләр баруын без белмибез. Аларны да тынычлыкта калдырмаслар. Болай да Җир шарының бар почмакларында вакыйгалар кайный. Бразилиядә Болсанару яклылар, яңа сайланган Лулаҗның отставкасын таләп итеп, хәрби казармаларга кереп тулдылар. Мантыйкка таянып кына аңлап та, аңлатып та булмый вазгыятьне.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

«АВЫРУ» МӘХӘББӘТ

ШӘФКАТЬ ТУТАШЫ, СӨЙГӘНЕНӘ ЯРЫЙМ ДИП, АҢА ЯШҮСМЕР КЫЗЛАР ТӘКЪДИМ ИТКӘН

Узган атнада башкаладагы гимназияләрнең берсендә булган вакыйга бар халыкны шаккатырды. Балалар сырхауханәсендә эшләүче 38 яшьлек шәфкать туташы яшүсмер кызларга ире белән җенси мөнәсәбәткә керергә тәкъдим иткән. Сәбәбе – сөйгәненә ярарга тырышу. Мәхәббәт уенында катнашырга саф кызлар эзләгән шәфкать туташы. Башка сыймаслык тагын бер факт: беренче итеп ир куенына ул үзенең 14 яшьлек кызын салган, дигән хәбәрләр дә бар.

Шәфкать туташы, сөйгән ярына ярарга тырышып, шәһәрдәге гимназиянең берсендә укучы өч кызны таба. Аларга «зурлар уены»нда катнашкан өчен акча да вәгъдә итә. Билгеле, яшүсмерләр баш тарта.

Ир турында да кайбер мәгълүматлар билгеле. Ул беркайда да эшләми, моңа кадәр мошенниклык һәм ялган документлар кулланганы өчен җавапка тартылганы да булган. Безнең мәгълүматлар буенча 33 яшьлек ир-ат һәм аның белән яшәгән 38 яшьлек хатынга карата Россия Җинаятьләр кодексының ике маддәсе буенча җинаять эше кузгатылган. Тикшерү эше бара. Балаларга психологик ярдәм күрсәтелә.

Инде хәзер адәм баласын мондый юлга нәрсә этәргәне турында уйлап карыйк. Бигрәк тә хатын-кызларны. Бу – җәмгыятькә диагноз куярлык очракмы? Шушы сораулар белән психология фәннәре магистры, психолог Чулпан Нигъмәтҗановага мөрәҗәгать иттек.

Белгеч фикеренчә, мондый акылга сыймаслык гамәлләргә гадәттә психик яктан сәламәт булмаган кешеләр бара. «Психологик тайпылышларның сәбәпләре берничә булырга мөмкин. Әйтик, балачакта алган психик җәрәхәтләр, органик тайпылышлар яисә организмдагы эндоген үзгәрешләр. Мәсәлән, ачык яисә ябык рәвештәге шизофрения», – дип аңлата психолог.

Чулпан Нигъмәтҗанова сүзләренә караганда, рухи яктан хатын-кызларның йомшаграк һәм хисчәнрәк булулары аларны әнә шундый куркыныч адымнар ясарга этәрергә мөмкин. «Алар «корбан» позициясенә тизрәк бирешә. Бу да – организмда булган психологик җәрәхәтләргә нокта куймау, негатив җыелу һәм түбән үзбәянең ачы җимеше», – дип саный белгеч.

Белгеч сүзләренчә, бу гамәлләре белән дөньяны шаулаткан ир-ат һәм хатын-кыз арасында сәламәт мөнәсәбәтләр һәм чын мәхәббәт булган дип әйтергә тел әйләнми.

– Икесендә дә психологик тайпылышлар бар. Ир-ат – тиран-абьюзер, ә хатын-кыз – корбан позициясендәге зат, – ди психолог. – Мондый куркыныч очраклар җәмгыятьнең сәламәт булмавын әйтә. Психологик яктан авырулар, чыннан да, хәзер бик күп. Моның сәбәпләре дә төрле. Әйтик, ил-көндә барган вакыйгалар, күп нәрсәнең рөхсәт ителүе (вседозволенность), мәгълүмат күплеге. Болар барысы да аңга негатив йогынты ясый.

Табиб-педиатр Илдус Лотфуллин исә моны системалы проблема дип атарга ашыкмый. Бу – аерым кешенең саулыгына бәйле куркыныч фаҗига.

– Барлык детальләре дә расланса, чынлап та, коточкыч җинаять инде бу. Ни кызганыч, шәфкать туташы да, табиб та – кеше генә шул. Алар да җинаятьче була ала, – ди ул. – Бу фаҗига балаларның хокукларын саклау системасының никадәр мөһим икәнен кабат исбатлый. Безне никадәр генә ювеналь юстиция (балигъ булмаганнар хокукларын яклау буенча махсуслашкан суд-хокук системасы. – **Авт.**) белән куркытмасыннар, нәкъ менә шундый очракларны булдырмас өчен кирәк тә ул. Бала хокуклары турында сөйли башласалар, һаман саен: «Мультиклар гаепле», «Интернет боза», «Хэллоуин боза», – дип әйтә башлыйлар. Бу кыз баланың фаҗигасендә дә Хэллоуин гаеплемени? Әллә инде вакытында асоциаль гаиләне танып белү системасының начар эшләвендәме гаеп?

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

продеток.рф

Сәяси сәгать

ЖУРНАЛИСТ АЛЬБЕРТ ШАКИРОВ:

«Бу – безнең уртак сынау»

Без әле кая барабыз? Дөньяданиләр бар? Бу сорауларга җавапны журналист, блогер Альберт ШАКИРОВ белән эзлибез.

:: Альберт, махсус хәрби операция әле дә телдән төшми. Соңгы арада сөйләшү, һәрхәлдә, шуңа омтылу турындагы сүзләр синдә дә өмет уятамы?

– Андый сүзләр Россия ягыннан инде яздан бирле әйтелә. Сөйләшү теләге бар, ишекләр бөтенләй ябылмаган. Ләкин моның өчен каршы якның да селкенүе кирәк. Шул ук вакытта бу вакыйгаларда Көнбатышның да мәнфәгатьләре барлыгын оныта алмыйбыз. Кайчан булыр бу сөйләшү дигәннән, шәхсән мин кыш айларына өметләнәм. Ник дигәндә, кыш – актив хәрби хәрәкәт өчен авыррак чор. Икенчедән, теге яктан да тоткыннар белән алмашуны башлау турында сүзләр ишетелә. Шуңа күрә озакка сузылмас дип уйлыйм. Дөрес, Россиянең тышкы эшләр министры Сергей Лавров фикеренчә, Украина Президенты Зеленский куйган шартлар арасында бөтенләй чынга ашырып булмастайлары да бар. Менә алары буенча сатулашу күпмегә барыр бит. Анысы да – мөһим мәсьәлә. Миңа калса, хәзер яклар бер-берсенең нигезен капшый, тел төбен чамаларга тырыша. Бик күп белгечләр кыш айларына өметләнә. Башкача була да алмый. Ике якка да, һич югы көч туплау, ниндидер нәтиҗә ясау өчен булса да, тынлык режимы кирәк булачак. Күпме генә каршы килү, бер-береңнең позицияләре белән бөтенләй килешмәү булса да, чынбарлык, тормыш барыбер үзенекен итә. Бөтен каршылыклар, сугышлар сөйләшү белән тәмамлана.

:: Сөйләшү, килешү димәктән, ноябрьдә Татарстан Президенты катнашында узган ике очрашуга игътибар итми мөмкин түгел. Рөстәм Миңнеханов Бәһрәйндә Рим папасы Франциск белән күреште, ә Казанда Төркия Президентының улы Билал Әрдоганны кабул итте. Боларның безнең өчен нинди әһәмияте бар?

– Дөньяда нинди генә хәлләр булмасын, һәр дәүләт башкаларның йогынтысыннан мөмкин кадәр азат булырга тели. Һәрберсенең үз мәнфәгате бар. Европаның мөстәкыйль сәясәт алып бару омтылышында Төркиянең роле бик зур. Чөнки бүген Төркия Европага ресурслар кертү өчен иң кирәкле каналларның берсе булып тора. Монысы – бер. Икенчедән, бу ил, каршылыклар булса да, башкалар белән араларны бөтенләй өзеп бетермәде. Төркия Президентының улы Казанга килгән икән, бу – бик зур күрсәткеч. Бер яктан, төрки халыклар, икенче яктан, Россиядәге мөселманнар исеменнән Рөстәм Миңнехановның чыгуы, бу юнәлештә аның фикере өстенлек итүе – бик мөһим вакыйга. Рим папасы белән очрашуга килгәндә, беренчедән, Россиядәге мөселманнарның хәлен, икенчедән, гомумән, Россиянең рухи позициясен җиткерүнең шулай ук әһәмияте зур. Бу очрашуның православлар Казан Изге Ана иконасы бәйрәмен билгеләп үткән көннәрдә узуы тагын бер мәгънәгә ия. Бу иконаны католиклар да олылый.

Бу ике вакыйга Татарстанның да, Рөстәм Миңнехановның да дәрәҗәсен раслый. Хәрби, дәүләт дипломатиясе мәсьәләләре буенча сөйләшү – бер хәл, икътисади һәм рухи элемтәләр дә һәрвакыт булырга тиеш. Алар әһәмияте ягыннан башкалардан бер дә калышмый. Ни генә булса да, мөнәсәбәтләрне барыбер яңартырга туры киләчәк. Бу очракта исә безнең милләтнең «татарга тылмач кирәкми» дигән статусы тагын бер мәртәбә раслана. Татар мөселманнарының хәзерге Россиядә дә арадашчы буларак танылуын, милли республикаларның киләчәге ягыннан караганда, уңай сигнал дип кабул итәм.

:: Өлешчә мобилизация халыкны, җәмгыятьне берләштерде, дигән фикер бар. Әмма таркату куркынычы барлыгын да танымый мөмкин түгел. Анысына ничек каршы торырга?

– Җәмгыять таркалмасын өчен, дөрес идеология кирәк. Бездә дәүләтнең рәсми идеологиясе юк. Булырга да тиеш түгел кебек. Ләкин төрле булсак та, рухи яктан бердәмлекне тоярлык кыйммәтләр кирәк. Бүгенге вазгыять барыбызга да йогынты ясый: милләткә дә, яшькә дә, җенескә дә карамый. Бу – безнең уртак сынау. Идеологияне яхшы мәгънәдә әйтсәк, дәүләт, ил, Ватан төшенчәләре калкып чыгарга тиеш. Ватанпәрвәрлек дигәндә, бу төшенчәгә тискәре мәгънә салучылар, «безнең белән түгел икән, димәк, син каршы якта, андыйларны илдән куарга, төрмәгә утыртырга» кебегрәк кискен сүзләр әйтүчеләр дә бар. Бердәм дәүләт икәнлегебезне аңларга кирәк. Әйтик, Европага чыга башлыйсың икән, син – барыбер Россия кешесе инде. Кайсы авылдан, шәҗәрәң буенча кемнәргә барып тоташуыңны сорап тормаячаклар. Барыбызның да хәлләре бер тирә. Димәк, бердәмлек кирәк.

Әйтик, авылда минеке, синеке дигән әйбер юк. Күрше урам егете китсә дә, бөтен халык аны үзенеке итеп озатып кала. Андыйларга ярдәм җыйганда кемдер оештырганны көтеп ятмадылар. Авыл үз кануннары буенча яши. Әлбәттә, анда да борчылалар. Әмма бердәмлек, хәбәрләшеп тору авылны көчлерәк итә.

:: Яңа елга 40 көн чамасы вакыт калып бара. Ничек уйлыйсың, кешедә бәйрәм кәефе булырмы?

– Кәеф җайлап килер инде ул. Гел киеренке хәлдә яшәп булмый. Бертуктамый борчылып, берни үзгәрми. Ахыры депрессия белән тәмамланачак. Һәр кеше үз өлкәсендә эшләргә, куаныч табарга, бәйрәм итә белергә дә тиеш. Яңа елны бит без һәрвакыт өмет белән каршы алабыз. Киләсе ел монысыннан яхшырак булсын, дип телибез. Бераздан шәһәрләрне бизи башларлар, балалар шигырь ятларга тотыныр. Аз булса да киеренкелектән коткарачак бу бизәкләр. Бер атна булса да, башка мәшәкатьләр белән янып алу, башка нәрсәләр турында сөйләшү бик кирәк безгә хәзер. Дәүләт, милләт сәламәт яшәсен өчен, өмет, яхшы кәеф тә кирәк.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Зөһрә
САДЫЙКОВА

ХУҖАҢ КЕМ, АВЫЛ?

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Зөлфия Хәлиуллина

Җир өчен тарткалаш

500ләп кеше теркәлгән Шахмайда алты фермер эшли икән. Һәркайсы диярлек игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнә. Әйтик, Илгиз Галәветдиновның 219 гектар җире бар. Анда ул күпьеллык үлән, арпа, солы һәм житен чәчә. Фермасында үгезләр һәм атлар тота. Тәлгать Гатауллин да үгезләр үрчетү белән шөгыльләнә. 75 гектар җирдә терлек азыгы үстерә.

Бүген күрше-тирәдәге җиде авылда, шул исәптән Шахмайда да, «Агро-основа» җәмгыяте эшли. 1,5 ел элек хуҗалары алышынгач, эш тәртибендә үзгәрешләр башланган. Халык сүзләре буенча, җәмгыять, төрле сәбәпләр табып, халыкка пай җирләрен рәсмиләштерергә рөхсәт бирми. «Авылларда уза торган җыелышларның берсе дә дөрес түгел. Аларда кеше аз катнаша, ләкин документта башкача күрсәтелә», – ди алар.

Фермерлар әйтүенчә, җирне аерым-аерым алу – бик катлаулы эш. Шуңа күрә быел язын бер массивны тулысынча алырга кирәк, дип уйлашканнар.

– Закон таләп иткәнчә, җыелышлар җыйдык, шартларын үтәдек. 284 гектар җирне биш елга арендага алдык, шуның бер өлешенә – без, калган 124 гектарына «Агро-основа» җәмгыяте житен чәчте, чөнки көзен җирне үзләре эшкәрткәннәр иде. «Агро-основа» мәйданында инвесторның үз участоклары да, халыкның пай җирләре дә бар. Безнең мәйданнар күбрәк булганга һәм «Агро-основа» көзен җирне эшкәрткәнгә күрә, халыкка пай җире өчен ашлыкны үзебез түлибез, дидек. Һәм шулай эшләдек тә, – дип аңлатты Тәлгать Гатауллин.

Алда язганыбызча, 124 гектар мәйдандагы җир кишәрлегендә берничә пайчының да җире бар. Алар инвестор белән 11 айлык килешү төзегән булган. Килешү вакыты исә шушы көннәрдә чыга. Тик моңа карамастан, кешеләр җирләрен үзләренә рәсмиләштерә алмый.

– «Агро-основа» җәмгыяте, төрле ысуллар кулланып, әлеге килешү вакытын 3–5 елга кадәр озайтмакчы була. Тик халык каршы. Кемдер үз җирендә үзе эшләмәкче, кемдер фермерларга бирмәкче. Эшебез судка кадәр барып җитте. Район суды халыкның теләгән канәгатьләндерде. Инде декабрь башында Казанда булачак суд утырышын көтәбез, – дип аңлаттылар фермерлар.

Алар фикеренчә, мондый каршылыклар авылларның киләчәгенә балта чаба.

– Заманында, «Вамин» кулына күчкәнче, без районның иң көчле, иң бай хуҗалыгы идек. Үзегез уйлап карагыз: без инде 1973 елда ук газлы булдык. Ә хәзер нәрсә? «Агро-основа»да хуҗалар алышынгач, күршедәге Чертуш авылындагы фермаларны тулысынча сүтеп бетерделәр, Чаллы Башының колхоздан калган биналарын шулай ук җимерделәр. Җимерсәләр җимерәләр, тик фермерларга, халыкка бирмиләр. Элек, колхозлар заманында, бар терлек азыгы колхоздан иде. Колхозлар бетте, халыкка терлегенең тамагын үзенә кайгыртырга калды. Җире дә булмагач, ничек ашатсын ул аны? Әлбәттә, бетерә дә шәһәргә чыгып китә. Шулай итеп, авыл үлә. Заманында мәктәбебез дә бик көчле иде. Хәзер анда дүрт авылдан 70–80ләп бала укый. Гөрләп торган көтүләрне күрәм димә хәзер. Ике зур көтү йөргән болыннарда барлы-юклы бер көтү калды. Инвесторларга халык түгел, аның җирләре генә кирәк, – ди Тәлгать Гатауллин.

Фермерлар сүзләренчә, җирләр буш ятмас, максатчан кулланылыр иде.

– Мин үз пай җирләремне үзем эшкәртәм, ә хуҗалыкта туганнарымныкы бар. Кызганыч, кайберәүләр җирнең чын кыйммәтен аңлап бетерми. Алар бүгенге белән яши. Җир өчен акчаны алып туздырып бетерә дә, шуның белән шул була. Болай барса, киләчәктә халык үзенә дип калдырган җирне дә ала алмаячак, – ди Тәлгать Гатауллин. –Кооператив ачу ихтыяҗын аңлыйбыз, тик аның өчен вакыт кирәк. Безнең авылда алты фермер, күпләп мал тотучылар бар. Ягъни кооперативны оештырыр өчен мөмкинлекләр бар.

Бер уйлаганда, көлке дә шикелле. Җирнең хуҗасы, ягъни авыл агае яки апасы, үз җиренең язмышын хәл итәр өчен, кемнәндер рөхсәт алырга тиеш булып чыгамы? Әле шуның өчен суд юлларын да таптыйсы.

– Шушы җиргә безнең кендек каныбыз тамган, ата-бабаларыбыз биредә гомер иткән. Хуҗалыкның гөрләп торган чагы да, сүнеп барган мәле дә – барысы да безнең күз алдында булды. Безнең гомер шушында узып бара. Монда җир җимертеп эшләдек, моннан соң да тыныч кына эшләргә, гаиләләребезне, авылдашларны эшле, ашлы итәргә телибез. Ни өчен безгә шуны эшләргә рөхсәт бирмиләр? Безнең шуңа да хокукыбыз юкмыни? Шуны гына аңламыйбыз, – дип ачына авыл халкы.

Әлеге вазгыятькә ачыклык кертер өчен, районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Леонид Богомоловка шалтыраттык.

– Декабрьдә пайчылар җыелышы булачак. Анда әлеге мәсьәлә дә күтәреләчәк, җир участокларын бүлү буенча да сөйләшергә исәплиләр. Минем уйлавымча, пай җирен алырга теләүче милекченең зур проблемасы булмаячак. «Агро-основа» берничек тә пайчыларга каршы килә алмый. Җирләргә алар хуҗа. Рөхсәт бирмәү законга каршы килү була, – диде ул.

Идарә башлыгы әйтүенчә, район җитәкчелеге өчен җирдә кем эшләүнең аермасы юк.

– Район өчен иң мөһиме – барлык җирләрнең дә үз максатларында кулланылуы, буш ятмавы, эшкәртелүе һәм пайчыларның лаеклы түләүне вакытында алулары. Ә инде анда эре агрохолдинг эшлиме, фермерлармы – анысында аерма юк, – диде Леонид Богомолов.

> Татарстанда пай җире өчен түләү гектарына 800 сумнан ким булмаска тиеш. Узган ел аренда түләве гектарына уртача 822 сум булган. Быелга түләүләр дәвам итә. Әлегә пай җире өчен иң яхшы аренда түләве түбәндәге хуҗалыкларда: Алексеевск районында Козин фермер хуҗалыгы (гектарына 2000 сум), Яңа Чишмә районында Салаватов фермер хуҗалыгы (2000 сум), Тукай районында «Сәйдәшев исемендәге» оешма (1853 сум), Кукмара районының «Урал» кооперативы (1807 сум), Алексеевск районында Фомин фермер хуҗалыгы (1688 сум).

Киләчәк – фермерларда

Озак еллар шушы җирлектә колхоз рәисе булып эшләгән, хуҗалыкны күтәрүгә үзеннән зур өлеш керткән, Россиянең атказанган агрономы, бүген инде лаеклы ялда булган Гомәр Сөләймановны да күреп сөйләшергә булдык. Авылдашларының хөрмәтен казанып эшләгән һәм яшәгән җитәкченең бу хәлләргә фикерен беләсебез килде.

– Авыллар эш һәм мөмкинлек булмау сәбәпле бетә, дип уйлыйм, – диде ул. – Инвесторлар эшчеләргә аз хезмәт хакы түли. 16 мең сумга кемнең эшлисе килсен? Минем биш еллар элек фермерларга ышанычым юк иде. Хәзер авылның киләчәген аларда күрәм. Эшләргә мөмкинлекләр генә бирелсен иде. Чынлыкта инвесторларга синең авылың да, халкың да кирәкми. Алар бүген җирдән табыш ала да иртәгә китеп бара. Аның урынына башкасы килә. Алар бит җир кешесе түгел. Арышны бодайдан аермый. Технологияләр кулланылмый, кайсы культура күбрәк табыш бирә – берничә ел рәттән бер үк урынга шуны чәчәргә мөмкиннәр. Бүген кырда аларның 2500 гектар житеннәре ята. Кукуруз, көнбагыш белән дә шундый ук хәл. Аларын Сабантуйдан соң чәчтеләр. Июнь уртасында кем ашлык чәчә инде? Аны беренче майдан да соңга калмыйча туфракка урнаштырырга кирәк. Аннан нинди табыш булсын?

Гомәр абый фикеренчә, фермерлар берләшеп эшләсәләр, уңышка тагын да тизрәк һәм җиңелрәк ирешерләр иде.

– Шахмайның 4050 гектар сөрүлек җире бар. Шуның якынча 1500е – фермерларда. Бүген авылның бөтен эшен алар башкара, ә инвесторлардан кадак та алып булмый. Егетләр фермаларны да ышанычлы, озакка җитәрлек итеп төзи. Җирен дә киләчәккә йөз тотып тәрбияли. Фермер егетләргә берләшергә, кооператив булдырырга кирәк. Алга таба фермерларны шул гына коткарып калачак, – дип нәтиҗә чыгарды тәҗрибәле җитәкче.

Шулай да ахырдан без аңа «Гомәр абый, бүген шушы хәлләргә күңелегез әрниме?» дигән сорауны бирдек. Ул исә ирләргә хас тыйнаклык белән елмайды да: «Әрнемичә... Йөрәккә биш ел элек катлаулы операция ясаттым. Берсе дә эзсез узмаган, күрәсең», – диде.

Сорау – җавап

Пай җирләренә кагылышлы сорауларга республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белгечләре ачыклык кертте.

◆Җир милекчеләре нинди хокукларга ия?

– «Авыл хуҗалыгы җирләре әйләнеше турында» федераль закон буенча, җир милекчесе аны арендага бирергә, устав капиталы буларак кертергә, бүләк итәргә һәм мирас итеп калдырырга хокуклы. Җир хуҗасы белән фермер, эре хуҗалык арасында килешү төзелә. Анда уртак бурычлар, җир пае өчен аренда түләве, җирне арендага бирү вакытлары һәм түләү шартлары күрсәтелергә тиеш. Арендага җир милекчесе, җир милекчеләре төркемнәре бирә ала. Кайбер очракларда аренда килешүен пайчының ышанычлы кешесе дә төзи ала. Мондый очракта күпьяклы килешү төзелергә тиеш. Килешү вакыты 11 ай булганда, аны Росреестрда теркәргә кирәкми. Калган очракларда аннан башка булмый.

◆Кеше ике арада төзелгән килешүне вакытыннан алда өзә аламы?

– Таләп итә ала, тик моның өчен хуҗалыкның яки фермерның түләүне билгеләнгән вакыттан ике тапкыр озаккарак сузуы шарт. Моннан тыш, әҗәтен ала алмаучы кеше, үз хокукларын яклап, судка да мөрәҗәгать итә ала.

◆Җирне инвесторларга тапшырганда, нәрсәгә игътибар итәргә кирәк?

– Арендага бирүче аренда түләвенә, түләү вакытларына, килешү шартлары үзгәрүенә, субарендага бирү мөмкинлеге булуга, җирнең ни хәлдә булуын белү өчен аны күзәтеп тору мөмкинлеге булуга игътибар итәргә тиеш. Һәм пай җирләре бары тик билгеләнгән максатларда гына файдаланырга тиеш.

САНАП КЫНА АРТМЫЙ

АКЧАНЫ НИЧЕК САКЛАРГА?

Акчаның артык булган чагы юк инде, диярсез. Анысы билгеле. Тик кулланышта булмаган, маяга калдырган кадәрен (ирекле акча дип атыйк) ишәйтү мөмкинлеге булса, аннан файдаланмый калу да дөрес үк түгел. Пассив керем һәрвакыт кызыктыра.

Хәзерге шартларда артык акчаны кая куярга? Берне биреп, бишне алу өчен нинди ысуллар кулланырга? Бу хакта финанс белгече Ләйсән Халикова белән сөйләштек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Инфляцияне исәпкә ал

Россия банкы фаразы буенча, 2022 елда инфляция күләме 12–13 процентны тәшкил итә. Алга таба бу күрсәткеч кимергә дә мөмкин. Вазгыять көн саен үзгәреп тора бит. Гомумән, акча мәсьәләсендә ниндидер гарантия дә бирерлек түгел. Шуңа да игътибар итәргә кирәк: финанс ягыннан белемнәре сайрак булган кешеләр рәсми инфляциягә генә карап, шуңа ышанып кына нидер хәл итә. Әле бит «реаль инфляция» дигән төшенчә, ягъни чынбарлыктагы саннар да бар. Рәсми күрсәткеч 10–12 булса, чынбарлыктагысы 18–20 процентны тәшкил итә дигән сүз. Без моны үзебездә үк тоябыз. Әйтик, «кулланучы кәрзине» дигән төшенчә бар бит. Аңа кергән товарларның бәясе артуында чагыла ул. 1500 сумга бер төрле продукция сатып ала торган булсак, ярты елдан соң бу акчага бөтенләй башка күләмдә, азрак товар сатып алырга мөмкинбез. Инфляцияне кисәбезгә карап билгелибез.

Банк кертемнәре

Февраль аенда Россия банкы төп ставканы 20 процентка кадәр күтәрде, июньдә исә 9,5 процентка калдырды. Төп ставкага ияреп, кыска вакытлы банк кертемнәренең ставкалары да үзгәреш кичерде.

Хәзерге көндә – 5–6, иң күбе 8 процентка кадәр куелган банк депозитлары бар. Банклар үзләрен дә иминиятләштерә. Әйтик, бер елга түгел, өч-алты айга дигән шарт куялар.

Әгәр ил-көндәге вазгыять һаман да хәзерге кебек дәвам итсә, ставкалар үзгәрмәсә, 7–9 чигендә торса, депозит инфляцияне капламаячак. Әйтик, 100 мең сум акча керттек, ди. Ничәдер сум керем алдык, ди. Ә бит әле «кулланучы кәрзине» бар. Инфляция без өметләнгән керемнән зуррак булачак, кыскасы. Ставкалар рефинанслауга да бәйле. Ул арта икән, депозит та арта, кими икән, шулай ук кими. Кредитлар белән дә – шул ук хәл. Ставка кимесә, кулай шартларда кредит бирелә. Арта икән, кредитның хакы да арта.

Акчаны депозитка куярга куркасыз икән, зур сумма һәм озак вакытка салмагыз. Шунысы да бар: кеше акчасын банкка биргәндә аңласын иде – бу аның артык акчасымы (ирекле акча), әллә инде бар җыелган мөлкәтеме (запас акча)? Беренче чиратта, «финанс мендәре»н булдыруны кайгыртырга кирәк.

Акчаны ничек итеп сакласак та, тормыш-көнкүрешебезнең нинди борылыш алуын белмибез. Ул акчаны теләсә кайсы мизгелдә кулга алырлык итеп сакларга кирәк. Әйтик, банкка 3–6 айга салырга, теләсә кайсы мизгелдә алырлык кертем шартын сайларга.

Җирме, фатирмы?

Бер яктан караганда, «первичка», ягъни яңа төзелешләр бар. Акчаны хәзер үк түлисең, ә фатиры берничә елдан гына төзелеп бетә. Әмма файда янында югалту куркынычы да бар. Төзелеш компаниясе ышанычлы һәм йортны вакытында кулланышка тапшыра икән, керем аласың. Төзи башлаганда фатирлар очсызрак була. Әмма икенче ягы – хәзер киеренке чор. Бар яктан да: төзелеш материаллары, өлешчә мобилизация шаукымы... Фатирларны вакытында төзеп бетерә алырлармы?

Икенчел торак базарын карасак, алар очсызрак. Чит илгә күченеп китеп, монда йортларын калдырган кешеләр дә бар бит. Кешегә арендага биреп торучылар да күп. Бу өйләрне яхшы шартларда сатып алырга мөмкинлек туа.

Әмма киләчәкне фаразлау кыен. Әгәр дә акчаны милек сатып алуга тотарга теләсәгез, берничә кат уйларга тәкъдим итәр идем. Бу акча сезгә кайчан файда-табыш китерәчәк? Ул сезгә кайсы вакытка кирәк? Кемнеңдер, әйтик, балалары бер-ике елдан шәһәргә укырга керә. Алар өчен фатир алып куючылар бар. Кешеләрнең тагын бер категориясе – яшәр урыны булмаучылар. Андыйларга хәзер фатир алырга вакыттыр.

Акция, облигация белән нишләргә?

Кайбер компанияләр облигацияләреннән керем, чыннан да, инфляция күрсәткечен узып китәргә мөмкин. Әмма вазгыять тискәре борылыш алса, компанияләрнең банкротка чыгу куркынычы бар. Димәк, салган акчагыздан колак кагарга да мөмкин дигән сүз.

Дәүләт облигацияләре бу уңайдан ышанычлырак булып санала. Әмма аның кереме бик аз булырга мөмкин. Дефолт булган очракта керем алып булмый.

Акциягә килгәндә, аның белән эш итүчеләр өчен югалту куркынычы зуррак. Акция алганда берәү дә беркемгә дә 100 процент гарантия бирә алмый. Әгәр дә гарантия бирәләр икән, ул чакта андый белгечләрдән котылу ягын карарга кирәк. Теләсә кайсы мизгелдә үсеш тә, түбән тәгәрәү дә булырга мөмкин.

Тотрыксыз чорда, киресенчә, кайберәүләр инвестицияләргә акча сала. Үз чиратымда шундый киңәш бирә алам: бу өлкәдә яңа кеше булсагыз, ашыгып эш итәргә кирәкми. Инвестицияләр кертергә телисез икән, башта белгечләр белән эшләргә кирәк. Сукыр тычкан сыман, «әйдә, ярый» дип, булган акчаны инвестициягә салырга киңәш ителми.

Инвестиция, акция өлкәсенә кереп китәсез икән, шуны аңлагыз: сез бу акчаны югалтырга да әзер булырга тиеш. Теләсә кайсы мизгелдә. Югалтуны җиңелрәк кичерү өчен, бу акчаның бернинди мәгънәгә ия булмавы кирәктер инде. Әмма берәүнең дә артык акчасы юктыр.

Киләчәкне уйлап

Катлаулы икътисади хәлдә үз ихтыяҗларыңны кайгырту турында да онытмаска кирәк. 5–10 еллык максатларны барларга була. «Акчаны кая куярга?» – дип уйласагыз, үзегезгә, балаларыгызга белем алу мөмкинлеген тудырыгыз. Бик файдалы инвестиция бу. Хәзер бу җәһәттән мөмкинлекләр бик күп. Үзегезгә кереме яхшы булыр. Ничек кенә булса да, акчагыз югалмаячак. Чөнки белемегез сезгә акча китерә алачак.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Куркыныч төенчек

Җитәкчеләр күпчелек очракта торак алганда субсидияләр һәм керемнәре турында тулы мәгълүмат бирмичә «яна». Муниципаль хезмәткәрләр арасындагы коррупциягә багышланган матбугат конференциясендә әнә шул хакта билгеле булды. Татарстан Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе оештыру бүлеге мөдире Алексей Панкратов әйтүенчә, ел башыннан муниципаль хезмәткәрләр арасында 16 меңнән артык тикшерү үткәрелгән. Шул вакытта коррупция белән бәйле 231 хокук бозу очрагы ачыкланган. Күпчелеге – 225 кеше – дисциплинар җаваплылыкка тартылган. Әйтик, Әтнә районындагы бер җирлек башлыгы бюджет акчасын үзләштереп тотылган. Җәзаны да каты алган: ирегеннән шартлы рәвештә мәхрүм ителгән. Чүпрәле районында да күңелсез хәл килеп чыккан. Биредә төзелеш һәм архитектура өчен җаваплы баш белгеч шәхси мәнфәгатьләрен өстен куйган. Аның торак төзер өчен субсидия алырга ярдәм итәм дип, халыктан акча соравы ачыкланган. Шулай итеп ул сигез кешене төп башына утыртмакчы булган.

Матбугат очрашуында Лаеш районына аерым игътибар булды. Билгеле булганча, берничә ведомство вәкилләреннән оешкан эксперт комиссиясе әлеге районда коррупциягә бәйле шактый хокук бозу һәм җинаятьләрне ачыклаган. 19 кеше җаваплылыкка тартылган.

– Лаеш районында табигатьне саклау өлкәсендә, керемнәр, милек турында дөрес булмаган мәгълүмат тапшыру, товар кабул итеп алганда тиешле контроль булмау кебек хокук бозулар ачыкланды. Моннан тыш, балаларны мәктәпкә һәм башка белем бирү оешмаларына кабул иткәндә дә хилафлыклар билгеле булды. Белгечләр бу районга аерым игътибар бирергә кирәк дип тапты һәм, районда мондый хәлләр килеп чыкмасын өчен, профилактик чаралар уздырды, – диде Алексей Панкратов.

Әйтик, район башкарма комитетының баш хисапчысы үзенә торак алыр өчен субсидия рәсмиләштергән. Эш урынын җиңел генә файдаланмакчы булган ханымга җинаять эше ачып, штраф түләттергәннәр.

Лаеш районы башлыгы Илдус Зарипов әйтүенчә, районнардагы хокук бозулар башлыча җир һәм яңа торак төзүгә бәйле.

– Әгәр безнең районда бердәм һәм көчле команда булмаса, территорияләрне үстерү һәм анда инвесторлар җәлеп итү бик авыр булыр иде. Район тиз үсә, эшлисе эшләребез күп, – диде ул.

Хәер, белгечләр фикеренчә, халыкның да гаебе бар. Алар, ришвәт биреп, җитәкчеләрне хокук бозуга этәрә. Социологлар мәгълүматлары буенча, Татарстанда яшәүчеләрнең 10 процентының бер тапкыр булса да ришвәтчелек белән очрашканы бар. Шуларның бары тик яртысы гына ришвәт бирүдән баш тарткан.

Алексей Панкратов әйтүенчә, мондый тикшеренүләр республикада 2004 елдан бирле уздырыла. Шул вакыт эчендә коррупциягә бәйле хәлләргә юлыгучы кешеләр саны ике тапкыр кимегән. Моңа, бәлки, даими рәвештә алып бара торган профилактика чаралары да йогынты ясагандыр. Ник дигәндә, бу эшләр муниципаль хезмәткәрләрнең һәркайсы белән алып барыла.

– Без коррупциягә бәйле җинаятьләргә каршы көрәшмибез, алар белән тиешле органнар шөгыльләнә. Безнең бурыч – методик яктан ярдәм итү. Мәсәлән, без съездлар уздырып, тегеләр яки бу проблемалар турында сөйләшәбез һәм аларны чишү юлларын эзлибез, – диде «Татарстан муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясенең юридик бүлеге җитәкчесе Сергей Столяров.

Зөһрә САДЫЙКОВА

21 ноябрь | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.00 «БЕСПОКОЙНЫЙ УЧАСТОК» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК». (Татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
15.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Сибирь» – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
18.00 «Татарлар» 12+
19.00, 20.00, 00.15 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Каравай». Фольклор татар-мишарей 6+
01.05 «Татар теле дәресләре» 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Родная земля» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Мирсәй Әмир турында телеочерк 6+
15.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә...» 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20, 21.25 «ИКЕ АККОШ». Зөһрә Шәрифуллина, Зөлфия Вәлиева. Тормыш һәм мәхәббәт турында 12+
19.20, 22.25, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро» 16+
09.00, 12.00, 15.00, 18.00, 03.00 Новости 16+
09.20 «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45, 03.05 Информационный канал 16+
21.00 «Время» 16+
21.45 «ШИФР» 16+
22.45 «Большая игра» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России» 16+
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время 16+
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести 16+
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «БАРЕНЦЕВО МОРЕ» 16+
22.20 «Вечер с В. Соловьевым» 12+
01.00 «Судьба человека» 12+
03.00 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.15 Новости 16+
06.05, 00.00 Все на Матч! 12+
09.10 Футбол. ЧМ-2022. Катар – Эквадор 0+
11.15 «Оазис футбола» 0+
12.20 Матч! Парад 0+
12.45 «ПЕЛЕ: РОЖДЕНИЕ ЛЕГЕНДЫ» 12+
15.00, 18.00, 21.00 Катар 2022. Все на футбол! 0+
15.45, 01.10 Футбол. ЧМ-2022. Англия – Иран 0+
18.45, 03.15 Футбол. ЧМ-2022. Сенегал – Нидерланды 0+
21.45 Футбол. ЧМ-2022. США – Уэльс 0+
00.45 «Футбол после полуночи» 16+
05.20 Международные соревнования «Игры дружбы-2022». Плавание 0+

НТВ

04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня» 12+
08.25, 10.35 «ЛЕСНИК» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие» 12+
14.00 «Место встречи» 16+
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СПЕЦБАТ» 16+
22.10, 00.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» 16+
00.35 «ПОСЛЕДНИЙ ГЕРОЙ» 16+
02.05 «ЗВЕРОБОЙ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.30, 04.20 «Давай разведемся!» 16+
10.30, 02.40 «Тест на отцовство» 16+
12.40, 01.00 Докудрама «Понять. Простить» 16+
13.40, 23.00 Докудрама «Порча» 16+
14.10, 00.05 Докудрама «Знахарка» 16+
14.45, 00.35 Докудрама «Верну любимого» 16+
15.15 «ДЖИНН» 16+
19.00 «МЕЖДУ СВЕТОМ И ТЕНЬЮ» 16+
01.50 «ВОСТОК – ЗАПАД» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «МИНЫ В ФАРВАТЕРЕ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.45 «РОССИЯ МОЛОДАЯ» 12+
10.45, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.20, 15.05 «СНАЙПЕР. ОРУЖИЕ ВОЗМЕЗДИЯ» 16+
15.00 Военные новости 16+
17.10 Док. фильм «Легенды разведки. Конон Молодый» 16+
18.50 Док. сериал «Битва оружейников» 16+
19.40 Док. сериал «Загадки века» 12+
22.55 «Между тем» 12+
23.25 «ТАСС УПОЛНОМОЧЕН ЗАЯВИТЬ...» 12+
02.55 Док. фильм «Морской дозор» 12+
03.45 Док. сериал «Москва фронту» 16+
04.05 «НОВЫЙ ГОД В НОЯБРЕ» 16+

22 ноябрь | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.00 «БЕСПОКОЙНЫЙ УЧАСТОК» 12+
11.00 «Азбука долголетия» 6+
11.15 Телефильм 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК». (Татар телендә) 16+
13.00 «Родная земля»12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тәмле» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
16.30 «Татарлар» 12+
17.30 «Трибуна «Нового Века» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 6+
21.00 «Соотечественники» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Декан. Памяти Ф.Агзамова посвящается 12+
00.45 «Каравай». Золотые руки мастеров 6+
01.10 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+
05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Таяну ноктасы» 16+
15.30 «Ватандашлар». Гази Заһитов. Исемсез батырлык» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә...» 6+
18.20, 21.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Зөләйха Хисмәтуллина турында телеочерк 6+
19.10, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро» 16+
09.00, 12.00, 15.00, 18.00, 03.00 Новости 16+
09.20 «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45, 03.05 Информационный канал 16+
21.00 «Время» 16+
21.45 «ШИФР» 16+
22.45 «Большая игра» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России» 16+
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время 16+
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести 16+
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «БАРЕНЦЕВО МОРЕ» 16+
22.20 «Вечер с В. Соловьевым» 12+
01.00 «Судьба человека» 12+
03.00 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.15 Новости 16+
06.05, 00.00 Все на Матч! 12+
09.10 Футбол. ЧМ-2022. Сенегал – Нидерланды 0+
11.15 «Оазис футбола» 0+
12.20 Футбол. ЧМ-2022. Обзор 0+
12.45, 01.10 Футбол. ЧМ-2022. Аргентина – Саудовская Аравия 0+
15.00, 18.00, 21.00 Катар 2022. Все на футбол! 0+
15.45, 03.15 Футбол. ЧМ-2022. Дания – Тунис 0+
18.45 Футбол. ЧМ-2022. Мексика – Польша 0+
21.45 Футбол. ЧМ-2022. Франция – Австралия 0+
00.45 «Футбол после полуночи» 16+
05.20 Международные соревнования «Игры дружбы-2022». Плавание 0+

НТВ

04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня» 12+
08.25, 10.35 Т/с «ЛЕСНИК» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие» 12+
14.00 «Место встречи» 16+
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СПЕЦБАТ» 16+
22.10, 00.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» 16+
00.30 «Англия – Россия. Коварство без любви» 16+
01.30 «ПРОФИЛЬ УБИЙЦЫ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55, 04.20 «Давай разведемся!» 16+
09.55, 02.40 «Тест на отцовство» 16+
12.05, 01.00 Докудрама «Понять. Простить» 16+
13.05, 23.05 Докудрама «Порча» 16+
13.35, 00.10 Докудрама «Знахарка» 16+
14.10, 00.35 Докудрама «Верну любимого» 16+
14.45 «ОПЕКУН» 16+
18.45 «Про здоровье» 16+
19.00 «ЗАВТРА Я ТЕБЯ РАЗЛЮБЛЮ» 16+
01.50 «ВОСТОК – ЗАПАД» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «НОВЫЙ ГОД В НОЯБРЕ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.50 «РОССИЯ МОЛОДАЯ». «МУЖАНИЕ» 12+
10.45, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.20, 15.05 «СМЕРШ» 16+
15.00 Военные новости 16+
17.30 Док. сериал «Москва фронту» 16+
18.50 Док. сериал «Битва оружейников» 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» 12+
23.25 «ТАСС УПОЛНОМОЧЕН ЗАЯВИТЬ...» 12+
02.55 «ДЕВУШКА С ХАРАКТЕРОМ» 12+
04.25 Док. фильм «Звездный отряд» 12+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 21–27 НОЯБРЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Максатларны барлау: ирешелмәстәйләрен яки кызыксызга әйләнгәннәрен онытып, яңаларын алдыгызга кую чоры. Үзгәрешләр кирәк. Ял көннәрендә әйбәт хәбәрләр көтегез.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Шактый ук киеренке, ыгы-зыгылы атна. Бик күп йөрергә-йөгерергә, хәтта кыска вакытлы сәфәргә дә чыгып керергә туры килер. Серләрегезне беркемгә дә ачып салмагыз.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Зур гына проблемаларыгызны бөтенләйгә онытыру өчен бик уңайлы сәбәп чыгар. Хыялларыгыз тормышка ашар. Моның өчен язмышыгыз барысын да үзе хәл итеп куяр.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Офыкта матди хәлегезне шактый ук җиңеләйтү мөмкинлеге шәйләнер. Атна ахырында сәеррәк кенә хәбәрләр ишетеп, бераз уйга калырсыз бугай.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Эшләрегез авыррак, әмма дөрес юлдан барыр. Үз көчегезгә генә түгел, иртәгәсе көнгә дә ышанычны арттырырдай хәлләр булып алыр. Бер хезмәттәшегез шәп яңалыклар белән куандырыр.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Тормышыгызның җиңеләюен сизеп сөенерсез. Күп кенә проблемаларыгыз чигенәчәк. Яңа танышыгызның бик вакытлы киңәше күңелсезлектән коткарып калачак.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Атна башында өстәмә мәшәкатьләр килеп чыгу сәбәпле, планнарыгызны үзгәртергә туры килер. Ләкин бу файдага гына булыр: акчагыз янга калыр. Күптәнге танышыгызны очрату күңелегезне алгысытып җибәрер.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Шактый ук катлаулы бурычларның очына чыгарга туры килер. Җиң сызганып эшләүне, яшен тизлегендә тегее яки бу карарга килүне таләп иткән чор. Ләкин хафаланасы юк: барысын да бик яхшы башкарып, булдыклы булуыгызга үзегез үк сокланып туя алмассыз.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Тормышыгызга билгеле бер йомгак ясау чоры. Әйтергә кирәк, әйбәт йомгак! Тегеннән-моннан эшлекле тәкъдимнәр ява башлар. Кайсын сайлап алырга белмичә аптырап йөргәндә, хезмәттәшегез үтә акыллы киңәше белән ярдәмгә килер.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Эштәге мәшәкатьләр бөтен вакытыгызны алыр. Аның карабы акчасы да әйбәт булыр. Тирәгездәгеләр үзегездән көнләшүне туктатып, киресенчә, әкренләп сокланa башлар. Сокланырлык та шул...

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Атна башында чын мәгънәсендә эшкә күмелеп калырсыз. Куркасы юк: сезгә канәгатьлек һәм әйбәт премиягә өметләнү хисләре генә китерәчәк бу. Уй-ниятләрегезне сер итеп саклап тотыгыз: күз тидерүләре бар.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Бу атнада ашыгырга, артык хәрәкәтләр ясарга кирәкми. Ыгы-зыгы арытачак кына! Тынычлык, сабырлык дөрес карарлар алып килер.

Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре вазыйфаларына кандидатларны алдан сайлап алу турында хәбәр

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы «Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» 2003 елның 11 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре вазыйфаларына кандидатларны алдан сайлап алу башлануы турында хәбәр итә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2003 елның 20 февралендәге 1898 номерлы карары (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2007 елның 28 сентябрендәге 3102-III ДС номерлы карары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары вазыйфаларына кандидатларны алдан сайлап алу тәртибе турында нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән тиешле документлар әлеге хәбәр басылып чыкканнан соң унбиш көн эчендә түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420060, Казан ш., Ирек мәйданы, 1 нче йорт, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты.

ӘНИ БУЛУ КОТКАРА

Күкрәк яман шеше әлеге зәхмәтле чирнең иң киң таралган төрләре бишлегенә керә. Ел саен дөньяда күкрәк яман шешенең 1,3 миллион яңа очрагы ачыклана. Бу яман чирдән саклану өчен, нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк? Бала имезү күкрәк яман шешен кисәтәме?

Әлеге четерекле сорауларга табиб онколог-маммолог Айгөл ХАҖИЕВА җавап бирде.

shutterstock.com

:: Айгөл Радиковна, хатын-кызлар сезгә, гадәттә, йөкле вакытта яки бала тапкач кына күренә. Чынлыкта маммологта ничә яшьтән тикшерелә башларга кирәк?

– Күкрәк бизләрен алар барлыкка килә башлауга ук даими рәвештә тикшертеп торырга кирәк. Бу эш белән иң беренче чиратта табиб-гинеколог шөгыльләнә. Консультация вакытында ул күкрәк бизләрен дә тикшерергә тиеш. Әгәр ул берәр хилафлык тапса, маммологка җибәрәчәк. 40 яшьтән узган хатын-кызлар маммографияне – ике елга бер, 50 яшьтән соң ел саен узарга тиеш. Әлеге төр тикшеренүне, иң беренче чиратта, күкрәк бизе составында май катламы күбрәк булган гүзәл затларга үтәргә кирәк. Ник дигәндә, май рентген нурларын бик яхшы үткәрә. Башлангыч чордагы күкрәк яман шеше дә еш кына нәкъ менә шунда күренә. Яшь кызлар исә маммография урынына УЗИ уза. Нәселендә күкрәк, күкәйлек яман шешеннән интеккән кешеләр булган гүзәл затлар маммографияне 35–37 яшьтән үтә башлый. Күкрәкнең торышын айга бер мәртәбә үзлегеннән дә тикшерергә кирәк. Әгәр күрем сәгать кебек, вакытында килә икән, аны циклның 5–12 көннәрендә башкарырга кирәк. Күкрәк борчымаса, елга бер тапкыр күкрәк бизләренә УЗИ ясатып, маммологка күренү дә җитә. Менопауза чорына кергән хатын-кызлар күкрәкне үзлегеннән айның теләсә кайсы көнендә тикшерә ала.

:: Күкрәкне үзлегеңнән тикшергәндә нинди билгеләр сагайтырга тиеш?

– Әгәр караңгы коңгырт, алсу төстәге сәер бүлендекләр күренсә, кичекмәстән табибка күренергә кирәк. Бу – күкрәктә ниндидер начар процесслар башланып килә дигән сүз. Тотып караганда тыгызланып торган, шешле урыннар сизелсә дә, табибка барырга кирәк. Имчәк башлары чиста, алсу төстә булырга тиеш. Аларның кытыршы булуы, кызарып торуы куркыныч. Бу очракта да кичекмәстән табибка күренергә кирәк.

:: Күкрәкнең зурлыгы белән аның сәламәтлеге арасында бәйләнеш бармы?

– Юк, күкрәкнең ни дәрәҗәдә сәламәт булуы аның зурлыгына һич кенә дә бәйле түгел.

:: Бюстгальтер кию күкрәкләргә зыянлы дигәнне дә ишетергә туры килә...

– Әгәр бюстгальтер дөрес сайланмаган, кечерәк икән, ул сөт бизләрендәге кан әйләнешен бозарга мөмкин. Нәтиҗәдә, сөт бизләре шешә. Күкрәк турысында авырту сизелә.

:: Халык арасында киң таралган тагын бер фикергә дә ачыклык кертеп китегезче. Бала имезү яман шешне кисәтергә ярдәм итәме?

– Бу, дөрестән дә, шулай. Бала имезү яман шеш килеп чыгу куркынычын бермә-бер киметә. Сабыен имезгән хатын-кызның күкрәгенә ачылган роза чәчәге белән чагыштырырга мөмкин. Ул күкрәктә булырга тиешле барлык үзгәрешләрне кичергән. Имезмәүче хатын-кызның күкрәге исә, киресенчә, ачылмаган роза чәчәге сыман. Ул гомер буе шундый кыяфәттә дә саклана ала. Шул ук вакытта башка гормоннар йогынтысында «ачылып», анда тискәре үзгәрешләр дә башланырга мөмкин.

:: Пластик операция ясату аркасында, күкрәктә яман шеш пәйда була аламы? Имплант куйдыргач, имезергә ярыймы?

– Юк, күкрәкне имплант ярдәмендә зурайту күкрәк яман шеше пәйда булуга берничек тә йогынты ясамый. Әмма аларны куйдыргач, канда үзгәрешләр (лимфома) башланырга мөмкин. Ләкин бу бик сирәк очракта гына күзәтелә. Мондый операция ясар алдыннан табиб аның тискәре йогынтысы турында кисәтергә тиеш. Имплант белән бала имезеп булу-булмау аның кайда урнашуына бәйле. Ул мускул астына урнаштырылган очракта бала имезеп була әле. Имплант тире астына куелган икән, имезергә ярамый.

:: Баланы күкрәктән аергач, күп кенә хатын-кызлар, күкрәкнең формасын матурлау өчен, имплантларсыз гына операция ясата. Ул куркынычсызрак дигән фикер яши. Бу шулаймы?

– Һәр операциянең уңай һәм тискәре яклары була. Болар бар да индивидуаль рәвештә хәл ителә.

КҮКРӘКНЕҢ СӘЛАМӘТЛЕГЕН САКЛАУ ӨЧЕН ТАБИБ КИҢӘШЛӘРЕ

➤Һәрчак хәрәкәттә булыгыз, спорт белән шөгыльләнегез.
➤Гәүдә авырлыгын контрольдә тотыгыз. Ник дигәндә, симерү күкрәк яман шеше китереп чыгарган сәбәпләр рәтендә беренче урында тора.
➤Исерткеч эчемлекләр кулланы, тәмәке тарту кебек начар гадәтләр дә күкрәкләргә тискәре йогынты ясый.
➤Табиб белән киңәшләшмичә контрацептик чаралар куллану да зыянлы. Күкрәктә үзгәрешләр булганда алар бөтенләй кулланылмаска яки башка төргә алыштырылырга тиеш.
➤Сабыйга ким дигәндә ике яшькә кадәр күкрәк сөте имезү дә күкрәкләрне сәламәт килеш сакларга ярдәм итә.

Үкчә тиресен йомшартабыз

✓1 стакан сыек сабынга яки гельгә тоз салып бутагыз да суны табакка салыгыз. Аякларны шунда ярты сәгать тотарга кирәк.
✓1 табак суга 1–2 аш кашыгы алма серкәсе яки лимон кислотасы салыгыз. Аякларны бу катнашмага 10–15 минутка тыгып торыгыз.
✓5әр кашык ромашка, шалфей, 3 кашык сары мәтрүшкәне бергә кушып бутагыз да шуңа 1,5 литр кайнап торган су өстәгез. 10 минуттан катнашманы кайнар су салынган табакка бушатыгыз. Аякларны шунда 20–30 минут тотыгыз.
Мондый процедуралардан соң үкчә тиресен махсус щетка яки пемза белән ышкып, скраб белән дә чистартырга онытмагыз.
✓Скрабны үзең дә ясарга мөмкин. Моның өчен әфлисун кабыгын ваклап, зәйтүн мае өстәп болгатыгыз да үкчәләргә сөртегез. 20 минуттан юып төшергәч, үкчә тиресенең йомшарып, чистарып калганын күрерсез.

Исеңдә тот!

УЙЛАП КАБАСЫ

Йокларга ятарга ике сәгать кала ашарга ярамаганлыкны һәркем белә. Әмма табиблар кичке якта ашаган ризыкка да игътибар итәргә куша. Йоклар алдыннан нәрсә ашарга ярый, ә кайсы ризыктан тыелып тору хәерле соң?

★Аксымга бай ризыклар озак үзләштерелә. Шуңа күрә кичтән аксымлы ризык ашап ятсагыз, иртән үзегезне начар хис итүегез бар.
★Организм кич һәм төнлә ял итәргә, үз халәтенә кайтырга тиеш. Шуңа күрә йоклар алдыннан майлы, кыздырылган, ысланган ризык ашаудан тыелып торырга кирәк.
★Җиләкләр, эчәклектә әчеп, эчне күпертергә мөмкин.
★Йоклар алдыннан эчегән сөт ризыкларын да кулланмаска кирәк. Алар ашказаны асты бизен инсулин эшләп чыгарырга мәҗбүр итә. Монысы, үз чиратында, организмда май запаслары барлыкка килүгә китерә.

vk.com

Файдалы киңәш

Кыяр кәефне күтәрә

Кәефегез төшсә, кыяр ашагыз, ди белгечләр. Ник дигәндә, анда серотонин дигән бәхет гормоны бар. Шуңа күрә бу яшелчәне кәеф төшкәндә, арыганда һәм депрессия вакытында ашарга киңәш ителә.

•Кыяр ябыгырга, шешенүдән котылырга, тиренең торышын яхшыртырга теләгән кешеләргә дә файдалы.
•Кыяр организмны чистарта, ашкайнату системасы эшен яхшырта, целлюлиттан котылырга ярдәм итә.
•Бу яшелчә 95 процент судан тора, калган биш процентын клетчатка тәшкил итә. Кыяр шулай ук май барлыкка килүгә комачаулый торган тартрон кислотасына да бай.
•Кыярны чистартмыйча гына ашагыз. Аның кабыгында K, A, C һәм B төркеменә керүче витаминнар, шулай ук тимер, калий, фосфор, бакыр һәм магний минераллары бар.

pixabay.com

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

ТҮШӘМЕҢ МАТУР, КЕМНӘР КУЙГАН?

Арзан, тиз әзер була, матур һәм чыдам. Бүген сүзебез популярлык казанган, хәйраннан кулланылышка керсә дә, әле модадан чыгарга җыенмаган тарттырылган түшәмнәр турында барачак. Аны сайлау серләрен безгә Рөстәм Гафаров чишә.

Мондый түшәмнәр тонык (матовый), ялтыравык (глянец), тукыма, пленка, бер тонда һәм рәсем төшерелгән була. Фантазияңне эшкә җиксәң, әллә ниләр уйлап табарга була. Артык акча чыгармас һәм сайлаганнан соң кәефең кырылмасын өчен, кайбер нәрсәләрне истә тотарга кирәк.

Тукыма яки поливинилхлоридтан ясалган юка һәм нык җаймәне тарттырып ясалган түшәм. Ул алдан алынган үлчәм буенча киселгән җаймәне каркасларга тарттырып куюдан гыйбарәт. Мондый түшәм бик тигез һәм тиз эшләнә.

Өстенлекләре

1 Эшләү өчен бик аз вакыт таләп ителә. Тигез түшәм тарттыру өчен 2–3 сәгать, берничә төрле дәрәҗәдәге биеклектәгеләрен эшләү өчен 5–6 сәгать вакыт үтәргә мөмкин.

2 Түшәмне куйганда юеш әйберләр кулланмаганлыктан, аны ремонт ясаганчы гына түгел, ә ремонт ясап бетергәч яки өйдә бераз үзгәрешләр кертергә уйлап яңартканда да кулланырга була.

3 Аны кую өчен түшәмне махсус тигезләргә яки әзерләргә кирәк түгел. Ул, киресенчә, өслектәге кимчелекләрне каплаячак.

4 Ут кабельләрен, су торбаларын яшерү өчен дә менә дигән.

5 Сәламәтлек өчен зыянсыз.

6 Бик озак хезмәт итә.

7 Чистарту һәм карап торуның бер мәшәкате дә юк.

Кимчелекләре

Мондый түшәмнең шулай ук үз кимчелекләре бар. Бердән, бәясе бөтенләй үк арзан дип әйтеп булмый. Чөнки түшәмгә обой ябыштыру арзангарак чыгарга мөмкин. Икенче кимчелеге – бүлмәнең биеклеген киметә, чөнки ул 5–10 см түбәнрәк төшереп ясала.

vk.com

Кайсын сайларга?

Тарттырылган түшәм тукыма һәм поливинилхлорид (ПВХ) була. Алар икесе дә үзенчә яхшы, тукымадан ясалганының бәясе кыйммәтрәк.

ПВХ түшәмне икенче төрле пленкасыман дип йөртәләр. Алар тукымага караганда популяррак. Ул арзанрак булудан тыш, судан курыкмавы белән дә алдыра. Шунлыктан аны аш һәм юыну бүлмәләрендә кулланырга була. Шулай ук өстәге күршеләрегез су агызган очракта да коткарып калачак. Чөнки пленка суны тота. Ә су белән асылынып төшкән пленканы түшәм куючылар тиз генә элеккеге рәвешенә кайтара алачак. ПВХ түшәм тонык, ялтырап торган һәм сатин була. Төслене сайлаганда исә аңа буяу тукыма түшәмгә караганда яхшырак ятачак, төсе җетерәк булачак. Сыйфатлысын сайлаганда, пленка түшәмнең сәламәтлек өчен бер зыяны да, исе дә юк. Озак вакыттан соң түшәм бераз асылынып тора башласа, аны элеккеге хәленә бик җиңел кайтарып була.

Мондый түшәмнәрнең киңлеге 5 метрга кадәр була, шунлыктан җөйләрсез дә түшәм ясау мөмкинлеге бирә. Чистартуга килгәндә, җылы суда чылатылган чүпрәк белән сөртеп алырга киңәш ителә. Составында спирт булган чистарткычлар кулланырга ярамый. ПВХ түшәмнәрне җылы пушка ярдәмендә куялар, ә тукыма түшәм ясаганда салкын ысул кулланыла.

Тукыма түшәмгә килгәндә, аның сәламәтлек өчен зыяны юк, һаваны бик яхшы үткәрә. Аның киңлеге 5 метрдан да артык булырга мөмкин. Ул зур мәйданлы түшәмнәрне җөйсез эшләү мөмкинлеге бирә. Аның ярдәмендә катлаулы түшәмнәр ясап була. Тукыма түшәмнәрне буярга мөмкин. Теләсә нинди төстәге акрил буяу белән түшәмне буяп, интерьерны тиз генә үзгәртергә була. ПВХдан аермалы буларак ул салкын температурадан курыкмый, шунлыктан җылытылмый торган биналарга да куярга мөмкин.

Тик тукыма түшәмне чистарту ПВХга караганда кыенрак. Шунлыктан аны аш бүлмәсенә куймавыгыз хәерле. Авыр булганлыктан, бераз вакыттан соң салынып төшәргә мөмкин. Тукыма түшәмне буяганда аңа буяу пленканыкы төсле җете булып ятмый. Ә бәясенә килгәндә ул кыйммәтрәк, әмма бик затлы күренә.

Тәмле булсын!

ИПИ ПЕШЕРУ

Мәрьям Миннегулова рецепты

Ипи камыры басасы савытыбызга 1,5 чәй кашыгы чүпрә (минеке коры чүпрә), 1 аш кашыгы шикәр комы, 1 чәй кашыгы тоз, 1 стакан җылымса су салып болгатабыз да, шуңа ярты стакан иләнгән он салып, әче камыр ясап, җылы урынга каплап куябыз.

Чүпрәбез яхшы булса, ярты сәгать дигәндә камырыбыз әчеп чыгачак. Әче камырга ярты стакан җылымса су салып болгатабыз, он кушып, яңадан басабыз. Камырыбыз үзләнгәнче басарга кирәк. Кулга көнбагыш мае (2 аш кашыгы тирәсе) салып, камырны яхшылап басып бетереп, өстен каплап, янадан кабартабыз. Кабарган камырны майланган табага салып, янәдән табада кабартабыз да, 200 градуска кадәр җылытылган мичтә пешерәбез.

УЫЛДЫК ТОЗЛАУ

Рәмзия Әхмәдуллина рецепты

Хәзер горбуша балыгының уылдыклы вакыты. Сатып алганда балыкның кечерәк башлысын, түгәрәгрәк борынлысын сайларга кирәк. Ана балык шулай аерыла, диләр балык сатучылар.

Балыктан уылдыкны алгач, салкын су белән яхшылап юабыз. Элпәләреннән аерып чистартабыз, аннары пыяла банкага салабыз. Өстенә бераз тоз, лимон согы салып болгатабыз. Сыектча 12 сәгать торганнан соң әзер була. Эре бөртекле, аз гына тозлырак уылдык бик тәмле килеп чыга. Сатып алган банкалы уылдык белән чагыштыра торган да түгел.

Белеп тор!

Чәй чүбен ташлама

Пакетлы чәй эчкәннән соң, аны чүп дип ташларга ашыкма. Көн буе компьютер каршында утырып күзләрегез арыганда, әлеге пакетларны күзләрегезгә куеп торыгыз. Ул күзләрне ял иттерә, вак җыерчыкларны бетерә. Әлеге ысулны еш кулланасагыз, файдасын күрми калмассыз. Шулай ук тәндәге күгәргән, кояш ялкынсындырган урыннарга да чәй пакетларын куеп торсагыз, файдасын күрми калмассыз.

Укучы киңәше

Җылы чакта чистартырга кирәк

Авылларда каз өмәләре гөрли. Мин үзем каз йолкуны бик яратам. Эш ансат барсын дисәгез, суйганнан соң казны 3–4 сәгать эчендә чистартырга тырышыгыз. Чөнки суынып беткәч, йолку кыенрак булачак һәм тиресе дә йолкынырга мөмкин. Гадәттә коры ысул белән чистартканда канат очларын чистарту кыенрак, әмма суынганчы эшләгәндә бер кыенлыгы да юк.

Ә юеш ысул белән йолкыганда казларны 80 градуслы суга тыгып алып чистартабыз. Яхшырак чистарсын дип, аны озак тотарга тырышмагыз, киресенчә, пешеп, чистарту бөтенләй кыенлашырга, түшкәсе ямьсезләнергә мөмкин.

Гөлсинә ЯРУЛЛИНА.
Арча

Матур бул!

КЛЕОПАТРА ВАННАСЫ

1 литр кайнаган сөткә 100 г бал салып эретәбез. Ул суынганчы тәнгә түгәрәк хәрәкәтләр ясап, 150 г каймак белән 150 г тоз салып ясалган катнашманы сөртәбез. 15–20 минут торганнан соң аны душта юып төшерәбез. Ваннага су тутырып, аңа алдан әзерләнгән сөтле катнашманы салып, 20–25 минут ятып торабыз. Тән яшәреп, сафланып китәчәк.

САВАБЫ ИЛЛЕ ТАПКЫРЛЫК

Намаз – Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте, бик зур бүләге. Адәм баласының күңеленә рәхәтлек бирә, җанына тынычлык индерә торган изге гамәлләрнең берсе дә ул. Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә пәйгамбәрлек иңгәнче, ул Исмәгыйль галәйһи вә сәлләм заманыннан килгән рәвештә намаз укыган, Кәгъбәтулла янына барып, гыйбадәт кылган.

«Рөстәм» мәчете имам-хатыйбы Исмәгыйль хәзрәт БИККИНИН белән намаз уку тәртибе, аның асылы турында сөйләштек.

– Мөэмин-мөселманның тормышында намаз – Аллаһы белән элемтә. Баштарак мөселманга 50 тапкыр намаз уку фарыз була. Ләкин ул, Аллаһы Тәгалә тарафыннан җиңеләйтелеп, пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм догасы аша биш вакытка калдырыла. Шул рәвешле мөселман көнгә биш тапкыр намаз укый, моның өчен исә 50 тапкыр намаз укыган шикелле әҗер-савап ала. Мөселман өчен намаз уку Аллаһ каршында: «Мин сине истә тотам, Я, Раббым, күңелем белән генә түгел, әле тәнем белән дә», – диюгә тиң. Кыямәт көнендә кешедән иң элек бу дөньяда укыган намазлары соралачак. Намаз – кешенең яшәү рәвеше. Намаз укыган кешенең күңеле, тәне генә түгел, намаз укыган җире дә, киеме дә чиста, ризыгы хәләл булырга тиеш. Намаз кешеләрне үзара берләштерә, җәмгыять белән элемтәдә торырга ярдәм итә.

:: Уразаны башында, уртасында һәм ахырында өчәр көн тотсаң да, җитә, намазны да күңелем кайчан тели, шунда укыйм, дип әйтүчеләр бар. Болай укыган намаз кабул буламы?

– Кеше шулай өчәр көн ураза тотарга мөмкин. Әмма утыз көнлек җаваплылык барыбер аның өстендә кала. Калган көннәр өчен казасын кылырга кирәк. Намаз укуга килгәндә, әгәр кеше вакытында намазны укымаса, яки биш вакыт намазны укымыйча, иртәнге, ястү намазларын гына укыса, атнасына бер тапкыр гына намаз укыса, калган намазлар аның өстендә бурыч булып кала. Киләчәктә ул аларны каза кылып кайтарырга тиеш. Әгәр кеше көнгә, атнага бер тапкыр гына, елга ике мәртәбә гает намазын гына үтәсә, кабул буламы? Әлбәттә, кабул була. Һәр изгелек үзенең урынына карата. Бер яктан үз өстеннән җаваплылыкны төшерә. Икенче яктан Аллаһы Тәгаләнең әҗер-савабына ирешә. Кеше намаз укымаса, әмма Аллаһы Тәгаләгә ышанса, сәдака бирсә, алар да кабул була. Фәкать бер шарт бар – ул намазны инкарь итәргә тиеш түгел.

:: Намаз укыганда буталсаң, ни эшләргә?

– Намаз укыганда буталу төрлечә булырга мөмкин. Кайчак гыйбадәт кылганда башка дөнья фикерләре кереп китә. Андый чакта пәйгамбәребез: «Әгузү билләһи минәш-шәйтанир-рәҗиим», – дияргә киңәш итә. Намазның кайсы өлешендә буталуыңа карамастан шулай дип әйтеп куйсаң, шушы фикер ерагая. Укыган сүрәнең аятьләренә игътибар итеп уку да буталулардан коткара. Намаз укыганда рәкәгатьләрнең санын онытып җибәрергә мөмкин. Андый чакта азрак санны алырга кирәк. Намазның фарыз өлешләре төшеп калган икән, яңадан кайтып, шушы намазны укыйсың. Юкса, намаз юкка чыгачак. Намазга басканда тәкбирне онытып калдырсак, бу очракта да, кире кайтып, тәкбирне әйтергә туры киләчәк.

:: Биш вакыт намазны барысын бергә казага калдырып уку дөресме?

– Нинди генә очрак булмасын, төшереп калдырган намазны казага калдырып укырга була. Биш вакыт намазыңны көн азагында казага калдырып булса да укысаң укы, Аллаһы Тәгалә каршында булган бурычыңны төшер. Әмма бу эш белән мавыгырга ярамый. Көнебезне намазларны вакытында укырлык итеп планлаштырырга кирәк.

:: Бер хәдистә: «Мисвак кулланып укылган намаз мисвак кулланмыйча укылган намазга караганда 70 тапкыр яхшырак», – дигән юллар бар...

– Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Әгәр минем өммәтемә авырлык китермәсә, мин намаз алдыннан мисвак куллануны йөкләмә итеп куяр идем», – ди. Икенче бер хәдисендә ул мисвакны тән чисталыгы белән

vk.com

бәррәттән куя. Мисвакның асылы гарәп якларында үсә торган шушы үсемлек тамырын куллану гына түгел, авызыбызны, тамагыбызны, тешләребезне чиста тотудан гыйбарәт. Аны куллану пәйгамбәребез сөннәтен зурлау санала. Ләкин заманча теш чистарту ысулларын файдалансак та, мисвак хисабыннан китә.

:: Сәфәр вакытында намаз ничек укылырга тиеш?

– Безнең Әбу Хәнифә мәзһәбе буенча сәфәрдә барлык биш вакыт намаз вакытында үтәлә һәм алар бер-берсе белән кушылмый. Калган мәзһәбләрдә өйлә белән икендене, ахшам белән ястүне кушу рөхсәт ителә. Сәфәр вакытында намазларның фарыз өлеше кыскартыла. Өйлә, икенде, ястү намазларының дүрт рәкәгате ике рәкәгать итеп укыла. Иртәнге, ахшам намазлары исә барысы да үзенең санында кала. Сәфәр вакытында сөннәт намазлары да укыла. Алар фарыз өлешкә керми. Әгәр без сәфәрдә туктый алмасак, тулысынча басып намаз укырга мөмкинлек булмаса, ул вакытта кешенең тәһарәте булырга тиеш. Су юк икән, аны туфрак белән дә алырга мөмкин. Транспорт кайсы якка бара, шул якка карап, машинада утырган килеш укыйбыз. Сәфәрдә чакта намазны рульдә дә укырга рөхсәт ителә. Туктарга мөмкинлек булса, ул чакта намазны тиешенчә укырга да мөмкин.

:: Ни өчен намаз укыган кешенең алдыннан узып китәргә ярамый?

– Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Әгәр бер кеше намаз укыса, сезгә аның каршыннан узу тыелган. Аның укып бетергәнен 40 ел көтеп торсагыз да, ул сезгә хәерлерәк», – ди. Ник дигәндә, намазның хөрмәте бар. Кеше шул вакытта барча күңеле белән Аллаһка юнәлеп дога укый. Икенче бер хәдистә: «Намаз укыган кеше Аллаһы Тәгаләнең йөзенә карый», – диелә. Ягъни кеше белән Аллаһы Тәгалә арасында үзенә күрә бер элемтә урнаша. Шуңа күрә кеше намаз укыган вакытта белә торып аның каршыннан үтеп китү шушы гыйбадәтне санламау дип атала. Кеше моны ялгышлык белән эшләсә, бу ялгышы кичерелә. Әгәр кеше намаз укучыны күрмичә, каршыннан узып китсә, җайлап кына кулыңны алга куеп, кешене кисәтәсең. Намаз укыганны кеше күрсен өчен, каршыңа берәр әйбер куярга да мөмкин. Җәмәгать намазы укыганда сафлар арасыннан чыгарга кирәк булса, ул вакытта сафлар арасыннан курыкмыйча үтә алабыз. Ник дигәндә, шушы намаз вакытында фәкать имам алдыннан гына үтәргә ярамый.

:: Гель-лакка буялган тырнак белән намаз укырга ярамаганлыгын беләбез. Ә буялган чәч белән намаз укырга ярыймы?

– Тәһарәт алганда суны үткәрми торган гель-лак кына түгел, тәндәге буяу да тәһарәтне тәзек тотарга комачаулык тудыра. Әгәр кешенең кулына бинт уралган булса, ул шушы ярасы өстеннән мәсех кылып ала, ягъни суда чылатылган кулы белән сыпыра. Чәч буяуга килгәндә, ул тәһарәтне бозмый. Чөнки тәһарәт алганда, чәч кенә түгел, баш та юыла.

Бу дөнья тормышы – сәяхәт

Җир йөзенә килүгә, кешенең тормышы башлана. Кеше тормыш юлын акрын гына үтә: үсә, камилләшә, картая. Көннәрдән бер көнне килгән үлем Җир йөзен калдырып китәргә мәҗбүр итә. Кеше, башка мәхлукатлардан аермалы буларак, Аллаһыдан бирелгән акылы ярдәмендә үз тормышы белән үзе идарә итә. Әмма акылга ия булса да, ул үзенә үзе тапшырылмаган.

Бу тормышта адәм баласы акылга ияреп кенә бәхеткә ирешә алмый. Ул юл күрсәтүче затка мохтаҗ, чөнки бу дөнья сынау урыны булып тора. Бу тормышта хак юлны күрсәтүче һәм аннан тайпылдыручылар бар. Аллаһының әмерләренә каршы ба- ручы шайтан һәрдаим кешеләрне адаштырырга тырыша. Кешеләрнең тормышларын җимерер өчен, ул төрле мәкерле хәйләләр кора. Аларны юлдан яздырып, начар гамәлләрне яхшы итеп күрсәтә, хакыйкатьтән ераклаштыра, килешмәгән эшләрне башкаруга этәрә.

Әмма колларын бик яратучы Аллаһ безнең яман эшгамәлләрдән ерак торуыбызны тели. Шуның өчен Ул төрле вакытларда Үзенең пәйгамбәрләрен җибәргән. Алар һәрвакыт кешеләргә бәхеткә илтә торган юлны – динне өйрәткән. Әгәр кешеләр пәйгамбәрләрнең сүзләрен тыңласалар, әдәпле һәм бәхетле булып гомер кичерерләр, ә инде шайтанның мәкерләренә иярсәләр, бу дөньяда да, киләсе ахирәт тормышында да кайгыда булырлар.

«Янә Ул көнне һәм төнне, кояшны һәм айны сезнең өчен әмеренә буйсындырды. Йолдызлар да Аның әмере белән [сезгә] буйсындырылган [өчен, әсләрегә йөкләнгән бер вазыйфаны да үтәми калмыйлар]. Һичшиксез, [зирәклек һәм нечкә аңлау сәләтенә ия булмыйча, фәкать] акыл иясе булган кешеләр өчен монда [могҗизалы] билгеләр бар».

«Ән-Нәхел» / «Бал кортлары», 16:12

Йәгез, бер дога!

КИЕМ КИГӘНДӘ УКЫЛА

«Әлхәмду лилләәһил-ләзии кәсәәни һәзәс-сәүбә үә разәканиһи мин гайри хәүлим минни үә ләә кууүәти».

Мәгънәсе: «Минем тарафтан куәт һәм көч куймыйча, мине киендергән Аллаһка мактау булсын».



Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Лилия
ГЫЙМАЗОВА

Ә син таныйсыңмы?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук. Тулы, дөрес итеп беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

*Газетабызның узган санында чыккан җырчы һәм җырларны беренчеләрдән булып кабаттан Саба районының Яңа Мичән авылыннан **Сөмбелә Ибраһимова** танып алды. Афәрин! Бүләк – хуҗасында. Ә рәсемнәр астына без Гөлсирин Абдуллина башкаруындагы «Пар торналар», Хәйдәр Бигичев репертуарыннан «Җилфер-җилфер җил искәндә», «Заман» егетләре төркеменең «Ташлама» җырларын яшергән идек.*

Әнә шул сүзләрне әйтсәң, кошлар камышка кача, ди җырчы. Тормышның безне гел сынап торуы турында бу җыр.

Икәү булсак, хаталар булмас иде, давыл-бураннарга бирешмичә, язның назларын татыр идек, дип җырлана бу җырда.

Бу җыр – еракта калган яшьлек мәхәббәте турында. Язмыш аерса да, йөрәктә калган ул, диелә җырда.

ИЛДУС САДЫЙКОВ:

«ГАИЛӘ КОРАСЫМ КИЛӘ»

Бүгенге сәхифәбезгә күпләргә «Кайтам инде авылыма» җыры аша таныш булган яшь җырчы Илдус САДЫЙКОВны дәштек. Яшь туташларның йөрәген яуларга өлгергән егетнең якын киләчәккә нинди ниятләре бар? Ни өчен аны, өйләндереп, авылда калдырмакчы булганнар? Милиционер, йә Марат Хуҗин булырга теләгән кечкенә Илдусның кайсы теләге чынга ашкан?

:: Ни хәл?

– Аллага шөкер, бар да яхшы. Күптән түгел кулыма операция булды. Шуннан соң тернәкләндерү үзәгендә ятып чыктым. Ике еллап спорт залына йөргәнем юк иде, ниһаять, янә шөгыльләнә башладым. Шуның белән бергә концертларга әзерләнәбез. Декабрьдә берничә район үзәгендә сольный концерт куярга ниятлим. Аңа кадәр бер-ике яңа җыр өлгертергә телим.

:: Ялгышмасам, бу синең беренче концертларың гына түгел?

– Юк, моңарчы авылларда куйганыбыз булды. Район үзәгендә концерт оештыру – чираттагы баскыч. Аңа тагын да җитдирәк әзерләнергә кирәк.

:: Ә Казан тамашачысы белән кайчан очрашырга ниятлисең?

– Алла теләсә, 2023 елда. Алдан кычкырасым килми, әмма, бар да яхшы булса, язга планлаштырып торабыз. Дөресен генә әйткәндә, Казан тамашачысы каршында бик тә чыгыш ясыйсыбыз килә. Сораучылар да шактый.

:: Синең концертларыңа күбесенчә кемнәр йөри?

– Яшьләр, төгәлрәк әйткәндә, яшь туташлар *(көлә)*. Гомумән, минем иҗатым, нигездә, яшьлек турында. Киләчәк яшьләр кулында, диләр бит.

:: Кечкенәдән үк җырлыйсыңмы?

– Әйе, үземне хәтерләгәннән бирле, дияргә буладыр. Минем әнием дә бик матур җырлый. Мәрхүм әтием дә, эш арасында булса да, моңланып йөрергә ярата иде.

:: Бала чагың турында да берәз сөйлә әле.

– Нурлат районының Би Күле авылыннан мин. Бала чакта бик шук идек инде. Чын авыл малайлары, кыскасы. Авылның үз романтикасы бар бит ул. Бәхетемә, мин шуны татып, эш һәм уен аша чыныгып үстем. Авыл егете булуым белән горурланам. Инде байтак кына Казанда яшәгәннән соң да бер ел торып килдем бит мин авылда. Ул чакта халык театрында режиссер (Илдусның режиссер булеме бар. – **Авт.**) булып эшләдем. Авыл халкы өчен шаккаткыч һәм шатлыклы вакыйга булды ул. Бергәләп театрга җан өрдек. Ләкин җитәкчелек белән аңлашылмаучанлыклар килеп чыккач, мин китәргә карар кылдым. И ул чакта ничек кенә калдырырга тырышмадылар инде. Өйләнерсең, кал инде, диештеләр.

:: Димәк, «Кайтам инде авылыма» җыры белән танылуың – очраклы гына хәл түгел?

– Аның популярлыгы – йолдызларның шулай туры килүеннәндер ул. Бар күңелемне, авылыма булган кадер-мәхәббәтемне салдым мин аңа. Бәлки, ул җыр ихласлыгы белән җәлеп итәдер. Бәлки, минем хисләр күпләргә таныш булганга уңышлыдыр ул.

:: Тормыш сәхифәләреңне барлаганда, миңа синең Казан юридик институтында укуың, әмма аны тәмамлавың мәгълүм булды. Беренчедән, ни өчен алдан бу юнәлешне сайлаган идең?

– Кечкенә чакта «Кем буласың килә?» дигән сорауга мин: «Йә, милиционер, йә Марат Хуҗин булам», – дип җавап бирә идем. Марат Хуҗин ул – безнең район эшмәкәре һәм җырчысы. Аның үз иҗат төркеме, җырлары яздыртылган дисклары бар иде. Менә минем шуңа охшыйсым килде. Ә мәктәптә укыганда бу уемнан кире кайттым, булдыра алмам кебек тоелды. Шунда мәрхүм әтием юридик институтка укырга керергә кәңәш итте. Бу тәкъдим үземә дә ошады. Анда укырга керу гаять катлаулы булса да, ничектер керә алдым.

:: Ә ни өчен китәргә булдың?

– Икенче елымны укыганда ук, ничек тә моннан китәргә иде, дип уйлана башладым. Әти-әнине борчыйсым килмәү генә туктатты. Аңламаслар, дидем. Ә миңа ирек җитмәде. Анда укыганда ук шул юнәлештә эшлисе дә бит, чит эштә эшләргә ярамый. Ә мин һаман иҗатка тартылдым. Өч курс ярым укыгач, тәвәккәлләдем. Укуымны тәмамлаган булсам, бүген без синең белән сөйләшеп утырмас идек.

:: Илдус, килешәсеңдер, бүген татар эстрадасында яшь җырчылар бик күп, көндәшлек көчле. Башкалардан аерылып тору катлаулымы?

– Көндәшлек – яхшы нәрсә. Эшләргә, һәрвакыт үсештә булырга этәрә ул. Ничек кенә булмасын, һәр артистның – үз тамашачысы. Иманым камил, әйтик, ике җырчының да концертына нәкъ бер төсле тамашачы килми.

Ә катлаулылыкка килгәндә, җырчының эше, гомумән, җиңел түгел инде ул. Читтән караганда җиңел тоелса да. Әйе, без 40 градуслы суыкта нефть чыгармыйбыз, катлаулы физик эш эшләмибез. Ләкин аның бит башка яклары бар. Әти миңа гел: «Эшнең җиңеле юк», – ди иде. Чыннан да шулай бит.

:: Тәнкыйтькә ничек карыйсың?

– Тыныч карыйм. Мин аларга җавап та бирмим, социаль челтәрләргә язсалар, «лайк» куям. Мәрхүм Илһам абый Шакиров әйтмешли, синең турында начар сөйлиләрме, яхшымы, иң мөһиме – сөйләсеннәр.

Шулай да, берәүнең сүзләре күңелемә тиде, мин аңа җавап та бирдем. Әйткәнемчә, кулыма операция булгач, миңа бандаж киеп йөрергә һәм шул килеш концертларда катнашырга туры килде. Шунда берсе: «Мобилизациягә эләкмәс өчен, бандаж киеп йөрисең», – дип язды. Җавапсыз калдыра алмадым моны.

Блиц-сораштыру

– Сине барысы да өйләндерергә тели, ахры. Үзең камыт кияргә уйлыйсыңмы соң әле?

– Әлбәттә. Матур гаилә корырга, балалар тәрбияләргә хыялланам. Әмма бу бит – зур җаваплылык. Насыйбымны табып, аның белән гомергә бергә буласым килә.

– Син гашыйкмы?

– Әйе.

– Үзеңне нинди өч сыйфат белән тасвирлар идең?

– Гади, берәз тырыш һәм кайвакыт ялкау *(көлә)*.

– Безнең укучыларга өч фильм тәкъдим итсәң иде.

– «Социальная дилемма» (реж. – Джефф Орловски), «Богемская рапсодия» (реж. – Брайан Сингер), «Начало» (реж. – Кристофер Нолан).

23 ноябрь | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.00 «БЕСПОКОЙНЫЙ УЧАСТОК» 12+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «Көмеш наратлык». (Татар телендә) 16+
13.00 «Жырлыйк әле!» 6+
14.00 «Если хочешь быть здоровым» 12+
14.15 «Мой формат» (с сурдопереводом)12+
14.45, 05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп өйрәник» 0+
16.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Барыс» – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 6+
21.00 Документальный фильм 12+
22.10 «Көмеш наратлык». Телесериал (татар телендә) 16+
23.50 «Соотечественники». Телефильмы. «Золото Дэрдмэнда» и «Остров памяти. Шариф Камал» 12+
00.15 «Каравай». Промыслы 6+
00.40 «Ватандашлар»12+
01.05 «Жырлыйк әле!» 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җавит» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 05.50 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
09.40 «Ачыктан-ачык» 12+
10.40 «Туган авылым» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Таяну ноктасы» 16+
12.35 «Кырыгый океан серләре». Док. фильм 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 21.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Дәрдмәнд (Закир Рәмиев) турында телеочерк 6+
19.10, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
00.15 «Яшьләр тукталышы» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
04.15 «Таяну ноктасы» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро» 16+
09.00, 12.00, 15.00, 18.00, 03.00 Новости 16+
09.20 «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45, 03.05 Информационный канал 16+
21.00 «Время» 16+
21.45 «ШИФР» 16+
22.45 «Большая игра» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России» 16+
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан 16+
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести 16+
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «БАРЕНЦЕВО МОРЕ» 16+
22.20 «Вечер с В. Соловьевым» 12+
01.00 «Судьба человека» 12+
03.00 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.15 Новости 16+
06.05, 00.00 Все на Матч! 12+
09.10 Футбол. ЧМ-2022. Франция – Австралия 0+
11.15 «Оазис футбола» 0+
12.20 Футбол. ЧМ-2022. Обзор 0+
12.45, 01.10 Футбол. ЧМ-2022. Марокко – Хорватия 0+
15.00, 18.00, 21.00 Катар 2022. Все на футбол! 0+
15.45, 03.15 Футбол. ЧМ-2022. Германия – Япония 0+
18.45 Футбол. ЧМ-2022. Испания – Коста-Рика 0+
21.45 Футбол. ЧМ-2022. Бельгия – Канада 0+
00.45 «Футбол после полуночи» 16+
05.20 Международные соревнования «Игры дружбы-2022». Плавание 0+

НТВ

04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня» 12+
08.25, 10.35 «ЛЕСНИК» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие» 12+
14.00 «Место встречи» 16+
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СПЕЦБАТ» 16+
22.10, 00.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» 16+
00.30 «Англия – Россия. Коварство без любви» 16+
01.30 «ПРОФИЛЬ УБИЙЦЫ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00, 04.20 «Давай разведемся!» 16+
10.00, 02.40 «Тест на отцовство» 16+
12.10, 01.00 Докудрама «Понять. Простить» 16+
13.15, 23.00 Докудрама «Порча» 16+
13.45, 00.05 Докудрама «Знахарка» 16+
14.20, 00.35 Докудрама «Верну любимого» 16+
14.50 «МЕЖДУ СВЕТОМ И ТЕНЬЮ» 16+
19.00 «МЕЖДУ НАМИ ВЫПАЛ СНЕГ» 16+
01.50 «ВОСТОК – ЗАПАД» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «РУССКАЯ РУЛЕТКА (ЖЕНСКИЙ ВАРИАНТ)» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.45 «РОССИЯ МОЛОДАЯ». «БЕДА ЗА БЕДОЙ» 12+
10.45, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.20, 15.05, 03.55 «НА ВСЕХ ШИРОТАХ...» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 Док. сериал «Битва оружейников» 16+
19.40 Док. сериал «Секретные материалы» 16+
22.55 «Между тем» 12+
23.25 «ТАСС УПОЛНОМОЧЕН ЗАЯВИТЬ...» 12+
02.50 Док. фильм «Бой за берет» 12+
03.20 Док. фильм «Раздвигая льды» 12+

24 ноябрь | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 00.00 «БЕСПОКОЙНЫЙ УЧАСТОК» 12+
11.00 Дөньякүләм белем тикшерү акциясе «Татарча диктант-2022» 6+
12.00, 23.10 «Көмеш наратлык». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Кәмит Җавит». Юмористик тапшыру 16+
14.00 «Каравай» 6+
14.15 «Рыцари вечности» 12+
14.45, 05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Казаннан – Казанга» 12+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Юлчы» 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры» 16+
21.00 «Ватандашлар» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Наша Республика – наше дело» 12+
00.50 «Видеоспорт» 12+
01.15 «Соотечественники». Асия Миннуллина. От керамики до бронзы 12+
01.40 «Каравай». Секреты казанского чаепития 6+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Башваткыч» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40 «Кәмит Җавит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Кунак БиТ Шоу» 12+
10.40 «Туган авылым» 6+
11.00 «Татарча диктант». Дөньякүләм online татарча диктант 6+
12.05 «Таяну ноктасы» 16+
12.35 «Кырыгый океан серләре». Документаль фильм 6+
15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
15.30, 00.15 «Халкым минем» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның халык артисты Резеда Шәрәфиева турында телеочерк 6+
19.10, 20.00, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
21.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның халык артисты Резеда Шәрәфиева турында телеочерк 6+
23.05 «Кәмит Җавит». Юмористик тапшыру 16+
02.50 «Караоке татарча» 6+
04.15 «Кәмит Җавит». Юмористик тапшыру 16+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро» 16+
09.00, 12.00, 15.00, 18.00, 03.00 Новости 16+
09.20 «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45, 03.05 Информационный канал 16+
21.00 «Время» 16+
21.45 «ШИФР» 16+
22.45 «Большая игра» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России» 16+
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время 16+
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести 16+
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «БАРЕНЦЕВО МОРЕ» 16+
22.20 «Вечер с В. Соловьевым» 12+
01.00 «Судьба человека» 12+
03.00 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Новости 16+
06.05, 00.00 Все на Матч! 12+
08.20 Биатлон. Pari Кубок России. Мужчины 12+
09.50 Футбол. ЧМ-2022. Бельгия – Канада 0+
11.50 «Оазис футбола» 0+
12.45, 01.10 Футбол. ЧМ-2022. Швейцария – Камерун 0+
15.00, 18.00, 21.00 Катар 2022. Все на футбол! 0+
15.45, 03.15 Футбол. ЧМ-2022. Уругвай – Южная Корея 0+
18.45 Футбол. ЧМ-2022. Португалия – Гана 0+
21.45 Футбол. ЧМ-2022. Бразилия – Сербия 0+
00.45 «Футбол после полуночи» 16+
05.20 Международные соревнования «Игры дружбы-2022». Плавание 0+

НТВ

04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня» 12+
08.25, 10.35 «ЛЕСНИК» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие» 12+
14.00 «Место встречи» 16+
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СПЕЦБАТ» 16+
22.10, 00.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» 16+
00.30 «Поздняков» 16+
00.45 «Мы и наука. Наука и мы» 12+
01.40 «ПРОФИЛЬ УБИЙЦЫ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 05.05 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.40, 04.15 «Давай разведемся!» 16+
09.40, 02.35 «Тест на отцовство» 16+
11.50, 00.55 Докудрама «Понять. Простить» 16+
12.50, 22.55 Докудрама «Порча» 16+
13.20, 00.00 Докудрама «Знахарка» 16+
13.55, 00.30 Докудрама «Верну любимого» 16+
14.30 «ЗАВТРА Я ТЕБЯ РАЗЛЮБЛЮ» 16+
18.45 «Спасите мою кухню» 16+
19.00 «ЛЮБОВЬ ЗЛА» 16+
01.45 «ВОСТОК – ЗАПАД» 16+

ЗВЕЗДА

05.20, 13.20, 15.05, 04.35 Т/с «На всех широтах...» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 02.00 «РОССИЯ МОЛОДАЯ». «СТРАШНЕЕ, ЧЕМ ШТОРМ» 12+
10.45, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
15.00 Военные новости 16+
17.00 Док. фильм «Легенды госбезопасности» 16+
18.50 Док. сериал «Битва оружейников» 16+
19.40 «Код доступа» 12+
22.55 «Между тем» 12+
23.25 «ТАСС УПОЛНОМОЧЕН ЗАЯВИТЬ...» 12+
03.05 «БЛИЗНЕЦЫ» 6+

25 ноябрь | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести-Татарстан

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
11.00 Дөньякүләм белем тикшерү акциясе «Татарча диктант-2022» 6+
12.00, 23.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК». (Татар телендә) 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
14.45, 05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Аулак өй» 6+
16.30 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Туган җир» 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 Телефильм 12+
21.00 «Юлчы» 6+
22.10 «КВН РТ-2022» 12+
00.00 «ПРОСТО САША» 12+
01.10 «Каравай». Народное искусство Лимы Кустабаевой 6+
01.35 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җавит» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Ком сәгате» 12+
09.40, 15.30 «Нәсыйхәт» 6+
10.30 «Казаннан – Казанга» 12+
11.00 «Татарча диктант». Дөньякүләм online татарча диктант 6+
12.05, 18.20 «Йөрәктән – йөрәккә». Җәүдәт Фәйзи турында телеочерк (субтитрлы) 6+
15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30 «Калеб» 6+
19.15 «Туган җир» 12+
19.40 «Заман көзгесе» 6+
20.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
21.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Булат Гыйльванов турында телеочерк 6+
22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
00.15 «Нәсыйхәт» 6+
00.40 «Калеб» 6+
01.05 «Әх, гармуннар уйный бел сәм!» Концерт 6+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро» 16+
09.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости 16+
09.20 «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 02.15 Информационный канал 16+
18.40 «Человек и закон» 16+
19.45 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время» 16+
21.45 ФАНТАСТИКА. Ф и н а л 12+
00.05 «Баста. Моя игра» 16+
01.20 «СУДЬБА НА ВЫБОР» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России» 16+
09.00, 14.30, 21.15 Местное время. Вести-Татарстан 16+
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести 16+
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.30 «Дуэты» 12+
23.45 «Улыбка на ночь» 16+
00.50 «НЕПРЕДВИДЕННЫЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВА» 12+
04.10 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.15 Новости 16+
06.05, 00.00 Все на Матч! 12+
09.10 Футбол. ЧМ-2022. Бразилия – Сербия 0+
11.15 «Оазис футбола» 0+
12.20 Футбол. ЧМ-2022. Обзор 0+
12.45, 01.10 Футбол. ЧМ-2022. Уэльс – Иран 0+
15.00, 18.00, 21.00 Катар 2022. Все на футбол! 0+
15.45, 03.15 Футбол. ЧМ-2022. Катар – Сенегал 0+
18.45 Футбол. ЧМ-2022. Нидерланды – Эквадор 0+
21.45 Футбол. ЧМ-2022. Англия – США 0+
00.45 «Футбол после полуночи» 16+
05.20 Международные соревнования «Игры дружбы-2022». Плавание 0+

НТВ

04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня» 12+
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» 6+
09.25, 10.35 «Следствие вели...» 16+
11.00 «Мусор против человека» 12+
12.00 «Дедсад» 0+
13.25 «Чрезвычайное происшествие» 12+
14.00 «Место встречи» 16+
16.45 «ДНК» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 «СПЕЦБАТ» 16+
22.10 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» 16+
00.00 «Своя правда» 16+
01.45 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
02.10 «Квартирный вопрос» 0+
03.00 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+
03.30 «ПРОФИЛЬ УБИЙЦЫ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.40, 04.20 «Давай разведемся!» 16+
09.40, 02.40 «Тест на отцовство» 16+
11.50, 01.00 Докудрама «Понять. Простить» 16+
12.50, 23.00 Докудрама «Порча» 16+
13.20, 00.05 Докудрама «Знахарка» 16+
13.55, 00.35 Докудрама «Верну любимого» 16+
14.30 «МЕЖДУ НАМИ ВЫПАЛ СНЕГ» 16+
18.45 «Про здоровье» 16+
19.00 «ГРЫМЗА» 16+
01.50 «ВОСТОК – ЗАПАД» 16+

ЗВЕЗДА

06.00 Т/с «НА ВСЕХ ШИРОТАХ...» 16+
08.05 Док. сериал «Память». «Саня, Саша, Сашка, Александр Покрышкин: следуя за мечтой» 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20, 02.05 «РОССИЯ МОЛОДАЯ». «КРЕПОСТИ БЫТЬ!» 12+
10.55 Док. фильм «25 ноября – день российского миротворца» 16+
11.25 Док. фильм «Освобождение» 16+
12.00, 13.20, 15.05, 18.40 Т/с «ЧЕРНЫЕ ВОЛКИ» 16+
15.00 Военные новости 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.00 «Музыка+» 12+
23.55 «ТАСС УПОЛНОМОЧЕН ЗАЯВИТЬ...» 12+
03.05 «МЕДОВЫЙ МЕСЯЦ» 12+
04.40 Док. сериал «Хроника Победы» 16+

26 ноябрь | Шимбә

ТАТАРСТАН
08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Синҗ Миннән Сәлам». Музыкаль котлаулар 6+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Винера Ганиева 12 +
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 Дөньякүләм белем тикшерү акциясе "Татарча диктант-2022" 6+
11.45 «Туган авылым» 6+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
13.30 И. Зәйниев. «БӘБИ». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 6+
15.30 «Добровидение». Гала-концерт VII Международного фестиваля народной песни 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «Кунак БиТ шоу». Чулпан Юсупова 12+
23.00 «Үзгәреш җиле-2018» 6+
01.40 «КОРОЛЕВСТВО ПОЛНОЙ ЛУНЫ» 12+
03.10 «Вехи истории». Татарский театр. Открывая занавес истории 12+
03.35 «Каравай». Влюбленный в родной край 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Дамир Сираҗиев турында телеочерк 6+
07.00, 15.00 «Синҗ Миннән Сәлам» 6+
09.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Татарча диктант». Дөньякүләм online татарча диктант 6+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Туган авылым» 6+
13.20 «Кайда сез, яшьлек еллары?» Зөһрә Шәрифуллина концерты 6+
17.10 «Казаннан – Казанга» 12+
17.45 «Халкым минем» 12+
18.15 «Башваткыч» 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Әниләр һәм бәбиләр». Концерт 6+
22.15 Ш. Хөсәенов. «ӘНИ КИЛДЕ». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
00.50 «Бар ул, бәхет, бар!» Татарстанның халык артисткасы Фирая Әкбарованың иҗат кичәсе 6+
03.00 «Башваткыч» 12+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
05.05 «Халкым минем» 12+

1 КАНАЛ
06.00 «Доброе утро. Суббота» 12+
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00, 12.00, 18.00 Новости 16+
10.15 «ПроУют» 0+
11.10 «Поехали!» 12+
12.15 «Видели видео?» 0+
14.40 «Роковая любовь Саввы Морозова» 12+
16.55 «Горячий лед» 12+
18.20 «Снова вместе. Ледниковый период» 0+
21.00 «Время» 16+
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.15 «ТЕНЬ ЗВЕЗДЫ» 12+
00.55 «Великие династии. Волконские» 12+
01.50 «Моя родословная» 12+
02.30 «Наедине со всеми» 16+
03.15 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России. Суббота» 16+
08.00 Местное время. Вести-Татарстан 16+
08.20 Местное время. Суббота 16+
08.35 «По секрету всему свету» 0+
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного» 0+
10.10 «Сто к одному». Телеигра 0+
11.00, 17.00, 20.00 Вести 16+
11.30 «Доктор Мясников» 12+
12.35 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «СТОЛИЧНАЯ ШТУЧКА» 12+
00.50 «ОБУЧАЮ ИГРЕ НА ГИТАРЕ» 16+
03.50 «НЕ ПОКИДАЙ МЕНЯ, ЛЮБОВЬ» 12+

МАТЧ ТВ
06.00, 08.30 Новости 16+
06.05, 12.25, 00.00 Все на Матч! 12+
08.35 Биатлон. Pari Кубок России. Мужчины 12+
09.30 Футбол. ЧМ-2022. Англия – США 0+
11.35 Биатлон. Pari Кубок России. Женщины 12+
12.45, 01.10 Футбол. ЧМ-2022. Тунис – Австралия 0+
15.00, 18.00, 21.00 Катар 2022. Все на футбол! 0+
15.45, 03.15 Футбол. ЧМ-2022. Польша – Саудовская Аравия 0+
18.45 Футбол. ЧМ-2022. Франция – Дания 0+
21.45 Футбол. ЧМ-2022. Аргентина – Мексика 0+
00.45 «Футбол после полуночи» 16+
05.20 Гандбол. Чемп. России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. «Ростов-Дон» – «Лада» 0+

НТВ
05.05 «Спето в СССР» 12+
05.50 «ИНСПЕКТОР КУПЕР» 16+
07.30 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня» 12+
08.20 «Поедем, поедим!» 0+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 «Секрет на миллион» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «ЧП. Расследование» 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение» 16+
20.20 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. СИМБИРСКИЕ МОРОЗЫ» 12+
22.35 «Ты не поверишь!» 16+
23.35 «Международная пилорама» 16+
00.15 «Квартирник НТВ у Маргулиса» 16+
01.40 «Дачный ответ» 0+
02.35 «Таинственная Россия» 16+
03.20 «ПРОФИЛЬ УБИЙЦЫ» 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «6 кадров» 16+
07.00 «ДЖИНН» 16+
10.40, 01.45 «ВТОРАЯ ЖИЗНЬ ЕВЫ» 16+
19.00 «Ветреный» 16+
22.30 «ПЕРЕЛЕТНЫЕ ПТИЦЫ» 16+
04.50 Докудрама «Порочные связи» 16+

ЗВЕЗДА
05.05 «В ДОБРЫЙ ЧАС!» 12+
06.40, 02.55 «ЗОЛОТЫЕ РОГА» 6+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.15 «Морской бой» 6+
09.10 Док. фильм «Маршалы Сталина. Семен Тимошенко» 16+
10.00, 01.25 «ЗА ВИТРИНОЙ УНИВЕРМАГА» 12+
11.45 «Легенды музыки» 12+
12.10 «Легенды науки». Гавриил Илизаров 12+
13.15 «Время героев» 16+
13.35 «Главный день» 16+
14.20 «СССР. Знак качества» 12+
15.10 «Не факт!» 12+
15.35 Док. сериал «Война миров» 16+
16.25, 18.30 «СНАЙПЕР-2. ТУНГУС» 16+
21.00 «Легендарные матчи». «Олимпиада 2016. Гандбол. Женщины. Полуфинал. Норвегия – Россия» 12+
00.00 «ПРАВО НА ВЫСТРЕЛ» 12+
04.10 Док. фильм «Вторая Мировая война. Город-герой Севастополь» 12+
04.35 Док. сериал «Москва фронту» 16+
04.55 «НЕБЕСНЫЙ ТИХОХОД» 12+

27 ноябрь | Якшәмбе

ТАТАРСТАН
08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Әниләр һәм бәбиләр». Концерт 6+
08.00 «Адымнар» 12+
08.30 Мультфильм 0+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
10.15 «Ачыктан-ачык». Гүзәлия 12+
11.00 «Туган авылым» 6+
11.20 «Йөрәк җылысы». Филүс Каһиров 6+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество»12+
13.00 «Видеоспорт» 12+
13.30 «Адымнар» 12+
14.00 «Безнең Республика – безнең гамәл» 12+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
16.00 «Ком сәгате» 12+
17.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – ХК «Сочи». Прямая трансляция 6+
19.30, 22.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
21.00 «Профсоюз – союз сильных» 12+
21.15 «Батырлар» 6+
21.30 «Болгар радиосы» концерты 6+
23.00 «Үзгәреш җиле-2021» 6+
01.35 «Халкым минем...» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+
05.50 Татарстан хәбәрләре 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
07.00 «Адымнар» 12+
07.30 Татарстанның халык артисты Искәндәр Биктаһировның юбилей концерты 6+
09.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы» 12+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Туган авылым» 6+
13.20 «Мәңгелектән иса җил». Ләис Зөлкарнәйнең 60 яшьлек юбилей кичәсе 6+
15.10 «Җырларымда син генә». Рафил Җәлалиев һәм Эльмира Гыйльфанова концерты 6+
16.20 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.05 «Ком сәгате» 12+
20.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
21.10 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
22.00 К. Тинчурин. «ҖИЛКӘНСЕЗЛӘР». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
00.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
02.45 «Адымнар» 12+
03.15 «Китмә, сандугач». Илһам Шакиров ядкаре 6+

1 КАНАЛ
05.10, 06.10 «СПОРТЛОТО-82» 0+
06.00, 10.00, 12.00 Новости 16+
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион». Национальная лотерея 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.15 «Жизнь своих» 12+
11.10 «Повара на колесах» 12+
12.15 «Видели видео?» 0+
14.30 «ЖЕНЩИНЫ» 0+
16.30 «Горячий лед» 12+
17.50 «Романовы» 12+
18.50 «КАК УБИЛИ ДЖОНА КЕННЕДИ» 16+
21.00 «Время» 16+
22.35 «Что? Где? Когда?» 16+
23.45 «БЕЗУМНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ЛУИ ДЕ ФЮНЕСА» 12+
01.35 «Моя родословная» 12+
02.20 «Наедине со всеми» 16+
03.05 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1
05.35, 02.30 «МАМА ВЫХОДИТ ЗАМУЖ» 12+
07.15 «Устами младенца» 0+
08.00 Местное время. Воскресенье 16+
08.35 «Когда все дома» 0+
09.25 «Утренняя почта» 12+
10.10 «Сто к одному». Телеигра 0+
11.00, 16.00 Вести 16+
11.50 «ДОМ ГДЕ СЕРДЦЕ» 12+
17.00, 19.00 «Песни от всей души» 12+
18.00 «Конкурс юных талантов «Синяя Птица» 12+
20.00 Вести недели 16+
22.00 Москва. Кремль. Путин 12+
22.40 «Воскресный вечер» 12+
01.30 «Судьба человека» 12+

МАТЧ ТВ
06.00 Новости 16+
06.05, 12.25, 00.00 Все на Матч! 12+
08.50 Биатлон. Pari Кубок России. Мужчины 12+
10.25 Футбол. ЧМ-2022. Аргентина – Мексика 0+
12.45 Футбол. ЧМ-2022. Япония – Коста-Рика 0+
15.00, 18.15, 21.00 Катар-2022. Все на футбол! 0+
15.30 Футбол. FONBET Кубок России. «Зенит» – «Спартак» (Москва) 0+
18.45, 03.15 Футбол. ЧМ-2022. Хорватия – Канада 0+
21.45 Футбол. ЧМ-2022. Испания – Германия 0+
00.45 «Футбол после полуночи» 16+
01.10 Футбол. ЧМ-2022. Бельгия – Марокко 0+
05.20 Керлинг. Международный турнир «Murom Classic 2022». Женщины 0+

НТВ
05.00 «ИНСПЕКТОР КУПЕР» 16+
06.35 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня» 12+
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
11.55 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели» 16+
20.20 «Суперстар! Возвращение» 16+
23.25 «Звезды сошлись» 16+
00.55 «Основано на реальных событиях» 16+
03.25 «ПРОФИЛЬ УБИЙЦЫ» 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «6 кадров» 16+
06.40 «ОПЕКУН» 16+
10.15 «ЛЮБОВЬ ЗЛА» 16+
14.30 «ГРЫМЗА» 16+
18.45 «Пять ужинов» 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ» 16+
22.25 «ДЕВИЧИЙ ЛЕС» 16+
01.55 «ВТОРАЯ ЖИЗНЬ ЕВЫ» 16+
05.05 «Порочные связи» 16+

ЗВЕЗДА
06.10 «Правда лейтенанта Климова» 12+
07.40 «Черные береты» 16+
09.00 Новости недели 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.45 «Скрытые угрозы» 16+
11.30 «Код доступа» 12+
12.20 «Легенды армии» 12+
13.05 «Специальный репортаж» 16+
13.55 «ПРИВЕТ ОТ КАТЮШИ» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.45 «Битва оружейников» 16+
21.20 Док. сериал «Легенды советского сыска» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.45 «БОЛЬШАЯ СЕМЬЯ» 12+
01.35 «ПРИКАЗАНО ВЗЯТЬ ЖИВЫМ» 12+
03.20 «ИЗ ПЛАМЯ И СВЕТА...» 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?
Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 21 ноябрь
6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10 «Әдәбиятыбыз сәхифәләре». Айдар Хәлим хикәяләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Безнең заман әдәбияты үрнәкләре». Вазыйх Фатыйхов
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 22 ноябрь
6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.20 «Вместе за безопасность»
18.30 «Газиз тавышлар». Зөлайха Хисмәтуллина язмалары

Чәршәмбе, 23 ноябрь
6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 «Вместе за безопасность»
7.20 Туры элемтә
7.45 «Юллар чатында»
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
11.40 Прокуратура разъясняет
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Шәүкәт Галиев шигырьләренә җырлар

Пәнҗешәмбе, 24 ноябрь
6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 Фәридә Фәизова әсәрләре

Җомга, 25 ноябрь
6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на марийском языке).
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Эстрада концерты

Шимбә, 26 ноябрь
8.10 Исмай Шәмсетдинов. «Тула өмәсендә». Әдәби-музыкаль композиция
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Гөлбакча»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм»
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында».
15.10 «Шигърият». Кадыйр Сибгатуллин

Якшәмбе, 27 ноябрь
8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында».
15.10, 16.10 Георгий Ибушевның иҗат кичәсеннән репортаж

РЕКЛАМА БУЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Сәрия
МИФТАХОВА

КҮЛӘГӘДӘН ЧЫГАРУ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Дәүләт Думасына үсмерләрне эшкә урнаштыру тәртибен гадиләштерүне күздә тоткан закон проекты кертелгән. Әгәр аны хупласалар, алар 14 яшьтән үк рәсми эшли башларга мөмкин.

Кәгазь эше кими

Узган ел илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге (ВЦИОМ) уздырган сораштыруда югары сыйныф укучыларының 91 проценты җәйге каникул вакытында эшләргә теләк белдергән. Россиядә ел саен 18 яшькә кадәрге 520 мең үсмер эшли. Һәр бишенче үсмер диган сүз бу. Хәзерге вакытта алар күбрәк курьер, промоутер, җыештыручы, менеджер, официант кебек хезмәтләрне башкара.

«Бездә яшьләр актив. Алар үсәргә, тәҗрибә тупларга тели, әмма моның нәтиҗәле механизмнары юк. Төрле киеньлеклар очрау сәбәпле, рәсми рәвештә эшкә урнаша алмыйлар. Тикшерүләр, бюрократия… Бу эш бирүчеләргә файдага түгел. Безнең закон проекты вазгыятьне яхшы якка үзгәртергә ярдәм итәчәк», – ди инициатива авторларының берсе, Дәүләт Думасының Яшьләр сәясәте комитеты рәисе Артем Метелев.

Дәүләт Думасына кертелгән закон проекты яшүсмерләрне эшкә урнаштыру тәртибен гадиләштерү, бу өлкәдәге киртәләрне бетерүне күздә тота. Бу очракта аларның хокукларын якларга да җиңелрәк булачак. Балаларга 14 яшьтән эшләргә мөмкинлек бирү хәзерге вазгыятьтә гаиләнең матди ягын җиңеләйтергә дә ярдәм итәчәк, дип саный депутатлар. Шулай ук балаларда җаваплылык хисе дә артачак, диләр. Закон проекты хупланса, үсмерләр эшне җиңелрәк табачак, хезмәт килешүе төзү өчен опека һәм попечительлек органнарының ризалыгы кирәк булмаячак. Моның өчен әти-әниенең яки законлы вәкиленең рөхсәте дә җитә.

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат үзәгеннән хәбәр итүләренчә, быел соңгы ун айда республикада 12537 үсмер эшкә урнаштырылган.

– 14 яшьлек үсмергә, эшкә урнашу өчен, әти-әнисенең берсенең һәм опека органнарының язмача ризалыгы кирәк. Аларны сәламәтлеккә зыян китерә торган авыр эшләргә тарту тыела. Бу исемлектә төнге клублар, уен бизнеслары да бар. Әгәр мәктәптә укый икән, дәрестән соң гына эшләргә ярый. Кече яшьтәге балалар кино, театр, цирк тамашалары, концертларда чыгыш ясый ала. 14–15 яшьлек үсмерләргә җәен 4–5 сәгатьтән артык эшләргә ярамый. Уку чорында – 2,5 сәгать, – дип аңлаттылар матбугат үзәгендә.

Өстәмә мәшәкать

Казандагы төзелеш фирмасының берсенә шалтыратып, яшьләрне эшкә урнаштыру тәртибе турында кызыксындык.

– Бездә бер үсмер дә эшләми. Ялерен-батырын түгел, җитәкчеләрнең күбесе аларны кабул итәргә атлыгып тормый. Ни өчен дигәндә, һәрберсенә имин шартлар тудырырга, җавап бирергә кирәк. Өстәмә мәшәкать кемгә кирәк? Шуңа күрә бу темадан читкә китәләр, – диде компаниянең кадрлар буенча белгече Ленар Чумарин. – Җәй көне килсәләр, каршы түгел. Алар җыештыра, урам себерә ала. Клининг компанияләрендә дә җыештыручыларга кытлык. Әлбәттә, башка белгечлекләргә квалификациясез алып булмый. Опека органнарыннан рөхсәт сорауны бетерсәләр, яхшы булыр. Бу өстәмә кәгазь эшен киметәчәк. Әлеге очракта җаваплылык әти-әниләргә төшә. Мин үзем беренче хезмәт хакымны 12 яшьтә үк алдым. Аклы-каралы фотолардан календарь ясап, мәктәптә сата идем.

Балык Бистәсе районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге директоры Гүзәлия Керженцева белдергәнчә, балалар җәй көне акча эшләргә тели, әти-әниләре дә каршы түгел. Укыганда эшләргә вакытлары калмый. «Бездә 14 яшьтән эшләүчеләр дә бар. Аларга кыскартылган эш сәгате каралган, имин шартлар тудырылган. Аерым остаз билгелибез. Шушы тәртипләр сакланганда, барлык әти-әниләр дә риза. Картага акча күчкәч, балалар бик сөенә. Стажлары да бара», – диде ул.

«Акча кадерен беләм»

Балтач районының Арбаш авылында яшәүче Айнур Ибәтуллин җәй көннәрендә көтү көтә. 7–8 яшьтә абыйсына ияреп чыкса, 13–14 яшьтә инде тәҗрибәле көтүчегә әйләнгән.

– Беренче хезмәт хакым көнгә 500 сум иде, – ди 11 нче сыйныфта укучы Айнур. – Балаларны 14 яшьтән эшләтү әйбәт. Мин моны авыл баласы буларак әйтәм. Авылда кечкенәдән кул арасына керәбез бит. Балалар акча кадерен белеп үсәргә тиеш. Әти-әниләр вак-төяк чыгымнар өчен биргәндә, ул моны аңламый, кирәкмәгән нәрсәгә тотарга мөмкин. Үзең тапканның тиененә кадәр кадерле. Мин, мәсәлән, телефон, сәгать, башка кирәкле әйберләр сатып алдым.

Татарстан Әтиләр берлеге әгъзасы Әмир Мамин да эшкә яшьтән өйрәтүне хуплый. Андыйлар үзенең дә, башкаларның да хезмәтен бәяли беләчәк, диган фикердә ул. Тик эш бирүчеләр иминлек мәсьәләсен контрольдә тотарга тиеш.

Мәгарифтән башларга

Укытучылар исә, баланың төп эше – уку, дигән фикердә. Эшләгән очракта укуга зыян килмәскә тиеш. Акча эшләү мөмкинлекләре күбрәк булса, үсмерләр, укып торуның кирәге юк, дип уйлый башларга мөмкин. Укытучыларны мәсьәләнең шул ягы борчый. Алай да, эшкә өйрәнеп үссен, диючеләре аз түгел.

– Илдәге вазгыятьне алсак, балалар хәзер олы абыйларын, әтиләрен алыштыруга әзер торырга тиеш. Эш мәсьәләсенә килгәндә, оешма җитәкчеләре бу балаларны эшкә алырмы, эш тәртибе яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып көйләнерме, хезмәт хокуклары сакланырмы? Монысын да уйларга кирәк. Бу бит – 9 нчы сыйныфны тәмамлаган бала дигән сүз. Аларга моңарчы мәктәпләрдә идән дә юдырмадылар, такта да сөрттермәделәр, җәйге практикада эшләтүне әйтмим дә инде. Бераз өзеклек килеп чыга шул монда. Башта мәгарифтән башларгадыр. «Әрәмтамак»ларны күпме тәрбияләп булга? Мин эшләтү яклы, әмма баланы бүгеннән моңа әзерли башларга кирәк, – ди Балтач районы мәктәптән тыш эшләр үзәгенең өстәмә белем бирү педагогы Рәҗәп Бәдретдинов

Фикер

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ, «ВТ» журналисты:

– Балаларның эшләве фактта бар бит инде ул. Без үзебез – 12–13 яшьтән басуда бәрәңге чүпләп һәм башка эшләр эшләп үскән буын. Безнең балаларга да эләкте әле ул. Шуңа күрә, беренче карашка, моның бер куркынычы да юк кебек. Закон кабул ителү чикләүгә китерергә дә мөмкин. Әйтик, бала эшли икән, аның хезмәте санитар нормалар кысасыннан чыгып китмәскә тиеш. Федераль Хезмәт һәм социаль үсеш министрлыгы 1997 елда ук кабул иткән унсигез яшьтән яшьрәкләр өчен авыр йөк күтәрү нормалары бар. Эш сменасы дәвамында 16–17 яшьлек кызларга 3 килограммнан артык йөк күтәрергә ярамый. Ә малайларга чик норма – 4 килограмм. Эш бирүчеләр менә шул нормалар кысасында эш белән тәэмин итәләр һәм хезмәт хакы түлиләр икән, бу начар түгел. Нормалар үтәлмәсә, без яшьтән үк эче төшкән, бөере эштән чыккан, аяк тамырлары киңәйгән һәм башка чирләрдән интегүчеләр армиясе тәрбияләячәкбез. Закон менә шуларны контрольдә тотуны максат итә икән, рәхим итсеннәр.

Марсель СУЛЬТЕЕВ, психолог:

– Авылда балаларның күбесе 6 яшьтән үк эшли башлый. Сыер сава, печән җыюда катнаша, өй җыештыра, кар көри… Әмма моның өчен әти-әни бер тиен акча да түләми. Балалар болай да эшли. Әгәр яшьли тир түгә башлый икән, аларның балачагы булмаячак, диган фикер дөрес түгел. Шәһәр баласы да авылга кайтып, теләсә-теләмәсә дә, әби-бабасына бәрәңге алырга, җәен чүп утарга булыша. Хикмәт балаларга рәсми рәвештә эшләргә рөхсәт итү-итмәүдә түгел. Аның тормыш кыйммәтләрен аңлавы мөһим. Ак белән караны аерган баланы акча беркайчан да бозмый. Ул беркайчан да, начар билге алгач, моңа эш гаепле дип сәбәп эзләмәячәк. Бер эш тә баланы бозмый. Кайбер әти-әниләр балалары каршында, җитәкчеләренә шалтыратып, авыруйым, дип алдалый. Ә үзләре башка эш белән шөгыльләнә. Бала бит моны күреп үсә. Җитәкчеләр, эш турында бөтенләй начар сүз әйтмәгез. Яраткан, яратмаган эш булса да, ул бит яшәү, ашау, коммуналь хезмәтләргә түләү өчен акча китерә. Шуңа күрә балага гаилә кыйммәтләре турында сөйләгез. Аны дөрес тәрбияләгәндә, эш укуга комачауламаячак.

Фәния
ӘХМӘТҖАНОВА

СЕЗНЕ ӨЙДӘ КӨТӘЛӘР

РОССИЯ ГЕРОЕ ИВАН ДОДОСОВНЫҢ ТОРМЫШ СӘХИФӘСЕ

Махсус хәрби операциядә күрсәткән батырлыклары өчен Россия Герое Иван Додосовка бүләкне Мәскәүдә Россия оборона министры Сергей Шойгу тапшырды. Казан аэропортына каршы алырга Питрәч районы башлыгы Ильһам Кашапов, әтисе Алексей белән әнисе Татьяна, туганнары, балалар җыйнаулашып киләләр. Кечке уннар тирәсендә геройны каршы алучы машиналар Питрәч урамнарыннан тоташ сигнал биреп уза. Халык шулай үзенең батыр улын каршы ала.

«Татар-информ»

– Күңелне кузгатырлык матур бер күрешү булды ул. Татарстан вице-премьеры Ләйлә Фазлыева, хәрби комиссариат вәкилләре, халык фронты активистлары килгән иде, – дип искә ала бу көнне геройның апасы Елена Алексеевна. – Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та чакырды аны. Әти-әниебезгә чын милләтпәрвәр үстергәннәре өчен рәхмәт әйтеп, котлау да җибәрде. Шушы берничә көн эчендә аны кайларга гына чакырмадылар. Питрәч халкы әле дә шул истәлекләр белән яши.

Үз башыңнан кичерсәң генә...

– Иртә белән машинада алып киттеләр, кич кайтарып куйдылар, – дип искә ала әнисе дә ул көннәрне. – Мәктәптә укучылар белән очрашты, ветераннарны юбилейлары белән дә котларга өлгерде, «Форпост» хәрәкәтенә йөрүче яшьләр дә чакырдылар. Тирә-күршеләр, сыйныфташлары турында әйткән дә юк, элек хезмәт иткән урыннарыннан – Оренбург, Чиләбе өлкәләреннән, Мәскәүдән хезмәттәшләре килде. Чәчәкләр, бүләкләр белән өй тулды. Барысы да котладылар. Һәркемнең бу зур шатлыкны уртаклашасы килде. Кайбер күршеләр хәтта төнлә, иртә таңнан керделәр, чөнки көндезләрен Иванны берничек тә тотып булмый иде. Аңа хәтта башка районнарны да әйләнеп кайтырга туры килде. Бергә хезмәт иткән офицер: «Минем әти-әнием янына да барып кайт», – дигән булган. Анысын инде район күләмендә бик матур очрашу итеп үткәргәннәр.

Татьяна Николаевна: «Сезгә кызыбыз Елена белән сөйләшсәгез, әйбәтрәк булыр. Ул күбрәк белә. Фотолар, документларны да җыеп бара», – дигән иде. Баксаң, сәбәбе ул гына булмаган. Иминлек федераль хезмәтендә үзе дә погоннар тагып йөргән Еленаның ире Андрей Янкин да инде гыйнвар аеннан бирле махсус хәрби операциядә икән.

– Дүртенче гыйнвардан бирле күрешкәнебез юк, – ди Елена. – Мондый аерылышу беренче тапкыр гына түгел инде. Моңа кадәр ирем Сүриядә командировкада булды. Без гел шулай көтеп яшибез. Бу хәлләрне үз башыңнан кичергән кеше генә аңлый ала.

Димәк, ана белән кызның кичерешләре дә икеләтә тирәнрәк дигән сүз инде бу.

Хәрби форма

Елена герой энесенең бала чагын нинди дер бер рәхәтлек хисе белән искә алды.

– Башкалардан аерылып тормады безнең тормыш. Ваняга 7 сентябрь көнне 33 яшь тулды. Туган җиребез – Питрәч районындагы Олан Иле авылы. Район үзәгендә башта балалар бакчасына йөрде, аннары 1 нче мәктәпне тәмамлады. Гел «бишле» билгеләренә генә. Бик тәртипле, бик башлы иде ул. Хулиганлыкның әсәре дә булмады. Шуңа күрәдер инде, дуслары да күп иде. Бигрәк тә кызлар белән дуслашырга яратты. Ваняның буе кечкенәрәк иде. Шуңа күрә әллә ни сугыш чукмары да була алмас иде ул. Аның каравы спортның нинди генә төре белән шөгыльләнмәде. Футболны да яратты, тимераякта да шуды, велосипедта да җилдерде. Ул 1 нче сыйныфка барганда, мин 5 нчедә укый идем инде. Шуңа да гел күз алдымда: бик тыңлаучан, ачык йөзле, киң күңелле, тәртипле, ярдәмчел бала булды. Һәр җирдә башлап йөрергә, лидер булырга яратты.

«Ни өчен хәрби булырга теләдең?» дигән сорауны Иванга гел бирәләр, ди Елена. Ул елмая да, гади генә: «Хәрби форма ошый иде», – дип җавап бирә икән. Бәлки, шулайдыр да. Төз, ыспай гәүдәле, хәрби киемле ир-егет нинди генә малай-шалайның күңелен ымсытмас икән.

> Икенче ягы да бар. Додосовлар гаиләсендә, төрле өлкәләрдә хезмәт итсәләр дә, погоны кешеләр бик күп. Әтисенең бабасы Иван Додосов – Бөек Ватан сугышы ветераны. Ул оныгына 6 яшь тулганда гына вафат була әле. Ваня белән күп вакытын үткәрә. Сугыш турында да сөйли. Әниләренең әтисе Николай Орлов, олы абыйсы Анатолий да – хәрбиләр. Анатолий Орлов – запастагы лейтенант. Әфганстанда сугышкан. Аның ике улы да бабасы, әтисе юлыннан киткән: берсе – артиллерия училищесын, икенчесе милиция мәктәбен тәмамлаган.

«Ни өчен Иван нәкъ менә танк училищесын сайлады?» дигән сорауга Елена елмаеп кына җавап бирде.

– Аны башкасына алмаслар да иде, мөгаен, буе кечкенә, дигән идем бит. Ә анда, киресенчә, бәләкәйрәк буйлыны алырга тырышалар. Танк эченә керер өчен җайлырак, күрәсең. Укырга кергәндә миннән кыскарак кебек иде ул. Ә училищедагы тәртип үзенекен эшләде. Хәзер шактый калку. Ирем Андрей ул вакытта училищеда взвод командиры иде. Иванның командиры булды. Энем янына барып йөри торгач, танышып киттек. Димәк, мине гаиләле иткән кеше дә әле ул. Хәзер инде улыбыз Кирилл үсеп килә.

Иван танк училищесын да гел «5ле» билгесенә генә, алтын медальгә тәмамлады. Анда отличникларның хезмәт урынын алдан ук билгеләп куялар. Шуңа күрә кайберәүләр кебек, хезмәтемне дәвам итимме-юкмы икән, дип уйланырга урын калмады. Әмма Иван андый юлга бармас та иде. Бик максатчан, башлаган эшен ярты юлда ташлап калдырмый торган, үз дигәненә ирешә торган кеше ул. Шулай итеп, Оренбург өлкәсендәге Тоцк шәһәрендә урнашкан хәрби частьта танк взводы командиры буларак хезмәтен башлап җибәрде. Анда чагында танк ротасы командиры, танк батальоны командиры урынбасары дәрәҗәсенә күтәрелде. Чиләбе өлкәсенең Чибәркүл шәһәрендә хезмәт иткәндә ул инде танк батальоны командиры иде. Соңгы вакытта Ростов өлкәсенең Новочеркасск шәһәрендә урнашкан хәрби частьта хезмәт итте. Кайда гына булса да, һәрвакыт диярлек озакка сузылган командировкаларга җибәрделәр: шул исәптән Кырымга да, Донбасска да. Сизеп торам: «Ул вакыттагы хәлләр ничегрәк булды?» – дип сорыйсыгыз килә. Сирәк кенә шалтыратулардан тыш, бары тик билгесезлек кенә. Бу халәтне сүзләр белән генә аңлатып булмый. Көне-төне кечкенә генә булса да бер хәбәр көтәсең. Шундый хәлдә без инде 8 ел яшибез. Моңа беркайчан да күнегеп булмый. Нииндидер бер могҗиза көткәндәй, яшисең дә яшисең. Әйтергә кирәк, бу хисләрне һәркем үзенчә кичерә. Шуңа күрә аны аңлатып та булмый торгандыр. Хәер, бу очракта сүзләрнең кирәге дә юктыр кебек. Без барыбыз да дәшми-тынмый гына көтәбез. 2014 елны Иван командировкага киткәндә, хатыны Надежда көмәнле иде. Хәзер кызлары Аняга – 8 яшь. 2 нче сыйныфта укый. Бик батыр, йөзе белән дә, характеры белән дә әтисенә охшаган. Кешеләр белән үзен Анна Ивановна дип таныштыра. Аптырап калсалар, кыскача Аня дип әйтергә дә ярый инде, дип өстәп куя. Әллә нигә бер күрсә дә, әтисен бик ярата, бертуктаусыз көтә. Былтыр 27 июньдә күргән иде, быел тагын бер очраштылар. Елга бер тапкыр... Әтисе кайтты да тагын озакка китеп барды.

Терәк булырга кирәк

Әле хәрби операция башланганчы ук, быел гыйнвар аенда Иван Мәскәүдәге Россия Кораллы Көчләренең гомумгаскәр академиясенең тыңлаучысы булыр өчен документлар тапшырды. Хәзер укуын дәвам итә.

Кайда гына булса да, кул астында хезмәт иткән хәрбиләр белән элемтәдә тора. Киңәшләрен бирә. Өйдә булганда да: «Үзем булсам, алай эшләмәс идем. Бу хәлләр килеп чыкмаган булыр иде», – дип, борчылып утырганын берничә тапкыр күргәнем булды. Шундый инде ул безнең Иван. Башкаларны бер дә авыр хәлдә калдырасы килми. Кулыннан килгәнчә ярдәм итә. Үзенә начарлык эшләгән кешеләргә дә ташка аш белән җавап бирә. Кечкенәдән шулай. Кайчагында аңы әрли дә иде үзен. Ә ул елмая да, үзе килгән бит инде, мин түгел, ди иде.

Әти-әниемә командирлары да шалтырата. Шундый батыр ул үстергәнсез дип, рәхмәт әйтәләр. Күңел күтәрерлек мизгелләр, чыннан да, күп үзе. Шатланасың да, горурланасың да. Әмма ул ничектер секунд эчендә юкка да чыга кебек, чөнки билгесезлек үз эченә өермә кебек алып кереп китә. Хәзер безгә ирләре, уллары мобилизацияләнгән бик күп гаиләләр шалтырата. «Ничек түзәсез?» – диләр. Мин инде шалтыраткан кешеләргә дә: «Начар хәбәрләр юк. Барысы да яхшы булыр, дип өметләнәбез», – дип кенә җавап бирергә өйрәндем. Сүз дә юк, авыр, әмма безнең әтиләребез, ирләребез, улларыбыз Ватан алдындагы бурычларын үти. Димәк, безгә дә җебеп төшмәскә, аларга тылдагы терәк булырга кирәк. Бары бер генә теләк: Җиңү яулап, ир-егетләребез тизрәк өйгә кайтсыннар иде, тыныч тормышта яшәсәк иде. Бу көннәрне якынайту өчен без барыбыз да кулдан килгәнне эшләргә тиеш.

ӨЧ ИГЕЗӘК – ӨЧ ТУГАН

ӘНИЛӘР МОНЫ КҮКТӘН ТӨШКӘН БӘХЕТ ДИП АТЫЙ

Өч игезәк. Өч тапкыр зуррак җаваплылык, шатлык һәм өмет. Мәшәкате дә өч тапкыр арта. «ВТ» журналисты берьюлы өч бала тапкан әниләр белән сөйләште. Алар бу вакыйганы, күктән төшкән бәхет, дип атый.

«Өченче бала сорадык – өчне бирделәр»

Шакиржановларның шәхси архивыннан

Балтач районының Куныр авылында яшәүче Гөлназ һәм Илнар Шакиржановлар биш бала үстерә. Кызлары Нәзилә, уллары Ильяс янына тагын бер сабый – ир бала алып кайтырга теләгән алар. Бер бала урынына тупырдап торган өч малай туа.

– Без ирем белән – күпбалалы гаиләдә үскән кешеләр. Илнар еш кына, их, биш балаң булса иде, дип әйтергә ярата. Менә фәрештәнең «амин» дигән чагына туры килү шул була инде ул, – ди Гөлназ. – Мин авырга узгач та, беренче УЗИны 8 атнадан ясадылар. Табиб: «Өчәү», – дигәч, телсез калдым. Әле ул тагын карый. «Тукта әле, Гөлназ, тагын юкмы икән?» – ди. «Шушы өчесе җитәр», – дигәнем истә. Ирем минем чыкканны машинада көтеп утыра иде. Мин аңа өч бармагымны күрсәттем. Ә ул аңламый тора. «Кабат сәгать өчтә киләсемени, бар кире кереп кара әле, Ильясны бакчадан аласыбыз да бар бит», – ди. Мин тагын өч бармагымны күрсәтәм. Авызны ачып сүз әйтерлек түгел идем. Ирем аңламый гына бит. Өч балабыз булачагын белгәч, ул да сүзсез калды. Игезәкләр табу – гадәти күренеш, өч бала исә безнең өчен бик зур вакыйга булды.

Гөлназның карынындагы малайлар ай үсәсен көн үсә. Дүрт айлык чакларында инде корсагы бала табарга җыенган хатын-кызныкы кадәр була. Табиблар да саклый үзен. Табарга ике ай кала Казанга җибәрәләр. Шөкер, малайлар сау-сәламәт туа. Өчесе дә тиешле гәүдә авырлыгын җыйган. Әниләренә Кесарь кисүе ясасалар да, малайлар, туугач ук, үзләре сулый, ашарга сорыйлар. Хәтта шәфкать туташлары да шакката. Алар ясап биргән катнашмалы шешәне куллары белән тотып имәләр. Табиблар аларны, яшәргә туган малайлар, дип атый. Гөлназ үзе бала табуны авыр кичерә. 7 көн дәвамында урыннан тора да алмый.

– Кечкенә чакларында авырлык сизелде инде, – дип искә ала хәзер. – Өч бала табучыларга дәүләттән аерым ярдәм каралмаган. Декрет акчасын да ике балага гына түләделәр. Табиб УЗИ үткәргәндә, сумманы өчкә тапкырлап алалар иде юкса. Акчаның мәңге җитәсе юк аның, ә балаларыбызда – бар өмет. Аларның иманлы, тәрбияле, тәртипле булып үсүләрен телим. Улларыбызга Мөхәммәд, Ибраһим һәм Сөләйман исемнәрен куштык. Алар шулкадәр бердәм. Өчесе бергә бик тату үсәләр. Уеннары да күңелле. Әллә ниләр уйлап чыгаралар. Мин аларны, авылдагы бакча ябылмасын дип, 1 яшь тә 3 айлык вакытта ук бакчага бирдем. Тиз үстеләр улларым. 3 яшь ярым инде хәзер үзләренә. Бер генә теләк – балаларыбыз исән-сау булсын!

«Тагын табар идем!»

Таҗетдиновларның шәхси архивыннан

Баулы районының Хансөяр авылында яшәүче Алинә Таҗетдинованың игезәкләренә – өч ай гына әле. Дүрт яшьлек уллары Шамилгә иптәш алып кайтабыз дип, алар берьюлы өч кыз алып кайтканнар.

– Йөгем 12 атналык вакытта Әлмәттә УЗИ уздым. Табиб карады да: «Сезнең өч балагыз була», – диде. Миңа шунда шок булды. Табибтан иремә үзенең әйтүен сорадым. Миңа ышанмас, дидем. Аны яныма керттеләр. Ул, экранга карап, тик утырды. Ул көнне Әлмәттә йөрисе җирләребез дә күп иде. Өч балабыз буласын ишетү әллә нишләтте. Тизрәк өйгә кайтып киттек, – дип искә ала Алинә.

Ире үзе дә игезәк сыңары булгач, алар ике балага әзер булалар. Ә менә өчкә – юк.

– Әкренләп ияләштек без. Үзем дә – биш балалы гаиләдә үскән кеше бит мин, – ди Алинә. – Җиңел күтәрдем. Корсак кына тиз үсте. Шуңа күрә табиблар вакытыннан алдарак таптырды. Кызларым 4 октябрьдә генә туарга тиешләр иде. 25 августта аларны ярып алдылар. Беренче кызым – 2,2 кг, икенчесе – 1,9 кг, өченчесе 2 кг булып туды. Җитлеккәннәр иде инде. Әкренләп балаларны карарга да өйрәндем. Кызларым бик акыллы, чиратлашып кына елыйлар. Берсен юатканда, икенче сабыр итеп тора. Өчесен дә имезәм. Улым Шамил дә булыша әле миңа. Кечкенә булса да, яннарында йөгереп кенә йөри. Эштән кайткач, ирем дә ярдәм итә. Бергәләп бәхет төенчекләрен үстерәбез инде. Мин балаларны бик яратам. Тагын табар идем әле.

Ире тагын бер малай булуын тели икән. Алинә каршы түгел. «Бер урынына тагын өчне бирсәләр дә, алып кайтачакмын», – ди.

«Өчесе өч төрле»

Питрәчтә яшәүче Мөхәммәтҗановлар гаиләсендә туып-үскән өч егет – Илсур, Илнар, Илнур Мәскәүдә табиб булып эшлиләр. Өйләнергә өч игезәк әзләүләре турында без язган идек инде.

– Өч улым да йөзгә-биткә бик охшаш. Кешеләр бутый аларны, без аерабыз. Тик менә холыклары гына бер-берсеннән аерыла. Өчесе – өч кеше инде, – ди әниләре Светлана. – Әмма алар гел бергә. Бер-берләрен тулыландырып торалар. Берсе лидер булырга ярата, икенчесе сабыр, өченчесе кызурак. Теләкләре – гаилә кору. Әмма иртәдән кичкә кадәр эшләгәч, кызлар белән таныша алмыйлар. Шулай да күңелне дә юатып куялар, бер елдан өчебез дә өйләнәбез, диләр.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Мөхәммәтҗановларның шәхси архивыннан

Белгеч сүзе

Галия ГЫЙМАДИЕВА, психолог:
– Карында да бергә булгач, игезәкләр үзара бик бәйләнгән була. Тагын шул ягы да бар: алар һәрвакыт янәшәдә таяныр кеше булганны белеп яши. Әмма әти-әниләр аларның өчесенә бер кеше итеп түгел, һәркайсына аерым шәхес итеп карасын иде. 2–3 яшьләргә кадәр пардан киендерү ярый. Әмма балада «мин», «минеке» дигән холык барлыкка килгәч, аларга сайлау мөмкинлеге бирергә киңәш итәм. Төрледән-төрле түгәрәкләргә йөртергә, һәркайсының сәләтен ачарга кирәк. Кабатлап әйтәм: игезәк балалар бик дус була. Ә инде берьюлы күп бала алып кайтырга җыенган әти-әниләр моңа алдан ук әзер торырга тиеш. Бөтен эшне планлаштырып куярга, якыннардан, туганнардан ярдәм сорарга кирәк. Янүгызда ун ярдәмчегез әзер торсын.

Әлфия ГАРИПОВА, акушер-гинеколог:
– Карында берничә яралгы йөртү хатын-кыз өчен җиңел әйбер түгел. Мондый сабыйлар кайбер очракта авыру да туа. Балаларда баш мие ялкынсыну да күзәтелә. Хатын-кызның сәламәтлеге дә какшарга мөмкин. Күбрәк йөрәк-кан тамырлары системасына зыян килә. Зурайган саен, сабыйларның авырлыгы кан тамырларына зыян сала. 20 атнадан соң бу балаларның төшү яки вакытыннан алда туу куркынычы була. Шуңа күрә һәрдаим табибка күренеп тору, гәүдә авырлыгын контрольдә тоту мәҗбүри. 28 атнадан башлап балаларның йөрәк тибешен тикшертеп торырга кирәк.

Бу – кызык!



- Хатын-кызда 200 циклга бер тапкыр берничә күкәй күзәнәк өлгерә һәм игезәкләр яралу мөмкинлеге барлыкка килә. Моннан тыш, игезәкләр туу бер күкәй күзәнәкнең бүленүе нәтиҗәсендә булырга мөмкин.
- ЭКО вакытында игезәкләр туу ихтималы арта, чөнки балага узу ихтималын арттыру өчен, берьюлы ике эмбрион кертелә, аерым очракларда 3 булырга мөмкин.
- Игезәкләр 80 очракка бер тапкыр, ә өч игезәк 8000 очракка бер тапкыр күзәтелә. Ә менә берьюлы 6 бала табу очрагы 4,4 миллионга бер тапкыр очрый икән.
- 1971 елда АКШта беренче тапкыр 11 бала туу теркәлгән. Икенче очрак 1977 елда Бангладешта булган. Ике очракта да балалар яшәп китә алмаган.
- 10 бала табу очраклары 1924 елда Испаниядә, 1936 елда Бразилиядә теркәлгән. 2009 елда АКШта бер ханым 8 игезәк таба. 2008 елда Мисырда бер фермер хатыны 7 бала таба, аларның барысы да исән-сау кала.

Фирдания Макарованың шәхси архивыннан

КЕШЕ КАДЕРЕ

«Аның бит хәтта вафат булганын да әлегәчә белмәүчеләр бар. Төрле чараларга чакырып, әледән-әле шалтыраталар. Үзе исән чакта Татарстан Мәдәният министрлыгына ышанып тапшырган әсәренең дә язмышы билгесез. Гомерен татар сәнгатенә багышлаган кешенең мирасы өчен гаиләсе генә җаваплымы? Бездә шәхес кадере бармы?» Шушы сорау-борчулары белән редакциягә танылган композитор Марс Макаровның хатыны Фирдания МАКАРОВА мөрәҗәгать итте. Җавабын бергә эзләдек.

:: Фирдания апа, без Марс Макаровны күбрәк «Киек казлар», «Агыла да болыт, агыла», «Мәк чәчәге» кебек популяр җырлар авторы буларак беләбез. Күләмле әсәрләр иҗат итүе турында үзе дә бик шауламады кебек.

– Марс үзен төрле яклап сынап караган тынгысыз җаннарның берсе иде. «Мин – менә шундый кеше», – дип, үзен күрсәтә генә белмәде. Студент чакларында ук җырлар язган, хореограф Гай Таһиров белән татар биюләренә багышланган ике китап әзерләгән, студентлар өчен баян эшкәртмәләрен булдырган, Тукайга багышланган күләмле музыкаль әсәр язган шәхес ул. Соңгы елларда Марсны шагыйрь буларак та таныдылар. Кызганыч, «Кайтаваз» дигән китабын нәшриятка үз куллары белән тапшырса да, аның табадан төшүен күтеп җиткерә алмады. Вафатына бер ел булгач, шушы китапны укучыларга татар филармониясе залында тәкъдим итәргә теләдем, анысы да төрле сәбәпләр аркасында булмый калды. Бусы 2017 ел иде. Шушы презентация мәшәкате белән Мәдәният министрлыгы бусагасын таптаганда, ул чактагы министр урынбасары Эльвира Камалова: «Марс абыйның симфониясе бездә, алып китегез», – диде. Шул чакта, бәлки, берәр оркестрга башкарырга бирү җаен табарлар дип, алып китмәдем. Инде хәзер шул симфонияне дә табып булмый. Алты кисәктән торган симфония икәнен генә беләм, төп нөсхәсен илтеп биргәч, бездә күчермәсе дә юк. Шундый күләмле әсәр юкка чыкмасын иде инде. Мин аны министрлыкта шактый эзләттем. Хәзер инде ул бүлекләр дә, ул хезмәткәрләр дә юк анда. Кызганыч, сәламәтлегем дә бетте, инде бусагалар таптый алмыйм, аякларым авырта. Әмма әсәр кадәр әсәр югалмагандыр, дәүләт оешмасында архив эше алып барыладыр дигән өмет бар әле миндә.

:: Мирасны популярлаштыру, саклау җәһәтеннән Композиторлар берлеге ярдәм итә аламы?

– Татарстандагы берлекләр арасында иң пассивы – мөгаен, Композиторлар берлегедер. Кемгәдер сан бар анда, кемгәдер юк. Исән чакта да белмиләр, үлгәч тә аларга таянып булмый. Бу яктан Язучылар берлеге яхшы эшли. Ә Композиторлар берлегендә Рәшит Абдуллин, Шамил Шәрифуллин кебекләргә дә игътибар булмады. Марсны берлеккә алуны кирәксенмәделәр. Гәрчә җырлары гына түгел, күләмле әсәрләре булса да. Әйтик, Анатолий Шутиков җитәкчелегендәге халык уен кораллары оркестры ул иҗат иткән Тукай шигъри циклына симфоник поэманы әле дә яратып башкара. Дөрес, Марс берлеккә алуларын сорап язды, берлек рәисе Рәшит Кәлимуллин белән дә сөйләшеп кайтты. Әмма теләгенә ирешә алмады. Хәер, ул ялынып йөри торган кеше түгел иде. Безгә бит хәтта халык артисты Шәүкәт абый Биктимеров булышып җибәрмәсә, фатир да булмас иде. Тугыз ел тулай торакта яшәгәннән соң, фатирга күченү үзе бер могҗиза кебек булды. Ә 1987 елда, Татарстан Министрлар Советы рәисенең беренче урынбасары Мансур Хәсәнов янына фатир мәсьәләсе буенча кергәч, ул да Марс Макаровның Композиторлар берлегендә булмавына гаҗәпләнгән иде. Мансур Хәсәнов кушылгач кына, «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» исеме бирелде. 1994 елда, ниһаять, фатир алу бәхетенә ирештек.

> Дөрес, талантлар барысы да шундый алар. Бар белгәннәре – иҗат. Гаиләне тарту, тормышны алып бару – хатыннары җилкәсендә. Иҗат – бер нәрсә, аны таныту да кирәк бит әле. Бу яктан Марс чая түгел иде. Бөтен иҗаты халык фольклорына, Тукай әсәрләренә бәйле булса да, Тукай премиясен ала алмады.

Әлеге премия комиссиясенә Язучылар берлеге һәм керәшеннәр җәмгыяте тәкъдим итеп карады, хәтта кандидат итеп тә теркәмәделәр үзен. Аллаһы Тәгалә талантны бирсә дә, шул талантын күрсәтә белмәде.

:: Хәсән Туфан фатихасы белән җырлар авторы булып киткән диләр, дөресме?

– Чыннан да, Марсның беренче җыры «Киек казлар» (Хәсән Туфан шигыре). Мәрхүм шагыйрь Хәсән Туфанның шактый еллар Сталин концлагерьларында җәфа чигеп, ачы йөрәк сагышы белән язылган тирән лирикасы, күрәсең, Марс Макаровка нык тәэсир иткәндер. Бу җырны ул башта ансамбль солисты Нәфисә Васыйлова белән радиога яздыра. Аннары аны фортепьяно белән дә, Татарстан Җыр һәм бию ансамбле хоры белән дә яздыралар. «Киек казлар» ансамбльнең иң уңышлы җырларыннан санала. Марс җырны махсус Нәфисә Васыйлова тавышын күздә тотып яза. Ә беркөнне радиодан яңа язмалар тапшыруында, үзенең «Киек казлар»ын ишетеп, Хәсән Туфан таң кала. Ул моны соңыннан Марсны эзләп өйләренә баргач сөйли. Бәхетенә, Марс үзе өйдә булып, ишекне ача һәм каушап кала. Хәсән Туфан, сине күрәсем килгән иде дип, эзләп килсен әле! Алар бик матур әңгәмә коралар, соңрак Марс пианинода Хәсән ага теләге белән «Киек казлар»ны уйнап җырлый. Хәсән Туфан шушы килүендә, үзе белән алган шигырьләр китабында: «Марс энем, бу билгеләп куелган шигырьләргә дә игътибар итәрсең әле, бәлки киләчәктә популяр җырлар булып китәр», – дип, аңа култамгасы белән китабын бүләк итә. «Ай чыга Арча кырыннан», «Барган саен еллар җылырак», «Агыла да болыт агыла», «Каеннар көтәләр», «Юксындырсаң, нишләрмен?» кебек җырлар Хәсән Туфан үтенече белән языла. Менә шуннан Марс популяр җырлар авторы булып халык теленә керә.

:: Марс абый шәхесләрнең онытылуына үзе дә борчыла иде булса кирәк. «Сәнгатебез йолдызлары» дигән китапка шул сәбәпле алынгандыр.

– Шәхес кадерсезлеге бик борчыды аны. Китапка алынуы да шуңа. Беренче җыры Хәсән Туфан шигыренә «Киек казлар» булгач, бу эшне аның турында истәлек язудан башлады. Шәхесләрне генә барламады, онытыла барган җырларның тарихларын да язды. Бу җәһәттән «Мирас» журналында махсус сәхифә дә алып барды. Эшләгән эшләре байтак, җырлары Татарстанда гына түгел, Башкортстанда да яратып башкарыла, тик менә ТАИС аркылы гонорары гына тулаем түләнми.

Үзем исән чакта, иҗатын ничек тә онытмаска тырышырмын анысы. Ә миннән соң Марс Макаров иҗатын кем кайтарыр? Бу сорау бик борчый мине.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Редакциядән: Марс Макаров иҗат иткән симфониягә бәйле сорауны редакция Татарстан Мәдәният министрлыгына юллады. Әлегә җавап алынмады.

Әңгәмәдә телгә алынган симфония уңаеннан «ВТ» юристы Булат ЗАКИРОВ аңлатмасы:

– Композитор Марс Макаров симфониясенә бәйле вазгыять буенча дөрес хокукый бәя бирү һәм җаваплы зат билгеләү өчен, һәрьяклы анализ ясарга кирәк. Беренче чиратта, бәхәстә катнашучыларның нинди раслау документлары бар икәнен һәм алар арасында үз вакытында нинди хокук мөнәсәбәтләре барлыкка килгәнен билгеләргә кирәк. Симфонияне министрлыкка тапшыруны раслаучы дәлилләр булмаган очракта, дәүләт органының гаебе бармы, юкмы икәнен бертөрле әйтеп булмый.

Бу очракта Марс Макаров варисларына дәүләт органы җитәкчесе исеменә хәзерге вакытта симфониянең төп нөсхәсе кайда икәнне билгеләү үтенече белән мөрәҗәгать итәргә киңәш бирергә була, чөнки бу сәнгать әсәре бөтен татар халкы өчен кадерле.

Мондый хәлләрдән саклану өчен, авторларга берничә киңәш:

✓ интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен башка затларга тапшыру фактын документлаштырырга онытмаска;

✓ төп нөсхәләрне ышанычлы урында сакларга һәм башка затларга бары тик күчермәләрен тапшырырга;

✓ интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен (язма әсәр, музыкаль әсәр) намуссыз файдаланудан яки үзләштерүдән саклау өчен, хосусыйлык турында килешү имзалау да артык булмас.

Зөфәр ХӘЙРЕТДИНОВ, Татарстанның халык артисты, композитор, Россия авторлар җәмгыятенең Татарстандагы бүлеге җитәкчесе:

– Марс Макаровның симфониясенә бәйле вазгыятьне бик яхшы беләм. Кызганыч, министрлыкта әлеге әсәрнең табылуына ышанып җитмим. Заманында ул оешмада үземнең дә документларның берничә тапкыр югалганы булды. Хәтта бер интервьюда, «Министр булсагыз, нишләр идегез?» дигән сорауга: «Иртәгәсен үк министрлыкны таркатыр идем», – дип җавап бирдем. Мин бу очракта авторларга киңәш кенә бирә алам. Бервакытта да, беркая да әсәрегезнең төп нөсхәсен тапшырмагыз. Әсәрне кемгәдер тәкъдим итәсез икән, аны канцелярия бүлеге аша башкарыгыз. Авторда әсәрнең теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы булырга тиеш. Бу хакта әлеге бүлектән белешмә алу да комачау итмәс. Марс Макаров зур талант иясе, әмма гади, самими, ышанучан иде. Күрәсең, бөтен кеше дә үзе кебек дип уйлап, киләчәкне кайгыртмагандыр.

Хәбир ИБРАҺИМОВ, «ТАИС» оешмасы җитәкчесе:

– Язмада телгә алынган гонорар мәсьәләсе буенча эш болайрак тора. Авторлар белән Россия авторлар җәмгыятенең Татарстан бүлеге һәм безнең оешма шөгыльләнә. ТАИС эстрада мәсьәләләре белән турыдан-туры эшләми, Россия авторлар җәмгыяте аша эшли. Чөнки өч кенә кешедән торган оешма эстрададагы хәлләрне күзәтеп өлгерә алмый. Җәмгыять акчаны җыя һәм безгә күчерә. Без, үз чиратыбызда, аны авторларга күчерәбез. Менә ярты ел инде Россия авторлар җәмгыятеннән акча күчкәне юк. Өзеклекнең сәбәбе әнә шуңа бәйле. Авторлар яки аларның варислары, ТАИС белән араны өзеп, турыдан-туры Россия авторлар җәмгыяте белән дә эшли алалар.

ЛАНДЫШ ӘБҮДӘРОВА

УМАРТА

(ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕК)

< Ахыры. Башы 14, 21, 28 октябрь, 4, 11 ноябрь саннарында

Аның каравы Камил үзендә ниндидер тыелгысыз зур бер көч барлыгын сизде. Бу хис аңа тынгы бирмәс булды. Үсмер егет бу көчкә сөенергә дә, көенергә дә, аның белән алга таба ничек яшәргә икәнен дә белмәде. Ул хәзер кешеләр белән идарә итә ала иде. Нәфисә кебек. Кыз бер генә кеше белән дә түгел, ә гавам белән идарә итә ала, ләкин әле үзенең нинди көчкә ия булуын ваемламый гына. Ә менә Камилнең күңелен кытыклый башлады инде. «Алай ярамый, алай дөрес түгел», – ди эчке тавыш әнисе Энҗебикә тавышы белән. «Мин зыян итмим аларга, минем максатым башка!» – дип каршы төшә яңа Камил. Ләкин теләсә кайсы көчкә каршы көч бар дип аңлатты физика дәресендә укытучы Мансур абыйлары Ньютонның өченче законын. Монда да Зарифә булды шундый көч.

Көннәрдән бер көнне Камил Илнур белән ферма сарыклары янына керде. Бохар да калмады. Сарыклар таныш булмаган әлеге ике үсмернең мыштым гына утарга керүләрен сагаеп каршылады. Печән кетердәтеп торган җирләреннән туктап, малайларга карап тора башладылар.

– Күз алдына китерәсеңме, болар сарык түгел, ә кешеләр, имеш. Клубта рәт-рәт тезелеп утырганнар да сиңа шушы сарыклар кебек карап катканнар, – дип көлде Илнур.

– Тс-с! – диде Камил. Ул чын фокусчы кебек яңа аудиториясен өйрәнә иде.

– Юк, күз алдына китер әле. Берничә мизгелдән барысы да йоклый.

– Йоклатырсың, бар, безнең авылларны. Хәләф абзый белән Зарифәттәй үлсә дә йокламаячак, – диде Камил өлкәннәрчә. Аның бу турыда уйлап караганы бар иде инде. Зарифәне искә төшерү белән үк сыртын чыбыркы әчесе яндырып үткәндәй булды. Ул каравылга төшкәнче өлгерергә кирәк иде. Илнур ферманың авыр ишекләрен эчтән бикләп куйды. Сарыклар селкенмичә дә бу икәүне күзәтә. Камил шәүлә кебек йөзеп кенә сарыкларга якынлаша башлады.

– Ничек? – Илнур түземсезләнә иде. Камил инде көтүгә килеп терәлә язды. Тегеләре һаман селкенми. Илнур, эш пеште дип, кулын уа гына башлаган иде, кинәт түшәм ишелгәндәй булды. Һәм аннан тавышсыз гына кемдер сикереп төште. Сарыклар дәррәү диварга ташланды. Ә тege кеше Зарифә иде. Үсмерләргә караганда, Зарифә елгыррак булып чыкты, тегеләр аны-моны аңышканчы, ул Камилне эләктереп алды да авызына яулык каплады. Тегесе эрегәндәй, җиргә бөгелеп төште. Ул арада Илнур, иптәшен коткарырга дип, Зарифәгә (!) килеп ябышты. Тегесе бик җиңел хәрәкәтләр белән икенче үсмерне дә тынсыз итте. Боларны күзәтеп торган Бохар да читтә кала алмады, ул да Зарифәгә ташланмакчы булды, әмма каравылчы мәчене дә тегеләр янына сузып салды. Зарифәне ике аягында басып торган көйгә күргәннәре булмагач, егетләр болай да югалып калганнар иде, өстәвенә түшәмнән төшсен әле!

Бераздан алар өчесе дә һаман да ярымаңсыз хәлдә каравыл өендә ята иде. Күп тә үтмәде, районнан милиция килеп төште. Милиция «УАЗигы» үткәнне күреп, Энҗебикә аларның эзенә бастырып килеп җитте. Икенче мизгелдә ишектә Мостафаның башы күренде.

– Улым! – дип җан ачысы белән кычкырып җибәрде Энҗебикә, улының җансыз гәүдәсен күргә. Батырлык кылган кеше кебек гайрәтләнеп торган Зарифә почмакка елышты: Энҗебикә – улы өчен Зарифәнең дә, әлеге погонлы әфәнделәрнең дә бугазын чәйнәп өзәргә сәләтле ана. Мостафа балтасының да йөзе шундый итеп ялтырый: аңа карап, күзгә сөрмә тартырга була. Милиция чакырып ашыкты бугай ул...

– Тавышланмагыз, исән алар, – диде участок милиционеры, беркетмә тутырыр өчен өстәлдә урын әзерләп. – Сөйләгез, ничек булды? Сорау Зарифәгә иде. Улын уятырга тырышкан җиреннән Энҗебикә колакларын торгызды, сагаеп калды. Чыннан да, ничек булды?

– Мин... мин аларны үтердем дип уйладым. Шуңа курыктым да тизрәк сезне чакыртырга булдым, – дип, гаепне үз өстенә алды Зарифә.

Милиционерлар үзара карашып куйды. Каракүл халкы читләргә сер чишәме соң инде? Монда да хикмәт башка нәрсәдә икәнен сизә иде алар, ләкин җеп очын оста итеп яшерә беләләр бит. Ул арада малайлар бер-бер артлы баш калкыта башлады. Погонлы кешеләрне күргә, янә йокларга сабыштылар. Хәтта Бохар да кымшанмаска кирәклеген аңлый иде булса кирәк.

– Мин аларны караклар дип белдем, сарыклар ашатырга килгән булганнар икән, э-э-э, җәмгыятькә файдалы хезмәт... Әйткәннәр иде аны киләбез дип, онытканмын, – дип дәвам итте җайдак хатын. Энҗебикә белән Мостафа Зарифәнең хәйләсен шунда ук сизеп алды. Үсмерләр дә җиңел сулап куйды. Хәзер инде аларның чираты җитте: торып, берни булмагандай исәнләшергә генә кирәк иде...

Милиционерлар буш кул белән китәргә мәҗбүр булуларына пошынып, иске «УАЗик»ларын кабызганда, «Карагыз аны!» дип бармак янады. Тегеләре алтысы бер рәткә тезелеп, дивар хасил итеп, баш селкеп калдылар. «Болар безне генә кызык итте түгелме соң?» – дип, баш кашыды соңыннан капитан, дәшмичә озак итеп тәмәке суырып барганнан соң.

Бу хәлдән соң ике өйдә дә бик җитди сөйләшү булды.

– Әти, әни, Нәфисә хакына! Ул гомер буе кешеләр арасына чыга алмыйча яшәргә тиеш түгел! – дип акланырга тырышты Илнур.

– Колхоз сарыкларына Нәфисәнең ни катнашы бар? Шуны аңлат син миңа!!! – дип җикеренде Мостафа. – Аларның әнә Зарифә белән милициядән башка этадәмгә дә кирәкләре юк!

– Әти, Камил аларны гипнозлап карамакчы иде. Ул шулай итеп осталыгын арттыра. Әгәр дә кешеләрне дә бер караштан гипнозларга өйрәнсә, Нәфисәне дә аңлап булачак. Ул да бит...

– Нәфисә шулай булып туган ул. Аны үзгәртеп булмый! – Мостафа әйткән сүзеннән кайта торганнардан түгел. Ул кызының үзгәрүен, кешеләр арасына чыгуын теләми дә бугай.

– Мостафа, – дип икеләнеп кенә сүзгә кушылды Фатыйма. – Бәлки, чыннан да ярдәме тияр. Без дә бит мәңгелек түгел...

– Абыйлары бар аның! Ә Энҗебикә малаена әйт: юк белән булышмасын!

– Аларның үз тормышы, үз язмышы. Илсур да соңгы хатында хәрби хезмәттә калам дип язган. Илнур да укуын дәвам иттермәкче була. Өйләнерләр, үз балалары туар... – Фатыйма эчтән сулкылдап елый иде инде.

– Әйе, әти, абый, офицер булып кайтам, диде. Кайтачак ул. Нәфисәбезне ул саклар. Ә мин табиб булачакмын, дәваларбыз. Әни, елама, без Нәфисәне ташламаячакбыз! – Илнур өчен дөнья катлы-катлы да, катлаулы да түгел иде әле. Ул әйткән сүзләренең нәкъ шулай буласына ихластан ышана иде.

Мостафа, «Күрдеңме!» дигәндәй, Фатыймага карады да бу сөйләшүләрне ишетмичә йоклап яткан кызы янына килде. Бу кадәр дә гүзәл, татлы булса булыр икән аның газизе. Юк, Нәфисәләре гаиләләренә имгәк түгел, киресенчә, байлыгы аларның. Ә байлыкны сакларга кирәк! Каракүлгә нигез салган нәсел баласы ул Мостафа. Борыңгы нәсел. Зираттагы иң әүвәлге кабер ташы унҗиденче гасырга карый, Мостафаның уникенче буын бабасының кабере өстендә. Моңа кадәр авылның йөзек кашы булып яшәде, моннан соң да... Нәфисәне тел-теш, җил-яңгыр тидермичә саклап үстерү – аның ата-баба алдындагы бурычы. Мостафаның кан хәтере йөрәгенә шушы хакыйкатьне пышылдый иде. Шуңа да Камил белән Илнурның тырышлыкларына бик ышанып җитми: каш ясыйм дип, күз чыгармагайлары.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының җинаятьчеләрне эзләү идарәсе урлау һәм талау очракларын ачу бүлегенең аеруча мөһим эшләр буенча оперуполномоченные, полиция майоры **Зәетов** Раил Рафис улына, Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Казан Кызыл байраклы Жуков орденлы югары танк команда училищесы» федераль дәүләт казна югары хәрби белем бирү мәгариф учреждениесе хезмәткәрләре: курсантлар батальоны рота командиры **Малкарбаев** Тимур Оспановичка, курсантлар батальоны рота командиры **Осипов** Филипп Дмитриевичка, курсантлар батальоны укытучысы – взвод командиры **Рогожа** Константин Анатольевичка, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге башлыгы **Әхмәтшина** Рамилә Хәсәнгата кызына, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Олы Болгаер авыл җирлеге башлыгы **Сәйфуллина** Зилә Имам кызына, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Зур Әтрәч авыл җирлеге башлыгы **Юнысов** Илнур Шәйхулла улына, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең шартнамәләр һәм конкурс аша сатулар бүлеге баш белгече **Козлова** Лилия Михайловнага, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең автомобиль юлларын һәм күпер корылмаларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь төзекләндерү идарәсе башлыгы **Мөҗипов** Равил Зәбир улына, «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте «Чистай электр челтәрләре» филиалы директорының хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашыру буенча урынбасары **Панфилов** Сергей Валентиновичка, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының хокукый мәгълүмат һәм компьютер системалары бүлеге башлыгы **Сафин** Адел Габбас улына, «Инновацияле индустриаль парк – югары технологияләр өлкәсендәге «Химград» технополисы» технопаркы» акционерлык җәмгыяте баш бухгалтеры **Хәбибуллина** Лилия Мөхәммәт кызына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары **Хәбибуллин** Зөлфәт Флүн улына, «Чаллы педагогия көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директорының укыту-методика эше буенча урынбасары **Шакирова** Люция Мөхәммәтгали кызына, «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директорының иҗат һәм оештыру мәсьәләләре буенча урынбасары **Вәлиуллина** Гөлчәчәк Рафикъ кызына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы җитәкчесе урынбасары **Миңнебаева** Гөлсем Әдһәм кызына, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зәй муниципаль районындагы «Шатлык» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең өйдә хезмәт күрсәтү бүлекчәсе социаль эш буенча белгече **Ишмякова** Галина Александровнага, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесенең мәгълүмат һәм инновация технологияләре бүлеге башлыгы **Редько** Наталья Владимировнага, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе директоры урынбасары **Фоничкина** Ирина Геннадьевнага, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Резерв» мобилизация резервларының республика медицина үзәге дәүләт казна сәламәтлек саклау учреждениесе директоры **Шәрипов** Илдар Сәлимҗан улына, Татарстан Республикасы Баулы нотариаль округы нотариусы **Фәткуллин** Радик Альберт улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама районы буенча идарәсе башлап сорау алу бүлеге башлыгы урынбасары – бүлекчә (анык булмаган җинаятьләрне ачу һәм тикшерү бүлекчәсе) башлыгы, полиция подполковнигы **Гарипова** Әлфия Ваһа кызына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы шәхси состав белән эшләү идарәсенең кадрлар бүлеге башлыгы, полиция подполковнигы **Гыйльмиев** Ренат Гарәфетдин улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе 9 номерлы «Сафиуллин» полиция бүлегенең башлап сорау алу бүлеге башлыгы урынбасары, полиция подполковнигы **Ибниев** Ленар Зөфәр улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Лениногорск районы буенча бүлеге полиция башлыгы урынбасары (җәмәгать тәртибен саклау буенча), полиция подполковнигы **Иваньчин** Андрей Николаевичка, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы җәмәгать тәртибен саклауны һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлекне оештыру идарәсенең шик астындагы, гаепләнүче һәм административ арест салынган затларны саклау, конвоирлау һәм көнкүрешен тәэмин итүне оештыру бүлеге башлыгы, полиция подполковнигы **Решетников** Богдан Андреевичка, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны, отставкадагы полиция майоры **Титова** Галина Владимировнага, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы эксперт-криминалистика үзәгенең биологик экспертиза бүлеге башлыгы урынбасары, полиция подполковнигы **Шиһабетдинов** Рәшит Рөстәм улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны, отставкадагы милиция подполковнигы **Шиһапов** Рафис Наил улына, «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча медицина-санитария часте» федераль казна сәламәтлек саклау учреждениесе клиник госпитале (Казан шәһәрендә урнашкан) хирургия бүлекчәсе мөдире – табиб-хирургы **Строителев** Иван Анатольевичка, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча идарәсе Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе юл-патруль хезмәтенең аерым ротасы 1 взводы (юл-патруль хезмәте) өлкән инспекторы, полиция өлкән лейтенанты **Шәмсиев** Ленар Наил улына, «Казан шәһәренең азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» акционерлык җәмгыятенең 1 номерлы ашханәсе администраторы **Бәширова** Айгөл Зирәк кызына, хезмәт ветераны **Вәлиев** Илгиз Гани улына, хезмәт ветераны **Ямалиев** Әхмәтгәрәй Мөхетдин улына, «МАКойл» акционерлык җәмгыятенең хезмәтне оештыру һәм персонал белән эшләү буенча әйдәүче инженеры **Галимова** Галия Азат кызына, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе монополиягә каршы контроль бүлеге башлыгы **Идиятуллин** Родион Нияз улына; «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводының очкычның үзәк һәм койрык өлешен җыю цехы җыючы-клепальщигы **Мифтахов** Рамил Шамил улына, «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директоры урынбасары **Мортазина** Альбина Фәрит кызына; Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәшү бүлеге башлыгы **Никитина** Инна Николаевнага, «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Төхвәтуллина** Илсөя Җиһангир кызына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны, отставкадагы милиция генерал-майоры **Вайда** Александр Васильевичка **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.**

БЕЗДӘН СЕЗГӘ – 3 БҮЛӘК

1 ЯЗЫЛ!
2023 елның беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына языл

2 КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ЖИБӘР!

89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘККӘ
1. Суыткыч.
2. Микродулкынлы мич.
3. Мультиварка.

П2435
жомга саны
512 сум 70 тиен

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
1143 сум 96 тиен

Акция 2022 елның 26 октябреннән башлап 2023 елның 20 гыйнварына кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru

16+

реклама

Әз-мәз мәзәк

– Әй, егет! Яраткан кызыңа чәчәк ал әле, монда сатып торып туңып беттем.

– Ярар, әби. Бер чәчәгең ничә сум?

– 1000.

– Җылырак киенәсе иден, әби.

* * *

– Ирем скрипкада уйнаганда, мин һәрвакыт елыйм.

– Ә мин – ирем тотализаторда уйнаганда.

* * *

– Вәлиев, нишләп эш урыныңда йоклыйсың?

– Төнлә кечкенә улым йоклатмады.

– Иртәгә аны үзең белән эшкә ал. Монда йоклатмасын.

* * *

– Бу спектакльдән икенче пәрдәдән соң китәргә киңәш итәм.

– Нигә?

– Беренче пәрдәдән соң гардеробта кеше күп, диләр.

Әй, замана!

• • •

Операторның җавап бирүен 47 минут көттем. Ярый әле чиратта беренче идем һәм минем шалтыратуым алар өчен бик мөһим иде.

• • •

– Институтта укыганнарыгызны онытыгыз!

– Мин институтта укымадым шул.

– Алайса, сез безгә туры килмисез, без югары белемлеләрне генә эшкә алабыз.

• • •

Китапны сатып алганда аны шундый иттереп алыгыз: әйтерсең сезнең аны алырга акча, укырга вакыт, куярга урын бар.

• • •

Шимбә көнен мин, гадәттә, хәтерләмим. Чөнки эш атнасыннан чыгып житеп булмый. Ә якшәмбе көн иртәгә эшкә барасы бар дип уза.

• • •

Интернет эшләми башлагач, китап укырга, балаларың белән уйнарга, спорт белән шөгыльләнергә мөмкин… О! Интернет эшли башлады!

• • •

«Кешеләрне ничек алдарга?» дигән китапка заказ бирдем. Килмәде.

Беләсең килсә...

1 Бу бөек рәссамның хатыны тумышы белән Казаннан була:
а) Микеланджело;
б) Сальвадор Дали;
в) Рафаэль.

2 Чебен уртача алганда күпме яши?
а) бер ай;
б) өч ай;
в) алты ай.

3 Россия Федерациясе составында ничә край бар?
а) алты;
б) тугыз;
в) унике.

4 Бу футболчы үз атасы белән адаш:
а) Лионель Месси;
б) Криштиану Роналду;
в) Диего Марадона.

Җаваплар: 1.б); 2.а); 3.б); 4.в).

Сканворд җаваплары

Горизонталь: шалкан, акбур, ау, Рәшидә, яр, Булат, тана, Раяна, ач, уймак, Ленария, Флүс, урлау, Натс, Күәм, Илдар, Ли, ана, аш, Вид, Зәлия, убырлы, еланбаш, унтугыз, шиш, ОСАГО.

Вертикаль: Русланова, ур, Аксубай, Шаһбан, яманат, Ту, буразна, си, рәт, акыру, лего, ир, ылыс, Азия, Ялла, Аза, рамазан, куәт, фук, авылдаш, наян, Гүзәл, шик, Уракчы, Миндияр.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15337 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 370

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+